Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 12 (1377) 1 апрель 2022 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

2

Сугыш кырында батырлык күрсәтеп, хәрби осталыгын раслап та, татар милләтеннән булган өчен түбәнсетелгән яугирләребез азмы?!

12

Татарстанда төшерелә торган «Ибн Фадлан» фильмында хан ролен Кырым татары вәкиле, җырчы Асан Билалов башкара.

14

Милләтебезнең үткәнен тәфсилле ачыклауда Мари илендәге татар авыллары тарихын өйрәнү дә гаять әһәмиятле роль уйный.

Аягүрә алкышладык кабат Сәхнәбезнең олуг аксакалын!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Мәдәният һәм сәнгать советы утырышы кысаларында галимә Гүзәл Вәлиева-Сөләйманованың Милли мәдәният музеен торгызу тәкъдимен Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов хуплады.

- Башкортстан Башлыгы Радий Хәбиров җырчы Салават Фәтхетдиновны Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләде, ирле-хатынлы Зөлфия һәм Җәвит Шакировларга Башкортстанның халык артисты исеме таныклыгын тапшырды.

- Казан кооператив институтының Татар мәдәнияте үзәгендә Евразия рәссамнар берлеге әгъзасы Гөлсем Хаҗиеваның шәхси күргәзмәсе ачылды.

- Әлмәт районы Рус Акташы авылында 200 курчактан торган күргәзмә тәкъдим ителде.

- Ульяновск өлкәсенең «Ел укытучысы -2022» конкурсында милләттәшләребез Тимур Артыков, Рөстәм Айнуллин беренче-икенче урыннарны алды.

- 16 апрельдә Татарстанның Россиядәге Тулы вәкаләтле вәкиллеге Россия башкаласында VII «Мәскәү – Татарстан күпере» яшьләр форумын үткәрә.

- «Партитура» Бөтенроссия яшь композиторлар конкурсының «Опера яки оперетта музыкасы» номинациясендә «Кави-Сәрвәр» операсы белән Миләүшә Хәйруллина җиңеп чыкты.

- 1-3 апрель көннәрендә Татарстан Милли музеенда «Бүләк тапшыру көннәре» уза – казанлылар фондка сирәк предметлар тапшыра алачак.

- Казан ипподромында узган «Нәүрүз» бәйрәмендә «Нәүрүз гүзәле» исеменә Әзәрбайҗаннан Айшан Аликберова лаек дип табылды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Әзһәр ШАКИРОВ, Татарстан һәм Россиянең халык артисты:

«Чит илдән татарлар белән горурланабыз, чөнки алар телләрен, диннәрен, рухларын югалткан кешеләр түгел. Алар безгә бик кадерле, монда килеп, кем икәнлекләрен күрсәтәләр. Мөмкин булган кадәр татарларны чакырыгыз, күрсеннәр бүтән халыклар: кайда гына яшәмәсен татар халкы, ни генә булмасын, алар бүген туганнар кебек дигән фикер калырга тиеш».

СЫНАМЫШЛАР

4 апрельдә кояш янында түгәрәкләр күренсә, игеннәр уңа● 5 апрель төне җылы булса, яз иртә һәм тиз килә● Яз иртә килсә, ташу көчле була● 7 апрельдә түбәләрдә кар ятса, 6 майга кадәр эреп бетмәячәк; бу көнне аяз булса, җәй яшенле килә; яшенле яңгыр яуса, арыш һәм чикләвек уңа; җылы булса – суыта; карлыгачлар очмаса – яз салкын килә.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **5 сәгать 14 минутта** чыкты, һәм ул **18 сәгать 21 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **13 сәгать 07 минут**. Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **32 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **8 апрельдә 13 сәгать 39 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

1 апрель – пианиночы, композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әгъзам (Азон) Нуретдин улы Фәттаховның тууына 100 ел (1922–2013);

– актриса, Башкортстан һәм Татарстанның халык артисты Ризидә Равил кызы Фәхруллинага 60 яшь (1962).

2 апрель – шагыйрь Ләис Мәүлит улы Зөлкарнәйгә (Харрасовка) 60 яшь (1962).

6 апрель – язучы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Якуб Камали улы Зәнкиевнең тууына 105 ел (1917–2003).

7 апрель – драматург Кәшшаф Сафиулла улы Әмировның тууына 100 ел (1922–1996).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Апрельнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 1 апрель.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(1-9 апрель)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **18 февральдән 29 апрельгә кадәр** бавыр һәм үт куыгы актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны чистарту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген шәгъбән аеның 29 нчы көне

КӨН КАДАГЫНА

Үгисетелгән хәрбиләр

Совет чорында да интернационализм атлы ямманың чын йөзен чагылдыручы һәм татар милләтенә кагылышлы гаҗәеп хәлләр булган. Аеруча 1988 елда ПВОның зенит-ракета гаскәрләре командующие итеп билгеләнгән генерал-полковник Рәсим Сөләймән улы Акчуринга кагылышлы вакыйга таң калдыра. 1982 елда Ленинград күген саклаучы ПВО армиясе командующие вазифасына иң кулай кандидат буларак генерал-лейтенант Р.Акчурин карала. ПВОның Хәрби советы тәкъдимне хуплый, Оборона министрлыгында һәм КПСС-ның Үзәк комитетында үткән әңгәмәләр дә уңай бәяләнә. Тик татар улын мөһим вазифага билгеләмиләр. Сәбәбе соңрак ачыклана. Аңа ул чактагы КПСС ҮК Политбюросы әгъзасы, Ленинград өлкә комитетының беренче секретаре Григорий Романов каршы төшә. Л.Брежнев урынында калу ихтималы зур булган ата коммунистның оятсыз рәвештә: “Октябрь революциясе бишегә өчен әллә татардан башка кандидатура табылмадымы?” – дип белдерүе, халыклар дуслыгы “чәчәк аткан” илдә хәлиткеч аргумент булып чыга.

Партия функционерының татарларга карата үтә шовинистик позициядә торуын Ягъсуф Шәфыйковның “Рейхстагка Җиңү Байрагын кем элгән” исеме белән 2015 елда дөнья күргән китабында танышырга мөмкин. Әмма татар хәрбиләре арасыннан бу төр гаскәрләрдә иң югары үрләр яулаган Р.Акчурин биографиясен хәрби яктан тулыландыру артык булмас. Ул 1954 елда Латвиянең Алуксне каласындагы ябык типтагы ПВО гаскәрләренең 3 нче Балтыйк зенит-артиллерия училищесын лейтенант званиесендә тәмамлый һәм Кыргызстандагы ПВО гаскәрләрендә взвод командиры булып хәрби хезмәт юлын башлый. Яшь офицер хәрби карьера үсешендә зур уңышларга ирешә: Төркестан хәрби округында үткән 11 ел эчендә майор дәрәҗәсе ала һәм дивизион командиры вазифасына билгеләнә. 1965 елда майор Р.Акчурин ПВО гаскәрләренең Хәрби команда академиясенә укырга керә. Биш елдан соң подполковник йолдызлары алган офицерны Мәскәү хәрби округына полк командиры итеп җибәрәләр. Бу – әлеге хәрби округта Академия тәмамлап чыгучы офицерны шундук полк командиры итеп куюның бердәнбер очрагы. Тагын шунысы искитмәле: подполковник Акчурин командалык иткән хәрби берләшмә штабы Кострома өлкәсенең Нея каласында урнаша һәм аның биләмәләре Архангельск өлкәсеннән алып Кострома төбәгенең көньяк чикләренә кадәр җәелә.

● Рәсим Акчурин.

Өч елдан соң милләттәшебез – Горький каласында урнашкан ПВО корпусының зенит-ракета гаскәрләре башлыгы. Бирегә полковник чинын алган Акчурин 1974 елдан, штабы Ярославль каласында урнашкан ПВО корпусы командиры урынбасары вазифасында, тагын бер елдан – шул корпусның командиры. Искәртеп үтик: бу – генерал-лейтенант чинындагылар гына башкара торган вазифа. Хәер, хәрби карьера баскычларыннан бик тиз күтәрелүче Рәсим Сөләймән улы 1976 елдан – генерал-майор, тагын биш елдан генерал-лейтенант чинында хезмәтен дәвам иттерә. Бирегә аңа ПВОның дистәдән артык полкы һәм бригадасы, өч авиация полкы, өч тыл часте буйсына. Ул командалык иткән гаскәрләр фәкать төньяктан көньякка гына да меңнәрчә чакрымга сузыла. Шуңа өстәп, бер үк вакытта Ярославль хәрби гарнизоны башлыгы вазифасын да башкара. Бирегә улы Тимур туа, үзе исә КПССның XXVI съездына делегат итеп сайлана.

1983 елдан – генерал-лейтенант Р.Акчурин ПВОның Мәскәү хәрби округы зенит-ракета гаскәрләре командующие, тагын ике елдан Саклану министрлыгы һәм КПСС ҮК карары белән ПВОның зенит-ракета гаскәрләре командующие итеп раслана, 1990 елдан – генерал-полковник званиесендә. 1992 елда хәрби хезмәт срогын тутыргач, гомеренең 41 елын хәрби хезмәткә биргән милләттәшебез 61 яшендә үз теләге белән отставкага чыга. Кремльдә шул җәһәттән, илнең Куркынычсызлык советы секретаре Ю.В.Скоков белән очрашкан вакытта, хәрби хезмәтен дәвам итү турындагы тәкъдимне кире кага. Әгәр ул чакта ризалашкан булса, хәрби өлкәдә тагын да югарырак үрләр яулаячагы шиксездерми, мәгәр шунысы хак: 200 дән артыграк бригаданы һәм полкны, өч меңләп подразделениене берләштергән ПВОның зенит-ракета гаскәрләре командующие генерал-полковник Р.Акчуринның бу адымыннан татар милләте отышта кала. Баштa ул Мәскәүнең Көнчыгыш округында яшәүче татарларны берләшмага берләштерә, ә 1999–2014 елларда Мәскәү Татар төбәк милли-мәдәни автономиясен җитәкли. 15 ел дәвамында милләт өчен изге гамәлләр кыла, шулардан иң мөһиме Әсәдуллаев йортын татар милләтенә кайтарып бирүдер. Моның өчен ул Россия президенты Путинга мөрәҗәгать белән чыга һәм 2003 елдан бирле Әсәдуллаев йорты Мәскәү татарларының мәдәни үзәге булып тора. Акчуринның гаиләсе дә күп татарлар өчен үрнәк булырлык: ул хатыны Фәүзия ханым белән өч малай һәм бер кыз тәрбияләп үстергән. Өлкән уллары Марат әтисе юлын сайлаган – полковник, уртанчы уллары Илнур – эшмәкәр, кече уллары Тимур да үз тормышын корган, кызлары Римма исә – табиб-терапевт.

Татар хәрбиләренә һәм генералларына карата адым саен очрап торган гаделсезлекләр уңаеннан янә бер мисал китерү вөҗданлы тулырак күзаллау мөмкинлеге бирми калмас. Бу хакта фәлсәфә фәннәре докторы, профессор, МВД генерал-полковнигы (2006) Мансур Сәләхетдин улы Хәкимовның 2006 елда “Татар хәбәрләре” газетасына сөйләгән хикәяте гыйбрәтле:

“ – Милләтегез Сезгә беркайчан да кыенлыклар тудырмадымы?

– Миңа калса, милли мәсьәлә бар һәм аның әле дә беткәне юк. Мин үз вакытында тагын да югарырак дәрәҗәләргә ирешкән булыр идем, әмма үткәрмәделәр. Милләтем аркасында Мәскәүдә хәтта бүлек башлыгы итеп тә куя алмаячакларын әйттеләр. Дәрәҗәви үсеш баскычыннан күтәрелү өчен үзеңнең татар фамилияңне русныкына әйләндерү лазем икән!

– Сезгә бу турыда ачыктан-ачык әйттеләрме?

– Әлбәттә! Дусларым арасында УВД, БХСС башлыклары бар иде һәм алар мине “үстерү” өчен күп тапкыр характеристика язды. Әмма Мәскәү каласының ГУВД кадрлары (кадрлар идарәсе) мине үткәрмәде. Иптәшләрем киләчәк “үсеш”ем, званиеләр алуым өчен СССР Эчке эшләр министрлыгының БХСС Баш идарәсенә урнашу мөмкинлеге булуы турында искәртте. Киңәшләрен тоттым, әмма анда килүем хезмәткәрләрне тәмам аптырашта калдырды. Чөнки, аларның әйтүләренә караганда, Совет хакимияте хөкем сөргән чорда Үзәк аппаратта беренче мәртәбә татар милләтеннән булган хезмәткәр, ягъни мин эшли башлаганмын икән”.

Генерал-полковник Мансур Хәкимов та – үз халкының чын патриоты. “Татары. Воины. Труженики. Патриоты” исемле биографик сүзлек, “Идел-Урал” легионының Совет ягына чыккан бер батальонына багышлап нәшер ителгән ике китап аның ярдәме белән дөнья күргән. Тагын берничә китап чыгарырга булышлык күрсәткән милләтпәрвәрнең Мәрҗани шәкерте, тарихчы-этнограф Хөсәен Фәизхановка һәм аның әтисенә, шулай ук Сталин репрессияләре корбаннарына туган авыллары Сафаҗайда һәйкәлләр ачуы да хөрмәткә лаек. Эчке эшләр органнарыннан киткәннән соң әлеге генерал “Чишмәкәй” хәйрия фонды оештыра, Түбән Новгород белән Пенза өлкәләрендәге балалар йортларына, өлкәннәр приютларына шефлык итә, төрле хәйрия чаралары үткәрә. Игелекле эшләрне башкаруда хатыны Асия һәм кызлары Эльвира белән уллары Рамилнең дә өлешләре зур.

Сарман районының Сөлек авылында туган танк гаскәрләре генерал-лейтенанты Рәфкать Габдрахман улы Ризатдиновның чинын күтәрмәүләре дә, аның татар милләтеннән булуына турыдан-туры бәйле. Советлар Союзы Маршалы Р.Я.Малиновский исемендәге бронетанк гаскәрләре (1962) һәм К.Е.Ворошилов исемендәге СССР Кораллы көчләре Генштабы (1971) Хәрби академиялләрен иң яхшы билгеләргә генә тәмамлаган милләттәшебез дивизия командиры һәм армиянең штаб башлыгы (1971–1975), Польшадагы Легницы каласында урнашкан Төньяк гаскәрләре төркеме штабының башлыгы – командующийның беренче урынбасары (1975–1980), Карпат буе хәрби округы командующие урынбасары (1980–1984) вазифаларын башкара.

(Дәвамы 5 нче биттә).

ЯЗМЫШТАН УЗМЫШ ЮК

«Без яралткан халыклар арасында шундый бер өммәт бар: алар һич туктамыйча хакыйкать (Аллаһ әмерләрен) алга сөрүче, гаделлек урнаштыручы».

Коръән, «Әгъраф» сүрәсе, 181 нче аять

Җәмгыятьне биләп алган бүгенге рухи кризис, билгесезлек һәм хаос шартларында кешеләрне илаһият вә рухи гармония юлына кем алып чыгар? Мондый куелыш Аллаһы Тәгалә тарафыннан әле яралтылышта ук тәкъдир кылынган. Аллаһ сүзенә игътибар итик: «Әй иманлы бәндәләр, арагызда диненнән язган кеше булса, белеп торсын: Аллаһ Үзе сөйгән мөэминнәргә кече күңелле; кяферләргә караганда итагатьле вә абруйлы бер кавем китерәчәктер. Алар Аллаһ юлында Җиһад итәр вә һичбер кыенлыклардан курыкмас. Бу Аллаһның Үзе теләгәненә биргән юмартлыгы. Аллаһның ярлыкавы вә гыйлеме киңдер» (Коръән, 5:54). Хактан да, Аллаһ кайсы кавемне дөньяның тарихи күчәре – Урталык җирләрендә бар кылган соң? Кемгә Ул анда дәүләтләр кору һәм дан-шөһрәт казану мөмкинлеге биргән? Кемнең телен кавемнәр арасында аралашу вә аңлашу теле иткән дә, кемгә вөҗдан һәм иҗтиһат иреге биргән? Шайтан коткысына бирелеп, үзара тарткалаша башлагач һәм аек акыл йөртү сәләтен вә уяулыгын югалткач, кемне дәүләтсез калдырган? Хак Тәгалә кемне җәбер-золым һәм дәүләтсезлек шартларында биш гасыр дәвамында сынаган? Таныдыңмы инде, милләттәшем? Үз-үзеңне тану әнә шуннан башлана.

Әйе, Җәнабе Хак татарны юмартлык белән дә, кыенлыклар аша да сынаган, аны бүгенге илаһи миссиясенә әзерләгән. Сынаулар исә (тел, моң, рух, тарих кебек хис вә милли аң чыганакларына тыкшынулар, милли мәгарифне җимерү һ.б.) бүген дә дәвам итә. Әмма Аллаһның төп сынавы әле алда. Ул – Аның татарга тәүхиди-иҗтиһади исламның асылын аңлауда һәм илаһият кануннары буенча яшәүгә күчүдә үрнәк вә әйдәп баручы көч булу тәкъдире. Шуның өчен Хак Тәгалә аңа исламның асылын киң мәгънәдә аңларлык һәм башкаларга да аңлатырлык фикерләү сәләте биргән, яшәвен дә Урталык җирләрендә тәкъдир иткән. Әгәр милләт күп гасырлык авыр сынаулардан соң да иманын һәм асыл сыйфатларын саклап кала алган икән, димәк, бу – «Аллаһның үзе теләгәненә биргән юмартлыгы». Ә тәүхиди-иҗтиһади ислам, кеше Аллаһтан башка беркемнең дә колы түгел, дигән рухи бәйсезлек карашы тәрбияли, тәкъдир белән бергә, үз язмышын корудa аның иреген, җаваплылыгын һәм тырышлыгын да таный. Бу исә, кеше – тәкъдирне гамәлгә куюда Аллаһның илчесе, дигәнне аңлата. Милләткә йөкләнгән тәкъдири миссияне үтәүгә карата да ул нәкъ шулай. Шуңа күрә татарда «Язмыштан узмыш юк» дигән мәкаль яши дә.

Шунысын да искәртеп үтик, язмадагы әлеге фикри бәйләнеш вә нәтиҗәләр татар иҗтимагый аңы өчен яңалык түгел. Милләтнең фидакяр улы Рашат Сафин үзенең татар язмышына геосәяси, эзотерик һәм метафизик анализ нигезендә язылган фундаменталь хезмәтләрендә аларны инде күп еллар элек һәм бөтен нечкәлекләре белән аңлатты. Шәхеснең зурлыгы вә таланты, әнә шулай, милләт һәм кешелекнең киләчәген кайгыртып, алдан фикер йөртә һәм дөрес нәтиҗәләр ясый белүендә күренәдер дә (әлеге юллар аның рухына бер дога булып барып ирешсен!). Хактыр ки, Р.Сафин хезмәтләре, татар язмышы өчен генә түгел, башка халыклар һәм кешелекнең киләчәге җәһәтеннән дә бик мөһим. Шуңа күрә алар милләт, ил һәм кешелек язмышына битараф булмаган һәр татарның өстәл китабы булырга, димәк, зур тираж белән кабаттан да бастырып чыгарылырга тиеш. Ә бүген аның фикерләре бигрәк тә актуаль яңгырый. Әйтик, табигый мөмкинлекләребезне милләт файдасына җигә алмауның төп сәбәбен ул иҗтимагый фикерләүдә татарүзәклек булмауда (татарны үзәккә куеп фикер йөртергә өйрәнмәвебездән) күрә. Ә инде татарга йөкләнгән тәкъдири миссияне үтәүгә килгәндә, аның Гыймран нәселеннән булуын да истә тотып, милләт аксакалы иң әүвәл, ияреп баручылар рәтеннән чыгып, ияртүчеләр рәтендә фикерле башларга киңәш итә, татар милли хәрәкәтенең стратегик кыйбласын да билгели.

Әйе, татар өчен бүген язмыш сынавының хәлиткеч мизгеле – халыклар арасында нәбилек хезмәтенә керешү вакыты җитте. Ә Раббыбыз: «Беркемгә дә көче җитмәгән кадәр вазифа йөкләмибез», – ди (Коръән, 7:42). Хәерле сәгатьтә булсын!

Фоат УРАЗАЙ.

«Тантана» хәйран калдырды

Быел «Тантана» премиясен тапшыру беренче тапкыр Чаллы театры сәхнәсендә узды. Тәбрикләү тантанасы күп шатлыклы мизгелләр бүләк итте, шул ук вакытта бераз сораулар да тудырды. «Әлмәт театрының «Җил артыннан» спектакленең иң шәп тамаша төрендә җиңү ялавы берәүгә дә канәгатьсезлек уятмады, әлбәттә. Иң шәп ансамбль номинациясендә Әтнә театрының «Алмачуар» спектаклен иҗат иткән артистларның бүләк алуы да күңелдә сөенеч кенә уятты. Танылган артистыбыз Равил Шәрәфиевнең күп еллык тугры иҗаты өчен намус һәм дәрәҗә төрендә бүләкләнүенә кем генә шатланмас икән?! Шагыйрә, яшьләр театр проектларының актив катнашучысы Йолдыз Миңнуллинаның да иҗат фасылындагы казанышларын билгеләп үтүләренә ике куллап риза. Иң яхшы музыкаль спектакль төрендә М.Җәлил театрының «Спящая красавица» балеты өчен бүләк бирелү берәүгә дә гаҗәп түгел. Татар композиторларының әсәрләреннән торган музыкаль театр булса исә опера һәм балет жанрларының ел саен беренчелеккә чыкмавы да ихтимал. «Әкият» курчак театрының «Адәмнәр»ендә уйнаган Дилүс Хуҗахмәтов һәм Альбина Шагалиеваны «Тантана» җиңүчеләре арасында күрү дә сөенечле. Фәрхәт Мөхәммәтҗановның Тинчурин театрында куелган «Ядәч! Исемдә! Бер гаилә трагикомедиясе» спектаклендә тәүге роле дә бик уңышлы булды, шуңа күрә егетнең дебют төрендә җиңүе гаҗәпләндермәде. Буа театрының иҗаты ел үсәсен ай үсүе шулай ук шатландыра. Буаларның «Шобага» спектакле, мәсәлән, карап туймаслык. Бу юлы «Никах» дип исемләнгән тамашалары өчен Татарстан Мәдәният министрлыгының махсус бүләгенә ия булдылар. Әлмәт театрының «Ул әле өйләнмәгән иде» спектакле сәхнәдән беренче тапкыр яңгырады – беренчесе – иң шәп ир-ат роле өчен Айрат Мифтаховны бүләкләгәндә, тагын берсе – эпизодик роль башкарган Динар Хөснетдиновны тәбрикләгәндә. Минзәлә театрының «Сөясеңме, сөймисеңме?» спектаклендә Фатыйма роле фестиваль жюриенең күңеленә кереп калган, юкса аны башкарган Динара Акматованы «Тантана» премиясе белән бүләкләмәсләр иде.

Балалар өчен иң шәп спектакль төрендә «Камыр батыр»ның җиңүе исә аяз көнне яшен суккандай яңгырады. Моннан беренче ел элек Кариев театрының иҗат төркеме «Кролик Эдвардның гаҗәеп сәяхәте» өчен премия алган мизгел күз алдына килде. Балалар күңеленә миһербанлык иңдергән куянкайның җиңүенә әй шатланган идек. Санаулы еллар эчендә жюриенең таләпләре шулай кискен үзгәрер дип кем уйлаган? Анык фикере, кыйбласы булмаган, мәгънәсез тамашаны иң яхшы дип билгеләүчеләре шуннан да яхшыракны тапмаганнан түгел ләбаса. Рус яшь тамашачы театрының «Иваново детство», мәсәлән, менә дигән спектакль. Сугышны бала күзлегеннән ача, бу тема белән бәйле ялган пафосны юкка чыгара торган бүген дә бик актуаль тамашаны тын да алмыйча карыйсың. Театр белгечләре мәгънәсез күңел ачуга корылган спектакльләрне җитди темалардан өстенрәк куя икән, гап-гади тамашачылардан, балалардан ни көтәргә кала?!

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мөгаллимнәр бәйгесенә йомгак

Казанның «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә 2022 елда Татарстанның иң яхшы укытучысын игълан иттеләр. Җиңүгә Казан шәһәре Мәскәү районының 2 нче лицей-интернатының тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы Илсур Зиһаншин иреште.

Өч сайлап алу этабыннан торган «Ел укытучысы» бәйгесендә Татарстаннан 146 укытучы катнашкан. Конкурсантлар мастер-класс, ачык дәрес, сыйныф сәгатьләре уздырган, методик остаханәсе белән таныштырган, «Ел укытучысына сорау» матбугат конференциясендә катнашкан.

Илсур Җиһаншин җиңүдән бәхет хисләре кичерүе белән уртаклашты. «Бу атна тормышымда иң яхшы атналарның берсе булды. Бервакыт хезмәттәшем «син булдыра аласың бит моны, катнашып кара» дип тәкъдим итте, шуннан тәвәккәлләдем. Аннары ризалашканыма күп тапкыр үкенеп тә куйдым, ләкин бу адымым юкка булмаган икән. Россиянең иң бәхетле субъектын федераль дәрәҗәдә тәкъдим итәргә хыялланам», – диде абсолют җиңүче.

«Иң оста, максатларына ирешә белүче укытучыларны Россия күләмендә бәйгеләрдә катнаштыру – безнең төп бурычыбыз. «Ел укытучысы-2022» бәйгесе 16 декабрьдә башланды, дүрт ай мәктәптә, районда, шәһәрдә, зоналарда булды. Биш укытучыны соңгы сынауда карадык, алар искитәрлек, шулкадәр тырыш, аларны тапшырулар алып барырга куярлык, бик сөендерделәр. Яшьләрнең күп булуы да рәхәт», – диде мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин журналистларга.

Министр калган номинацияләрне дә исәпкә алып, һөнәри бәйгедә быел 800 дән артык укытучы катнашканын әйтте. «Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» номинациясендә 11 төбәктән, республиканың 15 районыннан барлыгы 32 укытучы көч сынашкан. Җиңүгә Башкортстанның Уфа районы Михайловка урта мәктәбе укытучысы Динара Харисова, Казанның 116 нчы лицееның татар теле укытучысы Зилә Габдинова иреште. Икенче урында – Түбән өлкәсе Вагай районы Заречье урта мәктәбе укытучысы Венера Ибукова, Яр Чаллының 12 нче урта мәктәбе мөгаллиме Силүзә Вахитова.

Җиңүчеләргә 150 мең сум күләмендә акчалата бүләк тапшырыла. Икенче урын ияләре 100 мең сум, өченче урын ияләре 70 шәр мең сумга лаек. Лауреатлар 25 шәр мең сум, номинантлар 10шар мең сум алачак.

«Ел тәрбиячесе-2022» республика конкурсында җиңүгә Казанның Яңа Савин районы 397 нче балалар бакчасының бала үсеше үзәге логопеды Рената Хәбибуллина лаек булды.

Химия укытучылары ассоциациясе рәисе, «Россиядә ел укытучысы» конкурсының жюри әгъзасы Людмила Левина Татарстан конкурсантларына зур соклануын белдерде. «Татарстан бәйгесенең финалында катнашкан укытучылар бер шиксез Россиянең иң яхшы унбиш укытучысы исемлегенә керергә лаеклы», – дип бәяләде.

Гөлнар ГАРИФУЛЛИНА.

1 нче биттә – Язучы Факил Сафин «Намус һәм дәрәҗә» номинациясендә «Тантана» театр премиясен Татарстанның халык артисты Равил Шәрәфиевкә тапшырды. **Салават Камалетдинов** фотосы. «Татар-информ».

Мәдәният киләчәккә йөз тотарга тиеш

Казан Ратушасында Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать советы утырышы узды. Аның эшендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россия Дәүләт Думасының Мәдәният комитеты рәисе Елена Ямпольская катнашты. Чара башланыр алдыннан Р.Миңнеханов республика мәдәният министры Ирада Әюпова белән бергә татар музыка кораллары күргәзмәсен карады.

Татарстан Президенты ассызыклаганча, бүген Россия Көнбатыш ягыннан гаять зур басым кичерә. Көн саен мәгълүмати һөҗүмнәр бара. Һәм илебезне, һәм халыкны чагылдыручы ялган мәгълүмат тарату практикасы көчәя. «Дәүләтебезне, бәйсезлегебезне, гореф-гадәтләребезгә һәм рухиятебезгә таянып, тормышка хокукны саклап калу өчен без бердәм булырга тиеш. Россия һәрвакыт мәдәни традицияләре белән көчле иде. 2022 ел Россия Президенты тарафыннан Россия халыкларының Мәдәни мирасы елы дип игълан ителүе дә символик мәгънәгә ия», – диде Р.Миңнеханов.

Ул бүгенге көндә матди булмаган мирасны: гореф-гадәтләрне, милли кухняны, фольклорны саклау һәм куллану мәсьәләләрен җайга сала торган бердәм федераль закон юклыгына игътибар итте. Элегрәк Татарстан Дәүләт Советы Дәүләт Думасына «Матди булмаган мәдәни мирас турында» закон проектын җибәргән иде. Хәзер ул фикер алышу стадиясендә.

Р. Миңнеханов сүзләренчә, гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар тудырыга аерым игътибар бирелә. Ул билгеләп үткәнчә, балаларда зур белем багажы булу уңыш гарантиясе булып тормый. Креатив фикерләүне һәм идеяләрне генерацияләү сәләтен үстерергә мөмкинлек бирә торган инструментларның берсе – иҗат һәм мәдәниятнең бер-берсенә кушылуы.

«Традицион мәдәният белән танышу, халык бәйрәмнәрендә катнашу, милли театрларга бару – күпкырлы шәхес тәрбияләү гаранты. Кызганычка, яшь буын мәдәният учреждениеләренә йөрергә күнекмәгән, аларның кыйммәтләре системасында мәдәни байлыкларны куллану – беренче урында түгел. Былтыр 1 сентябрьдә старт алган «Пушкин картасы» проекты бу мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерелгән иде. Сезнең хезмәтегез нәтиҗәсендә, проектны гамәлгә ашыруның беренче елы нәтиҗәләре күрсәткәнчә, без сатылган билетлар саны буенча илдә беренче урында торабыз. Бу эшне Пушкин картасының яшь кысалары белән генә чикләнмичә дәвам итәргә кирәк», – диде Татарстан Президенты.

Р. Миңнеханов билгеләп үткәнчә, бүген мәдәният учреждениеләренең күп өлеше, бигрәк тә авыл җирлекләре, кардиналь модернизация таләп итә. Әмма инфраструктураны яңарту – бердәнбер проблема түгел. Яңа технологияләр кертү белән мәгълүмати агымнар киңәя, мәдәни тәңгәллек үсә.

«Мәдәният учреждениеләре заманча эчтәлекле, төрле яшьтәге һәм төрле мәнфәгатьләрдәге кешеләрне җәлеп итәрлек булырга тиеш. Алар төрле яшьтәге кешеләр өчен гаилә ял итү үзәгенә әйләнергә тиеш. Кешеләр үзләренең иҗади сәләтләрен ача һәм күрсәтә ала. Бу мәсьәләдә дәүләт-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашыру өчен зур потенциал бар. Бергәләп механизмнар эшләргә кирәк», – диде Татарстан Президенты. Ул искә төшергәнчә, «Россиядә уйлап табылган» стратегик инициативасы кысаларында быел беренче тапкыр Казан сәнгать училищесы базасында Фешин креатив индустрияләр мәктәбе ачыла. Бу – 12-17 яшьлек яшүсмерләр өчен иҗади сәләтләрен, дизайн-фикерләүне үстерүгә, аларның шәхси ресурсларын активлаштыруга юнәлдерелгән яңа киңлек.

Утырыш барышында мәдәни мирасны саклау, 2030 елга кадәрге чорга республика мәдәниятен үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру, шулай ук мәгарифне үстерү һәм кадрлар әзерләү мәсьәләләре буенча фикер алыштылар.

Белоруссиядә татарча радио

«Хозур» нәшрият йорты «Беларусь мөселман дини берләшмәсе»нең радио-каналын булдырырга ярдәм итте һәм шушы көннәрдә Белоруссия мөселманнары өчен «На волне веры» радиоканалы эшли башлады.

Беларусь мөселман дини берләшмәсе белән хезмәттәшлек турында төзелгән килешү нигезендә, «Азан» радиосы үз тапшыруларын «На волне веры» радиоканалында яңгырату өчен тапшырды.

Беренчеләрдән булып Белоруссиядә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның вәгазьләре, намаз уку дәресләре эфирга чыкты һәм радиотыңлаучылар тарафыннан бик яратып кабул ителде.

«Беларусь Республикасы мөселман дини берләшмәсе»нә бүгенге көндә «Хозур» нәшрияты эшләп чыгарган ислам тарихы, дин нигезләре, ислам әхлагы, гаилә кыйммәтләренә багышланган тапшырулар бирелә – аларның гомуми хронометражы 68 сәгатьне тәшкил итә.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Белоруссия мөфтие Әбу-Бәкер Шабанович белән нелыкны багланышта тора, дини оешмалар үзара уңышлы хезмәттәшлек алып бара.

2019 елда мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Татарстан Президенты катнашындагы рәсми делегациянең Минскига сәфәре барышында Беларусь татарларына нәзарәт әзерләгән Коръәнне, «Калям Шариф. Перевод смыслов» басмасын һәм аның электрон файлларын тапшырган иде.

Нәтиҗәдә, Коръән затлы тышлык белән Белоруссиядә дөнья күрде, аны хәтта Беларусь Республикасы Президенты Александр Лукашенко Мисыр башлыгы Абдель Фәттах әс-Сисига бүләк итеп бирде.

Театрның йөзек кашлары иде

Халыкара театр көне алдыннан Татарстанның халык артистлары Исламия һәм Хәлил Мәхмүтовлар яшәгән йорт диварында аларга багышланган истәлек тактасын тантаналы ачу булды.

Исламия һәм Хәлил Мәхмүтовлар – татар театры тарихында зур эз калдырган, сәхнә сәнгатенең йөзек кашы булган артистлар. Алар 50 елдан артык гомерләрен Кәрим Тинчурин театрына багышладылар һәм халык мәхәббәтен яулаган образлар иҗат иттеләр.

Халкыбыз И.Мәхмүтованы – киңкырлы иҗат әһеле буларак та белә. Ул, талантлы артист булуы, бихисап образлар тудыруы белән бергә, режиссер да, драматург та, тәрҗемәче дә. Исламия ханым 1991-1992 елларда театрның сәнгать җитәкчесе була. Режиссер вазифасында Данил Салиховның «Яшьлек хатам, йөрәк ярам», Наил Гаетбайның «Аты барның – дәрте бар», Рәдиф Сәгъдинең «Сынган беләзек» һ.б. әсәрләрне сәхнәләштерә, «Мәхәббәт чишмәсе», «Күрәсем килгән иде» һәм «Син бит минем бергенәм» пьесаларын яза, Б.Брехтның «Кураж ана һәм аның балалары» әсәрен татарчага тәрҗемә итә, телефильмнарда катнаша. Спектакльләрнең кайберләре бүген дә театр сәхнәсендә гөрләп бара. Шул ук вакытта И.Мәхмүтованы татар җырларын оста башкаручы буларак та беләбез. Хәлил Мәхмүтов халык хәтерендә К.Гольдониның «Ике хуҗаның хезмәтчесе»ндә – Флориндо, Шекспирның «Юктан чыккан гауга»сында – Бенедикт кебек классик рольләрне югары осталык белән башкаручы буларак та кереп калды. Мәшһүр гаилә династиясен хәзер театрда кызлары Лилия Мәхмүтова белән кияүләре Ренат Шәмсетдинов дәвам итә.

Мемориаль тактаны ачу тантанасында Татарстан Премьер-министр урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразиев халкыбызның һәрвакыт театрлы булуын искәртеп, анда хезмәт куйган артистларыбызның исемнәре мәңгеләштерелергә тиешлеген искәртте. К.Тинчурин театры бу юнәлештә әһәмиятле эшләр башкара. Мәхмүтовлар дуслары, хезмәттәшләре хәтерендә кунакчыл, якты кешеләр буларак та кереп калган. «Алар яшәгән фатирга адәм балаларының юлы өзелмәде. Һәр көнне кеше килә иде», – диде Мәхмүтовлар белән күршеләр булып яшәгән Әзһәр Шакиров. Мемориаль тактаны ачу тантанасында шулай ук Татарстан Президенты каршындагы мәдәниятне үстерүгә ярдәм фондының Башкарма директоры Нурия Хашимова, Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова, Исламия Мәхмүтованың сеңлесе Рузия Мотыйгуллина белән кияве Ринат Закиров, Әлки районы якташлар җәмгыяте җитәкчесе Алсу Нәбиева, язучылар, артистлар һ.б. чыгыш ясады. Артистларның кызлары Лилия һәм Ләйсән Мәхмүтовалар истәлек тактасы куюгә тәкъдиме белән чыккан депутатларга, әлеге эшне хуплаган Татарстан Хөкүмәтенә, истәлек тактасы авторы – рәссам Рөстәм Габбасовка һ.б. рәхмәт әйтте.

Сөембикә КАШАПОВА.

● Таиландта, дөге кырларын әкәм-төкәм һәм башка корткычлардан чистартыр өчен, аларга меңләгән үрдәкне куып кертәләр һәм ай буена шунда йөртәләр.

● Җирдәге иң зур хайван – озынлыгы 25-30 метрлы, авырлыгы 130-150 тонналы зәңгәр кит бер йотканда 35 мең литр диңгез суын йота. Каны – 8 мең литрдан артык, теле – 4 тонна чамасы. Минутына 4 тапкыр сулыш ала. Уртача гомер озынлыгы – 40-90 ел. Кит 500 метр тирәнлеккә чумып, анда 50 минут буе торырга сәләтле. Тәүлегенә уртача тонна ярым ризык – планктон һәм криль белән туклана. 6-8 метрлы, 2-3 тонналы булып туган баласы тәүлегенә 90 литр сөт имә. Кит мае һәм мыегына кызыгып, барлыгы 380 мең хайван үтерелгән, Халыкара комиссия 1966 елдан гына кит аулауны тыйган.

● Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә былтыр җәй ясалма яңгырны химик кушылмалардан файдаланмыйча яудыру технологиясе сыналган: моның өчен болытларга дроннар җибәрелгән. Әмма табигать болай тыкшынуны да яратмый – бик көчле яңгыр туктаусыз явып, су басу ихтималы арта.

● Рафаил Закиров.

● Рәфкать Ризатдинов.

● Мансур Хәкимов.

Үгисетелгән хәрбиләр

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

1984 елда Варшава Килешүенә керүче илләрнең Стратегик максатлардагы Көньяк-Көнбатыш юнәлештәге гаскәрләре Башкомандующиенең беренче урынбасары вазифасына билгеләнә. Генерал-лейтенант Р.Ризатдинов – Румыния, Болгария, Венгрия гаскәрләре, Чехословакиянең бер армия корпусы, Одесса һәм Киев хәрби округлары, Совет гаскәрләренең Көньяк төркеме, Үзәк төркемнең бер армия корпусы, Кара диңгез хәрби флоты, Украинадагы ПВО гаскәрләре һәм стратегик максатлардагы бомбардировщиклар армияләре тупланган ифрат дәрәҗәдә куәтле көчкә ия хәрби төркемдә шундый вазифа биләүче бердәнбер татар генералы. Совет чорында, башкалары кебек үк, Стратегик максатлардагы Көньяк-Көнбатыш юнәлештәге гаскәрләр турындагы мәгълүматлар сер итеп саклана. Фәкать социалистик илләр лагере таркалып, Варшава Килешүе гамәлдән чыккач һәм СССР дәүләте таралгач кына, ул хәрби сер булудан туктый.

Берничә дәүләтнең армия корпуслары, Советлар Союзының ике хәрби округы, Украинадагы Һава һөҗүменнән саклану көчләре, Кара диңгез флоты h.б. берләшмәләр тупланган стратегик максатлардагы Көньяк-Көнбатыш юнәлеш гаскәрләре Башкомандующиенең беренче урынбасарының вазифасы нидән гыйбарәт булган? Беренче чиратта, генерал-лейтенант Р.Ризатдинов гаскәрләрне хәрби-техник яктан заманча коралландыру өчен җавап бирә. Тик шунысы бар: аннан аермалы буларак, башка стратегик максатлардагы юнәлешләр гаскәрләрендәге Башкомандующийларның беренче урынбасарлары фәкать генерал-полковник погоннарын йөртә. Ни өчен мондый гаделсезлек хөкем сөргән соң? Хәләл җефете Ләлә белән Роберт һәм Марат исемле уллар үстергән Р.Ризатдинов Казанга кунакка кайткач, аны якыннан яхшы белүче күренекле журналист, татар генераллары һәм адмираллары турындагы язмалары белән абруй казанган Нургали Булатов моның сәбәбе белән кызыксына. Нургали аганың “Йолдызлы йолдызлар” китабында расланганча, генералның җавабы кыска һәм кырыс:

“Мөгаен, моңа татарлыгым аяк чалгандыр. Минем хәрби званиемне күтәрүләрен сорап югары инстанцияләргә берничә тапкыр үтенеч киткәнен беләм. Мәскәүдәге дусларымның шалтыратып, син генерал-полковник хәзер дип котлаганнары да булды. Әмма Саклану министрлыгыннан андый боерык килеп ирешмәде”.

Сугыш тәмамланып күп еллар узгач, Алманиядәге Совет гаскәрләре төркемендә шактый ук гыйбрәтле вакыйга төенләнә һәм ул турыда әйтмичә калып булмый. Бу вакыйганы Казан егете, МЧСның авиация һәм авиацион-коткару технологияләре идарәсе башлыгы генерал-лейтенант Рафаил Шәкүр улы Закиров Мәскәүдәге “Татар хәбәрләре” газетасы хәбәрчесе Нәзифә Кәримовага биргән әңгәмәсендә бәян итә:

“Авиация училищелары, аеруча вертолётчылар әзерли торганнары, татарлар күпләп яши торган Идел буе төбәкләрендә урнашкан иде. Аларда бик күп татар егетләре укыды һәм, мөгаен, шул сәбәпледер, мин беркайчан да “татарин” дип кимсетеп әйткәннәрен ишетмәдем. Әмма бер очрак хәтердә уелып калды. Ул чакта мин Алманиядә хезмәт итә идем. Андагы ике вертолёт полкы белән татарлар командалык итте. Берсе белән – мин, икенчесе белән – полковник Марсель Бигеев, шулай ук безнең якташ, Арчаныкы. Ә монда, тагын бер полкның командиры итеп шулай ук татар милләтеннән булган Мөхәммәтҗановны билгеләү турында тәкъдим алына. Әмма хәрби совет Мөхәммәтҗановны раслаудан баш тарта. Шуңа җавап җәһәтеннән, командирлары Александр Кошелёв Мөхәммәтҗановны үткәрү өчен тыреша башлагач, сәяси идарәсе башлыгы аңа әйтә: “Сез нәрсә, Кошелёв, үз акылыгыздамы? Алманиядәге биш вертолёт полкының өчесе белән татарлар командалык итүен телисезме!?” Әмма Кошелёв үз дигәненә ирешә – Мөхәммәтҗановны өченче полк командиры итеп билгелиләр. <…> Менә шулай бер заман, Алманиядәге биш вертолёт полкының өчесе белән өч татар командалык иттек”.

Хәер, милләтне данлау өчен Казан каласында туган милләт баласы – Татарстан өчен дә ят һәм үги. Әнә ич, Татар энциклопедиясендә аның турында мәгълүмат биреп мәшәкатьләнмәгәннәр, ике силикат кирпеч авырлыгындагы “Татарстан генераллары” белешмәсен нәшер итүчеләр дә татар башкаласында туган генерал-лейтенант Р.Закировны саллы хезмәткә лаек дип тапмаган. Башка милләтләрдә күрелмәгән мондый мәнсезлекне аңлап та, кабул итеп тә булмый. Югыйсә, Рафаил Шәкүр улы мактаулы тормыш юлын үтә, ул Сәйдә исемле кыз белән милли гаилә кора һәм Руслан, Ратмир атлы малайлар тәрбияләп үстерә. Сызрань Югары хәрби авиация училищесын тәмамлый һәм Төркестан хәрби округында, 162 нче аерым вертолетчылар полкы командиры урынбасары вазифасына билгеләнә. Аннары биш ел дәвамында Алманиядәге Совет гаскәрләре төркемендә 225 нче вертолетчылар полкы командиры урынбасары һәм командиры булып хезмәт итә. Ю.Гагарин исемендәге Хәрби һава академиясен тәмамлагannan соң, Коры җир гаскәрләре авиациясе командующиенең хәрби әзерлек идарәсе башлыгы урынбасары дәрәҗәсенә ирешә. 1996 елдан – РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы авиациясе башлыгы, 2004 елдан – министр ярдәмчесе. РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының авиациясен оештырган якташ 2014 елдан Генштаб башлыгының киңәшчесе итеп билгеләнә. Кызыл Йолдыз, “Хәрби уңышлары өчен” һәм “Батырлык” орденнары кавалеры генерал-лейтенант Р.Закиров 72 яшендә, 2020 елның 18 июлендә вафат була.

Илдәге интернационализмның чынбарлыктагы чагылышын раслау өчен янә бер мисал. 2007 елның июнь аенда «Звезда Поволжья» газетасында Лилия Шейферның Бөек Ватан сугышы башланган беренче көннәрдә Брест кирмәнен дошманнан саклаганда күрсәткән батырлыклары өчен, фәкать 1956 елда гына Советлар Союзы Герое исеме белән бүләкләнгән татар халкының каһарман улы, полк командиры майор Петр Гавриловка багышланган “Брест кирмәнендә утыз көн” дигән гаять кызыклы мәкаләсе чыкты. Совет чорында шовинизмның ни дәрәҗәгә җитүен ачыклау өчен шуннан бер өземтә китерик. Бөек Җиңүнең 30 еллыгы алдыннан майор Гаврилов Үзәк телевидениегә килә һәм сугышта кичергәннәрен бәян итә. Әсәрендә диктор ханым: “Фәкать рус кешесе генә Брест кирмәнен саклауны оештыра, ул гына бөтен җәһәннәм авырлыкларын үтеп, хәрби антына тугрылык саклый ала”, – дип белдерә. Петр Гаврилов исә тыйнак кына: “Мин рус түгел, мин – татар!” – дип җавап бирә. Шуннан соң аны Үзәк телевидениегә башкача чакырмыйлар.

Рәис ЗАРИПОВ.

Атнаның сәяси мизгелләре

ЯРТЫ ДӨРЕСЛЕК ЯЛГАНГА ТИҢ

Мәскәүнең энергия ресурслары өчен түләүне партнерларыннан “рубль”ләрдә таләп итүен соңгылары килешү шартларын бозу дип бәяләде. Шуңа күрә, әйтик, “зур җиделек” (G7) илләре (АКШ, Алмания, Бөекбритания, Италия, Канада, Франция һәм Япония) андый түләүдән баш тартты. Кремль моңа газ куыны туктату мөмкинлеген искәртеп җавап бирде. G7 илләре нефть һәм газ сата торган дәүләтләрне аларның күләмен арттырырга чакырды. Узган атнада АКШ һәм Бөекбритания Россиягә каршы тагын яңа санкцияләр кертте. Башка чикләүләр дә булды. Әйтик, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең суверен фонды Россиягә инвестицияләрен туктатуын белдерде. С.Лавров Көнбатышны Россиягә каршы чып-чын гибридлы сугыш игълан итүдә гаепләде. Россия Үзәк банкы, бер айга сузылган тәнәфестән соң, Мәскәү биржасында акцияләр сату эшен яңартты. Финанс министры А.Силуанов Россиянең үз тышкы әҗәтләре буенча вәгъдәләрен үти алуы турында әйтте. БМО Генераль Ассамблеясе Украинадагы гуманитар хәл буенча резолюция кабул итте.

РФ Генпрокуратурасы Украина президенты В.Зеленскийның Россия мәгълүмат чараларына биргән интервьюсында әйткәннәренең эчтәлеге һәм аларны бастырып чыгару факты буенча хокукый бәя бирергә җыена. Ә аңа кадәр “Роскомнадзор” ул әңгәмәдә катнашкан мәгълүмат чараларын интервьюны бастырмаска кирәклеге турында кисәткән булган. Хәзер инде ул басмаларга карата тикшерү эшләре башланган. Узган атнада, шул ук “Роскомнадзор” кисәтүе буенча, “Новая газета” да эшен туктатырга мәҗбүр булган. Юкса, илдә бүген “хәрби хәл” режимы да кертелмәгән. Шулай булгач, мондый хокукый кырыслыкны ничек аңларга? Дөреслек кемне һәм ни өчен куркыта? Ә ярым-йорты дөреслек ул, мәгълүм булганча, ялганга тиң. РФ Генштабы 25 мартка илнең 1351 хәрби хезмәткәре һәлак булуы, 3825е яралануы турында хәбәр итте. Менә шундый шартларда Россия һәм Украина делегацияләре бу атнада күзгә-күз сөйләшүләрен яңартты.

Фоат УРАЗАЙ.

ТӘҢРЕ ТАМГАСЫ

Тамырларга асылынып мендем ярга:
Саумы, ата-бабалардан калган атау!

Ләис Зөлкарнәйнең 1986 елда язылган «Җилкәнле утрау» шигыреннән бу юллар. Шагыйрьнең 2021 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Узганны кабатлау» җыентыгын укыгач, кабат шушы тезмәләр хәтердә яңара. Чөнки әлеге җыентыкка тупланган гаҗәеп әсәрләр бер фикергә китерә: шагыйрь – шигърияттә меңнәр эзләгән, эзли торган «ата-бабалардан калган атау»ны тапкан! Ул атауга, хисләрне сихерләүче шигъри мәйданга ике юл – тарих һәм сәнгать тамырлары юнәлтә ала икән.

Җыентыктагы «Тамырсызлар» шигыре, әйтерсең үзәккә куелган фәлсәфәнең сорау өлеше булып килә. Л.Зөлкарнәй тергезгән дөнья сурәтендә агачларны-имәннәрне борчыган: « – Тамырсыз алар ничек яши икән?.. / – Алар ничек яши икән... / Тамырсыз?!» дигән сорау кешегә, кешелеккә юнәлтелгән булып аңлашыла. Шагыйрь исә үзенең әсәрләрендә кешелек тамырларының, милли-этник тамырларның барлыгын расларга алына.

Җыентыкта тудырылган дөнья сурәтендә иң мөһиме – тарихи тамырлар. Күпчелек текстлар төрки-татар тарихының аерым сәхифәләрен, шәхесләрен, вакыйгаларны тергезә, аларны шәрехли, бүгенге югарылыктан бәяли. Әмма алар – төрлесе төрле вакытка юнәлә. Әйтик, «Идегәй» шигыре бүгенге җәмгыятьнең бер вәкиле – лирик герой исеменнән «күчмәнлекнең» җаннан китмәгәнлеге турында сөйли. Шагыйрь сурәтләгән күчмәнлек – күңелнең еракларга алгысынуы да, ашыгып-ашкынып, иркенлеккә күңенгә чикләргә сыймыйча, сынып-сыдырылып яшәү дә («Һаман күчмән минем җаным, - / Борынгыда кыпчаклар сыман / Борылганда, / Көпчәкләр сына....»), ирекккә омтылыш та. Шушы өч сыйфат укучыны да үз милли менталитеты, үзаңы турында уйланырга мәҗбүр итәрлек.

Аерым бер текстларда тарихи өстәлмә – тарихи хәтернең уяну билгесе («Күчмә учаклар»), кайчак тарих сурәте бүгенгедән торып татар халкына, аның күп мәдәниятләрне һәм этносларны синтезлаган асылына бәя булып яңгырый («Атланмай»).

Әмма иң кызыклы шигырьләр – табигатьне, дөньяны тарихи хәтерен яңартып яшәүче лирик герой күзлегеннән бәяләү: «Җәй уртасы – Саратан», «Соңгы адым», «Торымтай», «Тәнге яңгыр», «Хан капкасы ышыгы» һ.б. Мондый текстларда бүгенге сурәт – бик еракта калган күренеш белән тоташа. Матур, тәэсирле табигать сурәте үзгә эчтәлек ала – бер заманда да югалмый торган мәгънәләр хасил була. Мәсәлән, «Тугра чигә тургай» шигырендә лирик герой җете кояш астында бер күтәрелеп, бер түбәнәеп сайраган тургайның хәрәкәтен – тугра-байрак чигүгә охшата, бу чигүнең бизәкләрен исә арыш арасындагы чәчәкләрдә күрә. «Тәңре тамгасы – / күккүзләр чигә...» дигән соңгы тезмә матурлыкның – табынырлык илаһият билгесе булуын да искәртә, тугра лексемасы белән янәшә, ерак тарихи эчтәлеккә юл күрсәтә, башка укылыш булу мөмкинлегенә дә ишарәли.

Еш кына шагыйрь тарихи хәтерне үзенчәлекле символ ярдәмендә бүгенгегә тоташтыра. Тарихи эчтәлекне исә һәр очракта диярлек сайланган эпиграф тирәнәйтеп килә. Мисалга, «Нух көймәсе» шигырендә (автор аның жанрын притча дип билгеләгән, асылда ул фәлсәфи шигырьгә, шәркый шигъриятттәге кыйтга жанрына туры килә) ай символы шундыйлардан. Айны Нух көймәсенә охшату аның бер – идеалның кешелекне коткаруы мәгънәсен калкуландыра. Нух көймәсе – күктә, җирдә өрәкләр генә яши, диюче шагыйрь ай символының башка билгеле мәгънәләрен дә текстта табарлык мөмкинлек калдыра.

Әмма иң тәэсирлесе – әдәби тамырларны барлау, сәнгать хәтерен уяту. Шагыйрьнең күп кенә текстлары – ниндидер борынгы жанрны тергезү булып тоела. Алар арасында дала сәнгатеннән – чичән җыруын стильләштерүләр бар. Әйтик, каен исеменнән әйтеш («Балта чабылган каен») камлаучы тәкрарлаган мәҗүси бер сурәт булып калка. «Акын» – борынгы җырау формасында, әмма мәгънәсе тирән: «Иләткә аҗау тергездең, / Идел-йортың сарыкканчы...» дип, җыраучы-герой Алтын Урданың язмышында эпиграфта сылтама ясалган җырау-шагыйрьләр дә роль уйнаганны искәртә. Әмма Алтын Урданың Идел-йортны көчсезләндерү хисабына күтәрелүе фикере, әйтелсә дә, ахыргача шәрехләнеп бетми (бу очракта, җыраунның ачыклык таләп итүен күздә тотабыз).

Әдәби тамырларны – традицияләрне оста һәм урынлы файдалану җыентыктагы һәр шигырьдә диярлек күренә: аларның иң еш кулланылганы – охшаш яңгырашлы сүзләр тезеп уйнау, яңгыраш көчеше ярдәмендә сүз-сурәт тудыру! Мисалга исеме үк охшаш яңгырашлы сүзләрдән җыйналган «Көртләр төргән төндә» шигырен алыйк. Андагы «Көртлек урманнарын көртләр төргән төндә», «Шүрәлеләр үрелепләр уятмаса» кебек тезмәләр, символик образларның (балан, кызылтүш, шүрәле) мәгънәсен шәрехләмәү белән янәшә, шигырьдә хыялый сурәт тудыра. Әлеге сихри-шигъри сурәт үзенә шулкадәр җәлеп итә, хәтта төп фикердән игътибарны читкә алып китәргә сәләтле! Шул ук вакытта эчтәлекнең мәхәббәт, аның ачы да, татлы да, кузлы-утлы да булуы турында икенен искәртергә теләгәндәй, шагыйрь «Яратуның йөрәк тамгасы – кузлы төш» тезмәсен ике тапкыр кабатлый, әмма яратуның бер объекты гына телгә алына: «Авылларны төштә күрә кызылтүш».

Гади-гадәти генә күренешне әкияти бер рәсем итеп тергезү укучыны сер эзләү процессына тарта. Әйтик, елганың бер мизгелен тасвирлаган «Ык суы» кыска шигырендә табигать рәсеме серле бер табышмакка әйләнә: «Сәүдәгәрләр Шәрык илләреннән / Ефәкләрен алып килде микән, / Сөендереп марҗа коянтәләрен! – / Постау япкан тирән сандыгыннан / Көмеш алып, / Тирләп саный һаман / Чалмалы өянкеләрең...». Бу сурәттә елкылдап торган су өсте, аның өстендә уйнаклаган марҗа коянтәләре (энә каракларны), көмеш дулкыннарда тибрәгән өянкеләр урын алган. Тарихи сүзләр текстны пейзаж шигыре чикләреннән алып чыга – фәлсәфәгә күчерә.

Охшаш яңгырашлы сүзләр белән уйнау күләмле шигырьләрдә укучы игътибарын тотып торучы эмоциональ лейтмотив – үткәндәге матурлыкның югалуына бәйле сагыш хасил итә. Бу бик күп шигырьләрдә шулай. Әлеге сурәт-үкенечкә, сагышка кечкенә утраучыклар булып килеп кушылган бәяләр бүгенге заман, җәмгыять, кеше, милләт хәленә кагылышлы. Шул структурадагы озын шигырьләрнең берсен мисалга китерсәк, «Көмеш таллы тегермән» шигырендәге беренче строфада ук тергезелгән әкияти сурәт текстны буйлап озата бара: «Болындагы ак болытның / Җитен җәймә куләгәсен / Кайчы канат тәкәрлекләр / Өлге-өлге / Теләме соң? / Энә томшык тәкәрлекләр / Капчык телә беләме соң?!»

Шагыйрь укучысына бу сурәтнең үз күңелендә генә яңаруын сиздерә: «Китсә дә су тегермәне, / Шарлавыктан күтәрелгән / Салават күпереннән / Һаман әле чалымлана / Көмеш таллы тегермән!» Шушы сурәткә шагыйрь өчен бүгенге заманга бәя килеп кушыла: «Заманасы җилгәрүсез, - / Иләмтеге өскә чыга! / Ак он чыкмас бу заманнан, / Кубрәк көрпә чыга... / Этә-төртә чыга!». Әмма алар үтешли генә әйтелгән кебек яңгырый. «Артта калмас өчен авыл, / Узганнарын кабатлар...» сүзләре, күрәсең, шигырьнең ахырында сагышлы сурәтне юкка чыгарган өметнең сәбәбе булып килә.

Җыентыктагы «Алтын Урда. Бәян» дип аталган күләмле тарихи текст (ул160 бит тәшкил итә) шигъри повесть жанрына туры килә. Мәгълүм ки, татар әдәбиятында шигъри роман, шигъри повесть жанрлары XX гасырның икенче яртысында популярлашкан иде. Әмма Л.Зөлкарнәй бәяны – үзгә нигезләргә корылган, яңа бер жанрлык хасиятенә ия әсәр, татар шигъриятендә яңалык булып тоела. Бер яктан, бүген әдәбиятыбыз традицион поэма жанрын үзгәртү мөмкинлекләрен барлый. Чөнки 1960-1980 елларда мәйдан тоткан күләмле, чор рухында иҗат ителгән поэмалар бүгенге укучыга, иң беренче чиратта, тарихи факт буларак кызык: заман үзгәрде, укучы үзгәрде, лирик төр жанрлары арасында бу, бигрәк тә, поэмага тәэсир итте. Әмма бүгенгә татар поэмасының кайсы сукмактан китәчәге ачык түгел.

Л.Зөлкарнәй тәкъдим иткән юл – үзенчәлекле, асылда ул – дастан, борынгы эпоска охшатып стильләштерү булып чыккан; борынгы җырау, эпик хикәят кебек тә кабул ителә. Кабатланулар ярдәмендә тудырылган яңгыраш аны магик сихер текстына әверелдерә, ул укучыга хисси дәрәҗәдә, көе-аһәңе белән дә тәэсир итә башлый, текстның тагын бер – эмоциональ эчтәлеге хасил була. Шул ук вакытта, табылган форма татар халкының узганы, бүгенгесе хакында зур иҗтимагый-сәяси фикерләр әйтергә мөмкинлек биргән.

Текст үзе автор тарафыннан 3 бүлеккә – бабка бүленгән. Беренче баб «Сөен Бикә» дип атала һәм исем шунда ук бәян исеме белән каршылыкка керә. Сөембикә – Алтын Урда җимерелгәннән соң хасил булган Казан ханлыгының ханбикәсе! Әмма эчтәлектә шагыйрь Алтын Урда һәм Казан ханлыгының бер өлешен – Нугай йортын, аның тарихын үзәккә куя; Сөембикә һәм ханлык җимерелү фаҗигасенең сәбәпләрен, бигрәк тә, Алтын Урда тарихыннан эзли. Шуңа күрә әсәрне – төрки-татар тарихы, аның аерылгысыз өлеше булган Нугай ханлыгы тарихы турындагы шигъри дастан дип атарга мөмкин булыр иде.

Беренче баб, борынгы җырау аһәненә салып, укучы-тыңлаучысын борынгы күктөркләрнең ана бүре хакындагы риваятьләренә үк алып китә, Сөембикәнең манарадан ташлануы хакындагы легендага китереп ялгый, һәм төркиләр тарихын бер чылбыр итеп тезә: Төрки каһанлык (Ашина) – Дәште кыпчак – Алтын Урда; аларның фаҗигале язмышы – бүре каргышы, әмма Сөембикә – татарларны яңадан туплый алырлык символ дигән сүзләр («Ил-күч жыя / Сөен Бикә! – / Кассиопея») беренче бүлекне тәмамлап куя. Кереш өлеш – тарихи дастаннардагы кебек – тарихи контекстны тергезә.

Икенче баб «Нугай йорты (Садактагы ун кыйсса)» дип атала. Беренче – керештән соң ул төп текст булып аңлашыла. Үзе дә 10 кыйсса-бүлекчәдән җыела; бабны тулысынча укыгач, «садак»-тарихи хәтернең киләчәккә барып җиткән ун укны саклавы күзаллана. Беренче ук – батырлар турындагы хәтер. «Бачман хан» кыйссасы XIII гасырда кыпчак тарихына йөгерә, монголлар басып кергән вакытта илне саклар өчен халкын көрәшкә күтәргән, шул юлда шәһит киткән баһадирны данлый, аңа мәрсия төсен ала. Әйтерсең лә пәһлеваннарының, халык хәтерендә яшәп, үзләре катнашкан тарихи вакыйгаларны да шушы хәтергә беркетүләрен, садактагы ук шикелле, киләчәккә «атуларын» бәян итә.

Кыйсса ахырында табылган символик образ аннан соңгысын башлый: бүлекчәләр үзара шулай ялгана. Әйтик, беренче кыйссаны йомгаклаган «Баскынчак» хронотобы икенче кыйссага исем бирә. Әлеге исемнән соң шагыйрь жанрны билгели: «Борадәрем Фәиз Зөлкарнәй рухына – «салават». Салават – кешелек өчен зур эш эшләгән кешенең исеменә зикер әйтү, ихтирам белдерү, иң беренче чиратта пәйгамбәребезгә кылына торган олы дога; ул Фәизнең үлемен генә түгел, гомумән, көрәшләр тарихы булган татар тарихын, Туктамышның батырларын, Идегәйләрне колачлый, кан коешларда җимерелгән Алтын Урда дәүләтен, Казан, Касыйм, Кырым ханлыкларының егылуын XX гасыр тарихына китереп тоташтыра, шахталарда кырылган милләттәшләренә дә кагылып үтә.

Барлык татар шәһитләренә кылынган гыйбадәт шагыйрьнең бу югалтуларның юкка түгеллегенә, үткәннәр данының кире кайтачагына ышанычы белән тәмамлана («Инде ничә гасыр / Нур сүндерми Нугай Ана, – / Алыплары атта кайтыр.../ Сөенен дә алып кайтыр.../ Атлар кайтты, кайта, кайтыр!»). Димәк, халык хәтере азатлык өчен, халык бәхете өчен гомерләрен биргәннәрнең тарихын онытмый.

(Дәвамы киләсе санда).

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,
филология фәннәре докторы.

ҖИЛКӘНЛЕ УТРАУ

Чыкты җилләр,
Купты тулкын -
Ил корабын җил сөрә!..
Кайсы юллар,
Нинди упкын
Тарта безне җан сорап?!
Дәрдемәнд

Тамырларга асылынып мендем ярга:
Саумы, ата-бабалардан калган атау!
Тау-тау дулкын...
Талдым йөзеп...
Хәл алыймчы... –
Комың булып, һәр күзәнәк ятсын тарау.

Сулар аксын, кояш кучсен, иссен җилләр.
Ә мин ятыйм, ятыйм шулай, кымшанмыйча.
Урталыкта калыйм әле.
Өмет өзим,
Идел кичәр көчләремә ышанмыйча.
Ышанмыйча дәвер кичәр көчләремә
Каләмемә, илһам килгән кичләремә, –
Калыйм синдә...
Онытылыйм...
Монда тып-тын... –
Күтәрергә теләп түгел,
Батырам дип!
Баш калкыткан саен сукты саллы дулкын.
Онытылыйм
Онытылсын дип үткәннәрем.
Тик нигә соң тынгы бирми өянкелек?! –
Өянкеле җилкәннәрдәй шашып шаулый!
Кымшаныплар куя атау, кораб кебек...
Борынгыдан,
Болгарымнан килгән кораб
Комга утрып калган мәллә, утрау булып? –
Өянкеләр давыл даулый!
Китсен өчен
Сәях атау,
Тоткынлыктан кубарылып.

...Кичер, шигырь, мин юләрне
Ялгышканмын,
Синдә икән дәверләрне кичәр көчем.
Тормыш заман комнарына терәлгәндә,
Давыл даула!
Кубарылып китәр өчен...

Әрнүләр бар,
Таш йөрәкне эретерлек,
Язмышларны борып тоткан борчулар бар –
Кубарып ал манкортлыктан хәтерләрне,
Битарафлык сайлыгыннан
Җанны кубар!
Йолдызлар да чут төймәсенә әйләнгәндә,
Бәйләгәндә намус күзен нәфес, җәнҗал –
Кубарып ал максатларны түбәнлектән,
Матурлыкны һәлакәттән Кубарып ал!

Тау-тау дулкын,
Ил – җилкәнле ярсу атау.
Шаула, давыл!
Кузгалырбыз сөенешеп,
Баш калкыткан саен суга саллы дулкын,
Суга, димәк,
Ил күтәрелеп китсен өчен!
1986

ТУЗГАН КҮЛӘГӘМӘ ЕГЫЛГАНДА

Иртәнге сүз кичкә һич ярамый... –
Бакый бер сүз эзлим мин – шашкан.
Кешеләрдән эзлим,
ә кешеләр
Фанилыкка кереп адашкан.
Заманыннан эзлим,
ә заманы
Мордар киткән –
канлы чигәсе...
Бакый бер сүз кирәк!
Аннан башка
Гомер ни йөз белән чикләнсен?

Тузган күләгәмә егылганда,
Эзләүләрдән арып, сулыгып,
Тыны кысылган рух бәргәләнер,
Бакый бер сүз сорап, –
Соңгы сулулык...
1986

БОРЫЛА ДА КАРЫЙ

Кара көздә,
Арагызда
Бардыр аклык тансыклаган;
Котмәгәндә, төн эчендә
Сырлан-сырлан
зыкы сарган –
Зыкылаган карамалар!

Аклык тансыклаган карамалар...
Ыкның кара сулы көзгесенә
карамыйлар,
Тарамыйлар сырлан-сырлан
зыкы сарган
толымнарын,
Көнозын тарамыйлар...
Җилләр дә юк! –
Зыкы сарган толымнарны
Кызыгып тарамыйлар...

Җәйләр буе
Су кызының
Озын чәчен тарый-тарый,
Тараклары да юкарган! –
Ярамыйлар!
Караманың толымнарын
Сырлан-сырлан зыкы сарган, –
Зыкылаган!
Аклык тансыклаган карамалар
Карасу Ык көзгесенә
көнозын
карамыйлар...

Карамалар, карамалар!..
Шау чәчәктә
килеш корган
Алмагачлар бакчасына
Борыла да карый алар...

Шау чәчәкне
килештергән
Алмагачлар бакчасына
Борыла да карый,
Борыла да карый
Карамалар.

ФӘИЗ ЧИШМӘСЕ

Таллы тауда;
Караталда –
Тамырлар...

Талган булсаң,
Табаныңнан
Таныйлар.

Караталда
Абынмаса
Тамырсызлар,

Тамыр сызлар...
Тамыр сызлар...
Тамыр сызлар! –

Таллы тауда
Талымлаша
Талымсызлар,

Су тамыры...
Су тамыры
Сыкырап сызар!

ТАМЫРСЫЗЛАР

– Тамырсыз алар ничек яши икән?..
– Алар ничек яши икән...
Тамырсыз?!

Бер-берсенә имәнгеч сорау биргән
Имәннәрне
Шаулавыннан
Танырсыз...

Саргайтмады салкын җил сарылганын
Сабырсыз
Шомлавыннан
Танырсыз...
– Тамырсыз алар... Ничек яши икән?.
– Алар ничек яши икән...
Тамырсыз?!

Агачлар бер-берсеннән сорый төнлә,
Сорый,
Бер-берсенә
Шом салып...

Ләис ЗӨЛКАРНӘЙ

Урлап китәм сине үз-үзеңнән, Гомер сизелмәс тә, бу төндәй...

КЫШ ЧЕЛЛӘСЕ

(Элегия)

Чикерткәләр төш юрый.
Җ. Сөләйман

Печән белән бергә кайткан чикерткәләр
Кычкырмады...
Алар, әйе,
сайрый иде!

Сандугачны
Төн буена тын калдырып,
Таң атканчы, таң атканчы
Таң калдырып,
Күңелләрнең нечкә җирен
сайлый иде.

Җәйләр үткәч,
Җылы эзләп кергәннәр дә
Ни өчендер үз иткәннәр мич асларын.

Үз урынын тапкан, имеш, –
Үз урманын тапкан алар!
Үз агачын эзләп тапкан –
Табагачын!
Кисәүгачын!..

Чеңләп кипкән чырагачны зеңгелдәтеп,
Алар өйдә
төн буена
сайрый иде!
Тәрәзләрне кыш челләсе бозлаганда,
Җәй эссесен сала-сала,

Җаныбызны
сыйлый иде...
– ... Эс-с-седән
эс-с-се
ни эс-с-се?
– Печән өс-с-те
эс-се-се-ме?!
– Кыш челлә-се
эс-се-се!..

«Печән өсте» ариясе тәмамланса,
Әй изрәтә симфония:
– Киләсе җәй,
Киләсе җәй...
Кит-мәс-ләр-гә
ки-лә-се җәй...

Кыш уздырып
Сайрый белгән чикерткәләр,

Кош уздырып
Сайрый белгән чикерткәләр
Узмас кышлар сару белән
Сикергәләр!
Мәңгелекнең
киләседәй...
Бу сорауга әгәр җавап эзли калсаң,
Җаның куяр шомланып...
Җаның куяр шомланып...

ӘЙТЕЛМИ КАЛГАН СҮЗ

Ярен әйтмә, борын әйт,
Мин исәндә үлмәссең!
Үлмәссең дә бөлмәссең,
Авырлыклар күрмәссең!
«Идегәй» – дастаны

Син бәхилләш айлы урам белән, –
Урлап китәм сине бу төндә.
Капка төбегездә бу үбешү
Бүтән кабатланмас
бөтенләй.

Капка төбе белән бәхилләш син.
Кузгала ат атлар-атламас... –
Кабатланмас төннәр
кала монда,
Качып кайтсаң да... –
кабатланмас!

Кузгала ат...
Туктар өчен түгел,
Инде туктамаска кузгала.
Авылыңны чыккач,
Куллар изә,
Үзең белән хушлаш, кыз бала.

«Ашыгасың» диеп елый-елый,
Кыз чакларың кала...
Ул – садә!

Ә син минем белән,
Хәтта сөю
Капка төбендә үк калса да...

Урлап китәм сине үз-үзеңнән,
Гомер сизелмәс тә, бу төндәй.
...Капка төбегездә үбүләрең
Инде кабатланмас...
бөтенләй...

РЕДАКЦИЯДӘН. Иртәгә танылган шагыйрь Ләис Зөлкарнәйгә 60 яшь тула. Без каләмдәшебезне күркәм гомер бәйрәме белән ихластан тәбрик итәбез, аңа исәнлек-саулык һәм яңадан-яңа иҗат куанычлары теләп калабыз.

1958 елда Татарстаныбызда зур нефть химиясе комплексы төзү турында карар кабул ителә. Аны төзиячәк кешеләр өчен шәһәр генераль планы эшләнә. Тагын өч елдан биредә беренче йортлар салына башлый, бистәгә рәсми рәвештә Түбән Кама исеме бирелә. Ә тагын биш елдан ул шәһәр статусы ала. 1978 елда Казан инженер-төзелеш институтының архитектура-төзелеш факультетын тәмамлап юллама буенча яшь калага өлкән архитектор булып Фирдәвис Гайнетҗан улы Ханов кайта. Шул вакыттан башлап Ф.Ханов Түбән Кама белән бергә үсә. 1990 елда шәһәр һәм район баш архитекторы итеп билгеләнә, Татарстан һәм Россиянең атказанган архитекторы, Түбән Каманың почетлы гражданины исемнәренә лаек була.



Ханнарга тин Ханов





Яшерен-батырын түгел, милли республика булса да, Татарстаныбызда шәһәрләр нигездә бер-берсенә бик охшаган. Хәтта башкалабыз Казанда да архитектурада, урамнар бизәлешендә милли чалымнарны бик сирәк очратасың. Бу вәзгыятьтә Түбән Камада милли архитектура үрнәкләре пәйда булу шатландыра. Әлеге эшнең башында торган архитектор Фирдәвис Ханов быел архитектура һәм шәһәр төзелешендә татар милли мәдәниятен үстерүгә керткән өлеше өчен республикабызның Габдулла Тукай премиясенә тәкъдим ителде.

Ф.Хановның беренче эшләреннән булган шәһәрнең тимер юл һәм автовокзалына ул вакытта Идел буенда тиңнәр булмый.

Фирдәвис әфәндене мәчетләр проектлауда зур осталыкка ирешүен аерым билгеләп үтәргә кирәк. Түбән Кама җәмигъ мәчете үткән гасырның сиксәненче елларында төзелә башлый. Ул вакытта Хановның мәчет архитектурасы турында әллә ни белеме дә булмый, ник дигәндә, институтта төрле гыйбадәтханәләр турында төрле гыйлем бирелергә тиеш булса да, нигездә чиркәү архитектурасын гына өйрәтеп, чиркәү эчләрен бизәргә генә йөртәләр, шуңа күрә мөселман архитектурасын нечкәләп үзенә өйрәнергә туры килә. Нәтиҗәдә, Түбән Камада дүрт манаралы, 500 кешелек залы булган, җыйнак, матур мәчет калка. XVI гасыр архитектура үрнәгендә башкарылса да, ул заманча, килешле булып чыккан. Беренчеләрдән башкарылган җәмигъ мәчете проектыннан ук авторның үз стиле барлыгын чамаларга мөмкин. Тәүге чирканчык уңышлы килеп чыккач, Ф.Ханов Түбән Каманың Гагарин урамында тагын бер мәчет проектлый, «Кызыл чишмә» бистәсендә, Ташлык авылында, Азнакай районы Мәлбагыш, Минзәлә районы Дәвек авылларында да Ханов проектлары буенча төзелгән мәчетләр күзләрне иркәли. Фирдәвис әфәнде әнә шулай затлы нәселен лаеклы рәвештә дәвам итә. Аның бер бабасы Әбелхарис Уфада укып бөек мәгърифәтче галим Ризаэтдин Фәхретдин кулыннан таныклык ала һәм үз төбәгендә имам була. Әнисе Һидая авыл халкын хәреф танырга, укырга-язарга өйрәтә...

Түбән Камада байтак вакыт Сабан туен төрле урыннарда үткәреп, бәйрәм җиһазларын бер җыеп, бер сүтеп изаланган булсалар, үткән гасырның туксанынчы еллары ахырында Сабан туе өчен «Мәйдан» комплексы булдыру турында карар кабул ителә. Төзелешнең архитекторы итеп Ф.Хановны билгелиләр. Урман янында бик матур җирдә урнашкан «Мәйдан»ны бүген «Ильинка» мәдәни-спорт комплексы дип йөртәләр. Автор тамашачы урнашачак урынны, тау рельефын кисеп борынгы Грециядәге амфитеатрлар үрнәгендә проектлый. Анда бүген сигез мең кеше урнашып уч төбендәгедәй бөтен мәйданны күзәтә ала. Сабан туе мәйданының зурлыгы әле бүген дә шаккатыра. Ул вакытта исә рельефны уеп ясалган стадион, арена, мәйданнар бөтенләй булмый. Архитектор Ф.Ханов шул рәвешле милли бәйрәмебез Сабан туен колачлы, зур итеп үткәрүгә үзеннән саллы өлеш кертә.

«Кызыл чишмә» бистәсендә «Изге чишмә» комплексы да – Түбән Кама халкының мактанып сөйли торган урыннарның берсе. Хәер, аны проектлау һәм төзү эше бер дә җиңел булмагандыр, чөнки таулы җирдә урнашканга, анда техника белән кереп булмый, бөтен төзелеш материалларын кул белән ташырга туры килә. Ул гына җитмәгән иде, тарихи дөреслекне урнаштыру мәҗбүрияте туа. Чишмәнең төзекләндерүенә шатланып, христиан дине әһелләре бирегә тәре утыртып куймакчы була, чишмәне Стахеевларга бәйләп, Иннокентий Стахеев атып үтерелгән урын бу, дип аны үзләренчә изгеләштерү хәстәрен күрә башлый. Шәҗәрәне тикшереп карасалар, Стахеевлар нәселендә Иннокентий атлы кеше бөтенләй юк. Аның каравы, Алабуга дәүләт педагогика институты архивында чишмәне татар-болгар имамы Дәүһит Әсмәгыйҗан һәм аның алты буыны карап торганы язылган таныклык табыла. А.Радищев та биредә имам яшәгән дип язып калдырган. Дөрес, 1848 елда бу җирләр Стахеевлар биләмәсенә әйләнә. Әмма аңа кадәрге тарихның онытылуына юл куярга ярамый. Шуңа күрә Изге чишмә янында «1631-1733 елларда имам Дәүһит Әсмәгыйҗан торак куышы» дип язылган таш куела. Болар архитектор вазифасына кермәсә дә, тарихи дөреслекне әнә шулай архив тузаннарын актарып кайтарырга туры килә.

1990 еллар башында ук бөек рәссамыбыз Бакый Урманче Түбән Камага Габдулла Тукайның бронза бюстын бүләк итә. Аны шәһәрнең Яшьлек урамында урнаштыралар. Шуннан башлап архитектор Фирдәвис Ханов һәйкәл янындагы бакчаны Тукай паркына әйләндерү турында хыяллана башлый. Паркның проектын ясый һәм ул Мәскәүдә архитектура бәйгесендә беренчелекне алып, иң шәп эшләр каталогына кертелә. Архитектор Хановның теләк-омтылышларын сизгәндәй, Илбаш Рөстәм Миңнеханов 2015 елны республикада скверлар һәм парклар елы дип игълан итә. Ниһаять, Ф.Хановка егерме елдан артык күңелендә йөрткән кадерле проектны тормышка ашырырга мөмкинлек туа. Бүген Тукай исемендәге бакча бөтен шәһәр халкының яраткан ял урынына әйләнде. Биредә бала-чага Бала һәм күбәләк, Былтыр һәм Шүрәле, Кәҗә-Сарык, Су анасы-малай сыннары янында әвәрә килә. Татар авыл йортлары үрнәгендә төзелгән агач йортлар паркка җылылык өсти. Теләгән һәркем «Түбәтәй» кафесында милли ризыклар, кайнар чәй белән тамак ялгап чыгарга мөмкин. Янәшәдә үк Тукай исемен йөрткән китапханәнең урнашуы паркка тагын да зуррак мәгънә өстәп, аны белем-мәгърифәт урыны буларак бүтән бакчалардан бер баскыч югарырак күтәрә. Фонтан янында бертуктамый яңгыраган татар көйләре күңелне иркәли. Музыка тынып торган араларда артистлар башкаруында әдәби әсәрләр яңгыратыла. Йә, Кырлайдан кала, Татарстаныбызның кайсы шәһәре, бистәсе Тукай паркы белән мактана ала? Олуг шагыйребез рухын саклаган гүзәл бакча хәтта Казаныбызда да юк. Тукай музеен ремонтлаганда, аның тирәсендә шигърият, әкият геройлары сыннарын бастырып бакча корачаклар, балалар кафесы, эстрада да шунда урнашып, музей яны паркы шигъри-музыкаль кичәләр үткәрү урынына әверелечәк, дигән сүзләр белән никадәр кызыктырмасын, ни кызганыч, шәһәр һәм республика башлыкларының әйткәннәрне эш белән расларга милли хисе, күңел ялкыны җитмәде...

Архитектор Ф.Хановның проектлары буенча төзелгән ЗАГС, банк, ресторан, сәүдә үзәкләре, нотариаль контора биналары да хәтта бер-берсен кабатламый. Иҗат колачы шундый киң ки, ул стела, авылга керү билгеләрен, урам экслибрисларын да, пляж, экопарк, дистәләрчә чакрымнарга сузылган Сабан туе мәйданнарын да бердәй оста проектлый.

Бер ара Түбән Камада шәһәрнең үз йөзен булдыру өчен торак йортлар фасадларын «ириска» дип аталган плитәләр ярдәмендә милли орнаментлар белән бизәделәр. Шул бизәкләр генә дә шәһәргә никадәр җылылык өстәде! Хәзер яшел скульптураларны шәһәр саен күрергә мөмкин. Заманында исә аларны беренче булып түбән камалылар куя башлый. Бу эшләр дә – баш архитектор Ф.Хановның иҗатына бер штрих.

Ф.Хановның милли җанлы, зыялы шәхес булуы җәмәгать эшендә дә яхшы күренә. Ул беренчеләрдән булып Түбән Камада Актаныш якташлык җәмгыятен оештырып җибәрә (үзе ул Актанышбаш авылында туып-үскән). Бүтән якташлык җәмгыятьләреннән аермалы буларак, гел бер җирдә – Илһам Хисмәтуллин эстрада театрында җыелалар. Әле үзләре Актанышка баралар, әле актанышларны Түбән Камада кунак итәләр. Хановның якташларны берләштерү, туган телне, гореф-гадәтләребезне торгызу, саклау, яшь буынга тапшыру хакына кылган бу җәмәгать эшләре дә зур бәягә лаек.

Ф.Хановның эше төрледән-төрле конкурс-фестивальләрдә югары бәяләнүен дә искәртик. 2004 елда II Бөтенроссия архитекторлар арасында һөнәрмәндлек бәйгесендә беренчелекне алып, ул «Россиянең иң шәп архитекторы» дигән дәрәҗәле исемгә ия була. Түбән Кама шәһәренең исә Россиянең 100 меңнән артык кешесе булган шәһәр (бистәләре) арасында өч тапкыр беренчелекне алуы шулай ук баш архитекторның нәтиҗәле эшен раслый.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Риф Гатауллин исеме татар җыр сәнгатенә саф язгы җил, ярсулы ташкын булып килеп керә. Матур тембрлы ягымлы тавышы белән сәхнәләргә җырчы сыйфатында менгән Риф тиз арада композитор булып та танылып китә. Узган гасырның җитмешенче елларында ул иҗат иткән «Хушлашырга ашыкма», «Безгә дөнья дәшә», «Бергә чакларда», «Бир кулыңны», «Гармун алыйк әле, дускай», «Кал моңнарым булып», «Серле йөрәк», «Соялдем сөяннәргә», «Ялгыз көймә», «Син кояшлы көнем» һ.б. йөзләрчә җыры өлкән буын җырчылар тарафыннан да, үзешчәннәр тарафыннан да ифрат яратып башкарыла, аларны тамашачы да сөеп кабул итә. Хәзерге көнгә кадәр бу җырлар халык күңелендә саклана, сәхнәләрдә генә түгел, мәҗлесләрдә дә яратып җырлана. Бу кадәр популярлыкның сере нәрсәдә соң? Халык күңеленә ничек сукмак салган бу композитор? Язның үзе кебек ярсу, яшьлек дәрте сирпелеп торган җырларына язмышының кайсы чатларында моң сарылган?..

Җырларын халык сөйде

Рифка кечкенә вакытта ук тальян гармун алып бирәләр, үзлегеннән шул 12 телле тальянда көй чыгарырга өйрәнә дә, аннары авыл сәхнәләреннән төшми инде ул. Укытучылары аны гел сәхнәгә чыгаралар. Яңгыравык тавышы белән шигырьләр сөйли, җырлый, уйный. Көйне бутап җибәрсә дә, хурланып кереп китми, яңабаштан башлый да уйнап чыга. Сигезенчене бетергән үсмернең бик тә музыкаль белем аласы килә, әтисе янына (әти-әнисе Риф туганчы ук аерылыша) яңадан Казанга чыгып киткәндә дә, күңелендә шул яшерен теләк була. Тик җитәкче урында эшләүче әти кешенең аны каядыр музыка мәктәпләренә йөртергә вакыты булмый, авыр баянын сөйрәп, башта үзе йөреп маташса да, кыен булгач, Риф бу уку йортын ташлый. Мәктәпне тәмамлап, егет КХТИга керә, ләкин күңелдә дөрләгән талантны, музыкага мәхәббәтне кая куясың? Барыбер үз юлын табып, ургылып килеп чыга ул!.. Институтта бер көнне берничә кеше килеп, хорга сайлап алыр өчен тавышларын тикшереп карыйлар. Рифны тыңлагач, ә сезгә хорда түгел, ансамбльдә җырларга кирәк, диләр. Шулай итеп, егет вузның ансамбленә йөри башлый. Тик монда гел рус җырлары җырлаталар. Ә Рифнең татарча җырлыйсы килә! Рәхмәт төшкере, бер игелеклесе: «Сара Садыйкова хорына барып кара әле син», - дип киңәш бирә. Бара егет Бауман урамындагы Горький исемендәге клубка, эзләп таба Сара апаны. Ленинның ниндидер юбилей елы, шау килеп әзерләнеп яталар. Бик күп яшь кызлар, берән-сәрән генә егетләр дә бар. Риф җырлап күрсәтә, татарчасы бик үк камил булмаса да, йөрәгендәге моңны тоептыр, Сара апа аны ала. Монда инде рәхәтләнеп җырлый башлый, Сара апа сольный номерлар белән дә сәхнәгә чыгара башлый. Ә КХТИда икенче курс килеп җитә. Сара апа: «Әйдә, энем, анда буталып йөрмә, син музыка училищесына кер», – ди. Әгәр дә бу егеттә тирән иҗади куәс сизмәсә, ул аңа мондый киңәш бирер иде микән? Әтисе, әлбәттә, әйбәт кенә укып йөргән җиреннән институтны ташлавына каршы килә. Тик үҗәт егет тә бирешми, әти кеше, үзенә кара алайса, дип кул селти. Шулай итеп Риф әтисе фатирыннан чыгып китә һәм җаны теләгән музыка

дөньясына баш-аягы белән чума. Музыка училищесында укый, ялланган фатирларда яши. Борисковода бер фатир хуҗасы аңа үзенең сарае урынына өй салырга рөхсәт бирә (Унҗиде яшәр кызына кияү сыйфатында күз салган була, күрәсең). Риф төшеп калганнардан түгел, дус-ишләрен җыеп алып килә дә, алтыга дүрт метрлы «насыпушка» төзеп тә куялар. Кичләрен зур машиналар паркына машина юарга чаба. Беренче курста укыган елны ук гастрольгә алып китәләр дә, аннан 170 тәңкә белән баеп кайтып төшә ул. Шул акчадан әнисенә алтын алка да сатып ала әле. Тик йортында гына озак яшәргә туры килми, заводка тулай торак төзер өчен җирне алалар да йортны сүтәләр.

Ә иҗат уты көчәя бара. Сара апаның репетиция саен үз җырларын уйнап күрсәтүен күреп тора, көн саен аңа җыр сорап төрле җырчылар килә, һәммәсенә язып бирә. Риф та җырлар яза, ләкин беркемгә дә күрсәтми генә. Хор кызлары үзләренең мәҗлесләренә дәшеп торалар, шунда Риф үзенең кайбер көйләрен җырлап та күрсәткәли. Кызлар аларны тиз генә өйрәнеп алып, җырлый башлыйлар. Сара апага да барып җитә бу җырлар. Ул исә егеткә: «Энем, беренче көйләреңне күрсәтмәскә тырыш, чөнки алар камил булмый», – дип сабак бирә. Сара апаның сүзен күңелендә саклый ул, җырлары халык арасында популярлашса да, мөхтәрәм җырчыларга әсәрләрен бары тик консерваториядә укыганда гына тәкъдим итә башлый.

Көйләр иҗат итсә дә, консерваториягә ул вокал юнәлешендә керә, чөнки композиция бүлегенә керер өчен гаять зур әзерлек кирәк, училищеда алган вокалист белеме генә җитәрлек түгел. Консерваториядә сольфеджио фәнен Шамил Шәрифуллин укыта, Риф белән яшьтәш булсалар да, ул музыкаль белем ягыннан нык әзерлекле, музыка училищесын баян буенча тәмамлаган. Нәкъ менә шушы шәхес Рифне чын-чынлап композиция юлына кертеп җибәрә дә инде. Рифнең җырларын инде зур-зур җырчылар җырлый, ә Шамил исә фундаменталь белем туплый, мөнәҗәтләр өйрәнә, җитди музыка белән мавыга. Ул әбиләреннән мөнәҗәтләр, бәетләр язып алган. Шамил Рифне дә тирәнрәк чумарга, бүгенге популярлык белән башны әйләндермичә, белем нигезен ныгытырга өйрәтә. 1979 елда консерваторияне вокал буенча тәмам итеп чыга Риф, иҗаты гөрли. Гөлзадә Сафиуллина белән иҗади гаилә корып, дуэтлары халыкта зур мәхәббәт казана. Аларны Бөтендөнья яшьләр фестиваленә җибәрәләр, Муса Җәлил исемендәге яшьләр премиясен тапшыралар.

Тик Рифнең күңеленә һаман тынгылык бирми торган уй бар: композиция өлкәсендә дә һөнәри югары белем алу. «Син бит инде консерваторияне бер тапкыр тәмамладың, җырларың яңгырап тора, танылу алдың, нигә сиңа композиторлыкка уку кирәк?» – диләр аңа. Ләкин Риф максатыннан тайпылмый. Сара апаның мисалы да этәргеч була аңа: шул дәрәҗәдә танылган кеше, җырларын бөтен халык җырлый, ә аны союзга да алмыйлар, гел типкедә йөри. Аннары профессиональ композитордан радио бер җырны 250 сумнан сатып ала, ә үзешчәннең гонорары – 50 тәңкә генә… Берничә талпыныштан соң Риф максатына ирешә, тиешенчә әзерләнеп, кабат Казан консерваториясенә, бу юлы инде теория һәм композиция бүлегенә керә. Шамил Шәрифуллин остазлыгында белемен тирәнәйтергә керешә. Консерваторияне ул «Сак-Сок» симфониясе белән тәмамлый.

Икенче кабат консерваторияне тәмамлаганнан соң, 1991 елдан башлап Риф әфәнде Халык иҗаты йортында эшли башлый. Шул чордан башлап ул даими рәвештә халкыбызның үзешчән композиторларын барлау белән шөгыльләнә. Һәвәскәр композиторлар оешмасын төзи, алар өчен «Барлау» фестивальләрен уздыра башлый, чын мәгънәсендә халык талантларын, көй-моң чыганакларын барлау, үстерү белән шөгыльләнә. Кырыгынчы еллардан башлап иҗат иткән һәвәскәр композиторларның исемлекләрен төзи, биографияләрен, җырларын туплый. Аларны семинарларга җыеп укытуны оештыра. Ифрат Хисамов, Тәлгать Вәлиев кебек композиторларның җырлары халыкның теленнән төшми, ә һөнәри белемнәре булмагач, союзга алмыйлар. Шундыйлар өчен борчылып, аларга консерваториядә стажировка үтү мәсьәләләрен хәл итә ул. Соңыннан бу шәхесләр зур күләмле әсәрләр яза башлый. Халык композиторлары турында телевидениедә, радиода тапшырулар эшли. Үз иҗатын да алып бара.

Улы Туран дөньяга килгәч, композиторның иҗатында яңа агым барлыкка килә – ул балалар өчен әсәрләр иҗат итә башлый. Туран үзе дә әтисе язган җырларны җырлап үсә, 5 яшеннән консерватория каршындагы махсус музыка мәктәбендә укый. Риф әфәнде аны үзенең юлын дәвам итәр дип өметләнә, әлбәттә. Ләкин көчле пианист булса да, улы укуын консерваториядә дәвам итәргә теләми, башка юнәлешкә китә. Ләкин Туран композитор әтисенең иҗат биографиясендә бәрәкәтле ролен уйнаган – сабыйлар рәхәтләнеп җырларлык «Без биибез», «Яңгыр, яу, яу!» кебек дистәләрчә җырлар иҗат ителгән. Балалар өчен җыр текстлары эзләп, Р. Гатауллин Нәкый Исәнбәтнең фольклор җыентыкларына чума. Остазы Ш.Шәрифуллинның «Риф, нихәтле тирән катламнарга үтеп керәсең, иҗатың шулкадәр саллы булачак», – дигән сүзләрен беркайчан да исеннән чыгармый. Үзе дә гомере буе мөнәҗәтләр, бәетләр җыя, фольклор экспедицияләренә йөри. Җыйган мирасын туплап, «Көйле иман» дигән фәнни хезмәт яза. Бер генә үкенече бар аның: үз дәү әнисеннән белгән мөнәҗәтләрен язып калдырырга өлгерми. Югыйсә, дәү әнисе мәдрәсәләр бетергән бик дини, укымышлы карчык була. Тик ул чакта яшьлек белән бу хәзинәне язып калырга кирәклеген аңларлык зирәклек кенә җитмәгән…

Халык күңеленә җырлары белән кереп урнашса да, Р.Гатауллинның иҗат офыклары тагын да киң – ул академик музыка өлкәсендә дә милли мирасыбызны баетты: «Сак-Сок» симфоник бәете, «Тәңре чоры аһәңнәре» симфониясе, фагот һәм симфоник оркестр өчен «Дастан», фагот, кларнет, флейта өчен «Авылда бер көн», төрле уен кораллары өчен камера-инструменталь әсәрләр язды. Моннан тыш, ул күп кенә спектакльләрне музыка белән бизәде: «Шүрәлеләр үч алмый» (Р.Мингалим), «Пар күгәрченнәр» (Батулла), «Исемсез утрауда» (М.Галиев) һ.б.

Риф әфәнде соңгы елларда үзенең җырларын туплап һәр музыка сөючегә бүләк булырлык «Минем җырлыйсым килә», «Сезгә нинди җыр кирәк?», «Балачакның җырлы мизгелләре» кебек искиткеч матур ноталы китаплар чыгарды. Хәзер ул һәвәскәр саналган композиторларның антологиясен чыгарырга әзерли. Алар арасында М.Имашев, З.Яруллин кебек шәхесләрнең булуы халыкның нинди хәзинәсе хакында сүз барганын яхшы дәлилли.

Җыр сәнгатебезнең бүгенге хәле композиторны бик борчый. «Гомерем буе һәвәскәрләрне күтәрергә тырыштым, чөнки алар – халыкның рухи байлыгы, профессиональ сәнгатьне туендырып торган чишмә. Кызганыч, хәзер халык нык көчсезләнде… Үзешчән сәнгать бетте, музыка мәктәпләре дә тиешле дәрәҗәдә эшләми, – ди ул. – Җыр бит ул безнең татар халкын яшәтә. Шуңа күрә көй дә, җыр да яхшы булырга, тәрбияви булырга тиеш».

Язманың башындагы сорауларыма җавап табылды кебек. Җыр сүзләренә бары Г.Тукай, Ф.Сафин, Ә.Ерикәй, И.Юзеев, М.Әгъләм, Г.Зәйнашева кебек сүз остасы шагыйрьләрнең мәгънәле әсәрләрен генә сайлап алуы, милли колориты, тамырларыбызга тирән бәйләнештә иҗат итүе, белемгә чиксез омтылышы аның иҗатын чын халык мәхәббәтенә лаек иткән ләбаса. Аның иҗатының тулы бер буын күңелендә генә түгел, ә татар музыкасы тарихында да олы урын биләве һичбер шиксез.

Эльмира СИРАҖИ.

Ләбиб ЛЕРОН

КАЕШ

(Хикәя)

– Әссаләмегаләйкем, адаш!

Очрашканда ул миңа гел шулай эндәшә. Әтинең исеме минем әдәби кушаматым булганлыктан, аңа мин дә адаш булып чыгам инде. Минем исәнләшүем исә, гадәттә, аныкыннан кайтыш – үземчәрәк:

– Сәлам, кәнишне, адаш абый!

Ике куллап күрешкән вакытта ул коронный җөмләсен әйтеп өлгерә:

– Син – эш кешесе, шуңа күрә, вакытыңны алып тормыйм, ике генә сүз әйтәм дә, шуның белән вәссәләм! – ди.

Аның ике сүз дигәне, гәпләшә торгач, бер-ике сәгатькә сузыла...

Кызык агай ул. Белмәгән, аралашмаган кешесе юк. Татарның билгеле шәхесләре турындагы күпсанлы хикәятләре, гадәттә, болайрак башлана: “Бервакытны Марсель Сәлимҗанов белән икәү Ык буенда балык тоткан чакта...”, “Рафаэль Мостафин белән табигатьтә хозурланып йөргәндә”, “Риф Гатауллин минем көйне тыңлап карады да...”, “Шаһинур Мостафин шигырьләремне укыгач...”, “Алмаз Монасыйпов болай дип әйтте...”

Әгәр аның үз хисабына чыгарган шигырь китабын карамаган һәм аның фотоларындагы таныш йөзләр янәшәсендә аныкын да күрмәгән булсам, бәлкем, гомер буе нефтьче булып эшләгән, вышка-скважинадан башканы күрмәгән агайның сүзләренә ышанмас та идем.

Чандыр гәүдәле, пеләш башлы, үзе әйтмешли, “аяз күк йөзедәй саф һәм зәңгәр күзле” агай дәртләнеп-каударланып сөйләгән чакта, мин аның пинҗәге эченнән чалынып киткән киң, кызыл подтяжкасына игътибар иттем. Җете кызыллыгы өстенә, гаять киң булуы да җәлеп итте бугай. Кайчандыр моңардан кайтышрак подтяжка миндә дә бар иде. Узган гасырның сиксәненче елларында аны куллану модага кереп алды. Миндәй яшь кешегә барып та бетмәгәндер инде ул чакта, ә минә өлкән адашыма ул хәзерге вакыта бик килешеп тора. Шул турыда үзенә дә әйтермен, дип уйлап куюым булды, агаем, сөйләвеннән кинәт туктап:

– Син миңа бер танышымны хәтерләтеп торасың. Пинҗәгемдә мамык шәе юктыр бит? Ул иптәш, гозеремне җиткергән вакытта, дикъкать белән тыңлаган кыяфәт ясап, киемнән чүп эзләгәндәй итенә башлый, – диде.

– Гафу ит, адаш абыкаем,сине тыңлыйм мин! Кем турында әйткәнеңне дә чамалыйм. Әйе, тыңлау рәвеше шулай аның – күзләреңә туп-туры караган килеш, киемеңнән йон-мамык яисә чәч бөртеге алган булып, синең фикереңне чуалта, син исә, үзең дә сизмәстән, аның алдында кечерәеп калып, инде нәрсә әйткәнеңне бик үк аңламыйча, быдыр-быдыр сөйлисең-сөйлисең дә, ахырда, нинди йомыш белән килгәнеңне онытып, үзеңне тыңлаганы өчен аңа рәхмәтләреңне яудырып, яныннан китеп барасың. Бераздан башыңа килереп суга: бәй, бу миңа файдалы бернинди сүз дә әйтмәде бит, дисең!

– Әйе шул! Карале, син мин уйлаганны әйттең дә бирдең.

– Адаш абый, тагын бер мәртәбә гафу ит! Менә, чия кебек кып-кызыл подтяжкаңы күрдем дә, кайчандыр шундыйны үзем дә киеп йөргәнемне исемә төшердем. Чалбарын моның белән каптырып куючыларны күптән очратканым юк иде.

Адаш агай, уң кулының имән бармагын күккә төбәп, аны бер мәлгә һавага катырып куйгандай итеп:

– Каеш такмавымның сәбәбе бар... Чөнки... Яратмыйм мин аны! Яратмыйм! Шуның белән вәссәләм! – диде.

Бер килүендә:

– Адаш булуың өстенә, җандаш та син миңа, чынлап әйтәм, безнең уйлар, фикерләр туры килә, шуңа күрә, синнән дә кулай кеше тапмадым, әгәр каршы булмасаң, менә бу роман сыман нәрсәне укырга бирмәкче идем, – дип, шактый калын папка китереп салды. Аны чишеп, кампитрда басылган кульязманың тәүге битенә күз төшерергә генә өлгердем, ул үтенечен кире кага күрмәсен берүк диптерме, минем салпы ягыма салам кыстырды:

– Синең фикереңне ишетү – минем өчен мәртәбә!

Шул сүзләре белән ул миңа артка чигенергә урын калдырмады. Гәрчә, мондый үтенечләр соңгы вакытларда аеруча күпкә киткәнлектән, вакытым тарлыгын, эшемнең үтә тыгыз булуын сәбәп итеп, үземнең дә әһле каләм икәнлегемне искәртеп, баш тартырга да була иде. Шулай дип әйткән булам гына инде, әле берәүнең дә йомышын үтәмичә калганым юк.

Өйгә кайткач, тузынган булам үземчә, бәргәләнәм:

барып җиттем. Агай башыннан кичкәннәрен – ничек нефтьче һөнәрен сайлавын, нинди шартларда, тәгаен кемнәр белән эшләвен бәян иткән. Җөмләләре озын булса да, язганнары төзек, хисле, шигъри урыннары байтак – күренеп тора, монда нефтьче агайның шагыйрьлеге сизелә. Миңа кадәр берәрсенә укытып алдымы икән – хаталары да әллә ни күренмәде. Әмма кульязманың бер кимчелеген таптым бит тәки. Шылтыратып, бу хакта үзенә дә әйттем:

– Күренеп тора, үзеңнең тормышыңны язгансың. Балачак бар, мәхәббәт һәм яшьлек бар. Әмма...

Агаем, кинәт, сүземне бүлеп:

– Әллә ошатмадыңмы? – дип сорады.

Туры җаваптан качып:

– Эшчеләр темасын бик шәп ачкансың. Узган гасырның 70-80 нче елларында басылып чыккан булса, бәлки, бу әсәр буенча хәтта кино төшерергә булырлар иде, – дим. – Әйе, монда иң мөһиме – әсәр бар!

– Ошамаган урыны булса, туп-туры әйт, аңлый торган кеше мин. Бәлки миңа бу әсәрне язып та торасы булмагандыр, ә?

– Син аны язгансың инде, димәк, шулай кирәк булган. Мин бөтенләй башка нәрсә турында. Әниең хакында бик яратып язгансың, җай чыккан саен аны телгә аласың. Ә менә кайчандыр укытучы булып эшләгән әтиең турында нибары бер җирдә генә әйтеп үткәнсең – алтмышынчы еллар уртасында каты авырудан вафат булды, дигәнсең дә, шуның белән вәссәләм! Әтиеңә нишләп шундый мөнәсәбәт? Сәбәп нидә? Аннары, гаиләдә дүрт бала үскәнсез, ә романыңда калган өчегез хакында да бер сүз юк...

– Кырык эшем кырык якта кырылып ята. Тегенең шигырьләрен, моның хикәяләрен карап чыгарга һаман җай юк, бусын ник алдым инде! – дип дулыйм. Хатыным хәлемә кермәсме, дип тә үземчә чәүчәләкләнүем инде бу. Аның исә кызганырга һич исәбендә юк – өзми дә куймый да:

– Вәгъдә бирмәскә иде! “Юк” диярге өйрән! – ди.

Әйтүе җиңел ул, син бар, баш тартып кара! Үтенече булган кеше сине ныклап өйрәнеп, синең баш тартмасыңны белеп килә бит ул!

Озын сүзнең кыскасы, бер атна дигәндә, кульязманың ахыргы ноктасына

– Дөрес тотып алгансың, әй! Әтине искә алмадым шул. Махсус! Чөнки... чөнки ул мине яратмады. Яратмавы бер хәл, ул мине гел кыйнады!

– Ничек инде – кыйнады? Укытучы башы беләнме?

– Кыйнау гына бер хәл, каеш белән ярды! Җай чыккан саен! Әнигә дә күп эләкте. Каешны яратмавым, әтине күралмавым менә шуннан килә...

– Тиктомалдан кыйнамагандыр бит инде әтиең? Ул бит – укытучы, заманында Ленин ордены белән бүләкләнгән! Моның сәбәбе булгандыр?!

– Сәбәбе... бәлки берничә булгандыр. Әни бик чибәр иде минем. Өстәвенә, әтидән җиде-сигез яшькә кечерәк. Аннары мин кыяфәтем белән калган өч баланың берсенә дә охшамаганмын. Башкалар – кара чәчле, кара күзле дигәндәй, бер мин – зәңгәр күзле, соргылт чәчле. Үзләреннән аерылып торгангадырмы, калган өчәү дә мине яратмады. Бәлки, төп сәбәп шул булгандыр?!

– Безнең авылда да бар иде әтиең шикелле берәү. Фәхретдин исемле. Минеке түгел, дип биш баласы арасыннан берсен – миңа яшьти тиешле Әсхәтне гел какты. Какты, дип... Гәрчә аның каккан-сукканын күргәнем булмады үзе. Өйдә өлкәннәр сөйләшкәннән чыгып кына әйтүем. Әсхәтнең дә кыяфәте башка абый-энеләреннән аерылып тора иде...

– Үсә, исәя төшкәч, борын астында мыек шәе шәйләнә башлагач, мин суда коенудан кыенсына, тәнемне чит-ятка, бигрәк тә кызларга күрсәтүдән оялла башладым. Күкрәгемә, култык астына котырып йон үсүе сәбәпче булды моңа. Кызлар шуны күрер дә гаеп итәр, миңа кырын карар төсле тоелды. Минем нилектән борын салындырып йөрүемне белгәч, әни болай диде:

– Улым, минем әтием Сәлимҗан кыяфәт ягыннан нәкъ синең чама булган. Синең сыман зәңгәр күзле, соргылт чәчле, йонлач. Мин бик кечкенә чакта үлгән. Авылдашлары аны Җонлы Сәлимҗан дип йөрткән...

Телефонның теге башында агаемның көрсенеп куйганын сизеп алдым:

– Менә шул чактан бирле каешны да, гөнаһ булса да, әтине дә күралмый башладым инде...

– Адаш абый, мин күреп алганны, башка укучы да күреп алачак, аның башына да: “Нишләп автор әсәрендә әтисен бер дә искә алмый?” – дигән сорау киләчәк. Минемчә, әсәрнең кайсыдыр бер төшендә әтиең турында бер-ике җөмлә белән генә булса да әйтеп үтәргә кирәктер, – дидем мин.

– Каты авырып үлде, дисез бит. Нинди чир белән авырды ул? Ул чире, бәлкем, син гөнаһсыз сабыйны кыйнаганы өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан аңа бер җәза буларак бирелгәндер?!

– Карале, син боларны каян беләсең? – дип, гаҗәпсенеп әйтеп куйды агаем.

– Сиземләвем көчле, – дигән булдым.

Ни сәбәптәндер, сөйләшүебез өзелде. Адаш агайга кабат шылтыраттым.

– Телефонымны колагыма терәп алган идем, шуңа өзелде, ахры, – диде ул. Аннары сүзен дәвам иттереп:

– Ә бит син дөрес чамаладың... – диде. – Чынлап та, әтине Алла бабай сукты. Безнең якта шулай сөйләшәләр – берәрсенә бәла-каза килсә, Алла бабай сукты, диләр...

– Бездә дә шулай диләр...

– Сугышка яраксыз булуы аркасында, фронтка алмадылар әтине. Мин белеп бетермәгән ниндидер чирен таптылар бугай. Шул чире, сугыштан соң тагын да көчәеп, көннәрнең берендә аны паралич аяктан екты. Әйтергә онытканмын, эти сулагай иде минем. Менә шул кулы бөтенләй хәрәкәтләнми торган булып калды... Икенче кулының да кирәге шуның кадәре генә иде... Өстәвенә, эти сүзен җүнле-рәтле әйтә алмый торганга әйләнде... Ул үләр алдыннан Ходай алдан сиздердеме шунда, әнине күреп, хәлен белим, дип кайткан идем. Хәл-әхвәл алышып, үземнең күчтәнәчтән авыз итеп, әни белән чәй эчеп утырган чакта, әтинең элеккедән катырак итеп ыңгырашканын ишетеп алдык та, ул яткан карават янына килдек. Шулчак аның өстендәге япмасы астыннан каеш шәе идәнгә шуып төште. Нурсыз күзләрен минем тарафка төбәп яткан әтинең хәлсез, кипшенгән иреннәре арасыннан ике сүз – аның соңгы сүзләре – аермачык булып ишетелгән кебек булды:

– Кыйна... улым...

Телефон тагын өзелде. Күңелем тулудан, адаш агайга шактый вакыт шылтыратмый тордым. Бу мизгелләрдә аның үз хәле хәл иде булса кирәк...

23 февраль, 2022 ел.

Үсәр мөмкинлек күп әле

Бөтендөнья театр көнендә Идел буе федераль округы төбәкләрендә балалар һәм яшьләр театр коллективларының «Театраль Идел буе» фестиваленә нәтиҗәләр ясалды. 14 төбәк онлайн конференциядә аралашты, бер-берсенең спектакльләре өчен баллар куйды. Конференциянең Казандагы трансляциясе Шәрык клубында узды.

Фестивальнең финалында Татарстаннан ике коллектив катнашты. Алар – региональ этапта җиңү яулаган Әтнә районының «Сәхнәдәш» театраль студиясе һәм Чистай «Экспромт» халык музыка-драма театры.

Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин әлеге бәйгенең беренче этабында Татарстаннан 400дән артык бала һәм яшүсмер катнашканын әйтте. Ул төбәк этабының җиңүчеләренә рәхмәт хатлары тапшырды, Камал театры һәм Кариев театрына билетлар бүләк итте.

«Театраль Идел буе» фестивалендә балалар коллективлары арасында Саратов өлкәсе беренче булды, Әтнә районының «Сәхнәдәш» театраль студиясенең «Урмандагы тамаша» спектакле 20 балл җыеп, тугызынчы урын алды. Яшьләр арасында беренчелекне Пермь крае яулады, Чистай «Экспромт» халык музыка-драма театрының «Конек-Горбунок» спектакле 22 балл белән – җиденче.

«Сәхнәдәш» студиясе җитәкчесе Финә Сафиуллина быел әлеге фестивальдә Татарстан ирешкән нәтиҗәләр узган елныкына караганда уңышлырак булуын билгеләде.

Финә Сафиуллина әйтүенчә, балалар театры студиясендә уйнап йөрүчеләр соңыннан театр училищесына укырга керґән.

Гөлия ХӘСБИУЛЛИНА.

Күренекле тарихчы-археолог, башкалабызга 1000 еллык бәйрәм бүләк иткән галим Фаяз Хуҗин Тукай бүләгенә тәкъдим ителде. Шул хәбәрне ишетүгә үк, күз алдыма туган ягым Балык Бистәсе районының иң атаклы тарих-археология истәлеге – Чаллы каласы килеп басты.

ОСТАЗ –АРХЕОЛОГ

Риваятьләргә караганда, аңа кайсыдыр бер Казан ханы нигез салган. Шәһәр заманында бик зур һәм алтын капкалы булган. Шәһәр урыны XIX йөздә дә яхшы сакланган әле. Бу хакта Күгәрчен авылы мулласы Бикмөхәммәд Зәетов һәм шул чорда эзләнүләр алып барган урыс тарихчылары язып калдырган. Шәһәр кирмәне 4-5 катлы ныгытмалар белән уратып алынган. Кремльнең тышкы ягында гади халык – һөнәрчеләр, игенчеләр, вак сәүдәгәрләр яши торган бистә урнашкан. Аның мәйданы 100 гектардан арткан, заманасы өчен зур шәһәр булган.

Биргә мин еш килә идем. Килгән саен якында гына урнашкан Котлы Бөкәш һәм Тәберде Чаллысы кешеләренең шушы тарихи байлыкны саклауга битарафлыгына гаҗәпләнеп, күңел сыкрана иде. Бервакыт радиодан археологларның яңа ачышлары турында сөйләүләрен ишетеп калдым. Тәвәккәлләп, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты археологлары янына бардым. Исәбем аларны Чаллы шәһәрлеген казып өйрәнергә күндерү иде. Күп йөрдем. Берсе белән сөйләшәм – һич килешми, икенчесенә ялварам – бу тема белән шөгыльләнмим, ди. Шунда Фаяз Хуҗин атлы археологны табып сөйләшергә киңәш иттеләр. Аның командировкадан кайтканын көттем. Җүкәтауда казу эшләре алып бара икән. Мөлаем кеше бит, тыңлады, хәлемә керде кебек. «Карап кайтыйк булмаса», – диде. Икенче көнне Балык Бистәсе автобусына утырып, Казаннан чыгып та киттек.

Менә без кирмән урынында, ә борынгы кала биләмәсе нык кызганыч хәлдә. Шәһәр кирмәненең ныгытмалары эченә ягулык саклый торган цистерналар урнаштырылган. Хезмәтчәннәр арасыннан «татар тарихының безгә кирәге юк», дип бугаз киерүчеләрнең сүзләрен дә тыңларга туры килде.

Авыр уйлардан аерылып, һөнәрчелек бистәләренә таба атлыйбыз. Сөрелгән җир өстендә чүлмәк китекләре, кеше һәм хайван сөякләре аунап ята. Менә бу – борынгы зират урыны. Күптән түгел генә казылган тирән чокырда, тау кадәрле чүп өеме белән янәшәдә, кабер эзләре күренеп тора. Фаяз абыйны колхозның машина-трактор паркы һәм ындыр табагы урнашкан җиргә алып китәм. Биредә тагын да күңелсезрәк күренешләр көтә. Ашлык саклау складлары, гаражлар, ремонт мастерскойлары – барысы да борынгы бабаларыбызның зираты өстендә утыра. Шунда эшләүче агайларның сөйләвенә караганда, биналарның нигезен казыганда йөзләгән кеше скелеты чыккан. «Актарылды инде, – диләр, безнең сораулы карашыбызны тоеп. – Өстән кушкач, нишлисең?»

«Карап торып җимерттереп булмый, киләсе елга түгел, быел ук казый башларга кирәк!» – Фаяз абый Хуҗинның ныклы карары иде бу. Шул ук көнне Казанга кайтып киттек. Бер атна эчендә Фаяз абый үзе эшләгән бүлек мөдире һәм институт директоры Мирфатыйх Зәкиев хәер-фатихасы белән яңа экспедиция оештырырга өлгерде һәм хезмәттәшләре Гамирҗан Дәүләтшин, Илгизәр Газимҗанов, Айрат Гобәйдуллин белән, әлбәттә, мине дә ияртеп, яңадан борынгы Чаллыга юл тоттык.

Бу 1993 елның август ае иде. Ике-өч көн эшләргә өлгермәдек, безгә тарих укытучысы Кәримулла абый Ахунов җитәкчелегендәге Котлы Бөкәш мәктәбе укучылары килеп кушылды. 1995-1997 елгы сезоннарда Казанның 42 нче мәктәп-гимназиясе укучылары эшләде, Алабуга дәүләт педагогика институты студентлары археологик практика үтте.

Шәһәрлекнең борынгы ныгытмалары, йорт урыннары, хуҗалык корылмалары, ханлык чорына караган тимерче алачыгы казып тикшерелде. Каланың әле монголларга кадәрге чорда ук яшәгән булуы ачыкланды, Алтын Урда чорына караган акчалар табылды. Антрополог Илгизәр Газимҗанов XIII–XV йөзләргә караган мөселман зиратларын өйрәнде. Борынгы Чаллы каласының, Казан шәһәре яулап алынганнан соң, 1553-1556 елларда, ханлыкның башкаласы булып торуы да ачыкланды.

Мин Фаяз Шәрип улының актив эшчәнлегенә, эшне оештыра белү, яшь һәм белем дәрәҗәсе ягыннан ярыйсы гына чуар коллективны бербөтен итеп туплый алу сәләтенә сокланып йөрдем. Кичке якта базага кайтып та (базабыз Тәберде Чаллысының мәктәп бинасында иде) тик ятмадык, табылдыкларны юып-киптереп пакетларга төрдек, казу эшләренә багышланган язмаларны тәртипкә китердек. Фаяз абый эшсез утырырга яратмый иде, бездән дә шуны таләп итте. Әле бит ул укучылар һәм студентлар белән җанлы әңгәмәләр оештырырга да вакыт таба иде. Бу елларда Фаяз абыйның Казан кремлендә алып барыла торган казу эшләре белән җитәкчелек итүен дә искә алсак, аның өлгерлегенә, тырышлыгына, чыннан да, сокланмыйча булмый.

Безнең якны, аның кешеләрен дә яратып өлгерде ул. Казу эшләрен төгәлләгәч тә аерылмады ул Чаллыдан, чөнки аның материалларын музейларга урнаштырып, халыкка җиткерәсе бар иде. Табылдыкларның иң кызыклыларын башта Котлы Бөкәш мәктәбе музеена урнаштырдык, аннан соң байтагын Балык Бистәсендәге төбәк тарихы музеена алдылар. Эшләребезне иң ахырда район үзәгендә үткән фәнни-практик конференция белән тәмамладык. Чаллы археологиясенә багышланган фәнни чыгышлар Казанда һәм Биләрдә Татарстан Фәннәр академиясе, Мәдәният министрлыгы һәм Милли музей оештырган бөтенроссия конференцияләрендә дә укылды һәм галимнәр арасында зур кызыксыну уятты.

Эшләребезнең фәнни нәтиҗәләре 2000 елда Ф.Хуҗин редакциясендә нәшер ителгән «Борынгы Чаллы. Древние Чаллы» исемле 320 битлек күләмле китапта чагылыш тапты. Соңрак, Борынгы Чаллы каласы федераль дәрәҗәдә сакланучы тарихи-тыюлык буларак расланды.

Чаллыдагы казу эшләре, киң җәмәгатьчелекне төбәк тарихы белән кызыксындыру безнең өчен мөһим булган тагын бер проблеманы күтәрергә һәм аны уңышлы гына чишәргә ярдәм итте. Сүзебез Котлы Бөкәш белән Тәберде Чаллысы арасында урнашкан Хәлфә бабай чишмәсе турында. Хәлфә бабайны (Идрис бине Зөлмөхәммәт) безнең якларда белмәгән кеше юктыр, әмма яшьләр аны оныта башлаган иде. Аның исеме яңадан торгызылды: чишмәсе тәртипкә китерелде, 1995 елда Тәберде Чаллысы зиратында Хәлфә баба истәлегенә таш-стела куелды, аның тормышына, эшчәнлегенә һәм, гомумән, суфыйчылык хәрәкәтенә багышлап фәнни конференция үткәрелде. Бу эшләрнең барысында да Фаяз Шәрип улы актив катнашты һәм район җитәкчелегенең, төбәк халкының рәхмәтенә лаек булды.

Борынгы Чаллы – халкыбызның уникаль археология һәйкәле. Аны фән өчен, киләчәк буын өчен саклап калуда Фаяз Хуҗинның роле бүген дә зур. Олуг галимебез җитәкчелегендә ясалган ачышлар фән дөньясында танылу алды, болгар-татар тарихы өчен әһәмиятле табылдыклар да юкка чыкмады – музейларда саклана. Бабаларыбыз калдырган тарихи мирас аларның дәвамчыларына, безгә, яшь буынга кайтарыла. Югарыда язарга өлгергәннәремә нигезләнеп, мин, әлбәттә, Фаяз Хуҗинны Г.Тукай исемендәге олы бүләккә лаек дип саныйм.

Нурулла ГАРИФ,
тарих фәннәре кандидаты.

Мәдәни җомга
1 апрель
№12, 2022

Әхмәт ибн Фадлан илчелегенең Идел буе Болгарстанына килүенә һәм Алмыш ханның ислам динен дәүләт дине дәрәҗәсендә кабул итүенә 1100 ел тулу уңаеннан Татарстанда «Ибн Фадлан» фильмын төшерү тәмамланып килә (продюсеры – Айназ Мөхәммәтҗанов, баш режиссеры – Рәмис Нәҗмиев). Анда төп рольләрнең берсен Кырым Республикасының атказанган артисты, талантлы җырчы һәм актер Асан Билалов уйнады. Аның белән әңгәмә кору үзе бер шатлык.

● «Народна зірка» конкурсы. Җырчы Злата Огневич белән.

КИНОДАГЫ

– Асан бәй, сез кай якта, нинди гаиләдә үстегез?

– Миңа 52 яшь. 1970 елда Үзбәкстанның Учкудук бистәсендә дөньяга килгәнмен. 1975 елда гаиләбез Әндиҗанга күченде. Әнием Ольга Борис кызы – рус милләтеннән, әтием – Кырым татары. Әнием – музыкант, концертмейстер, пианист, гомере буе балалар музыка мәктәбендә эшләде, кечкенә балаларны җырларга өйрәтте. Ул хәзер дә исәнсау, бүген Новосибирск шәһәрендә яши. Сәйран исемле бертуган абыем бар, башка туганнарым да.

Хәтердә, балалар бакчасында тәрбияче апа җырларга кушса, кечкенә урындыкка менеп, суза идем: «... Не плачь, девчонка, пройдут дожди! Солдат вернётся, ты только жди!»

Әтием Айдер күп һөнәрдә булып, гомер буе гаиләнең матди ягын кайгыртып яшәде. Ул диңгезче дә булган зат. Кайчак бездә утны сүндергән чаклар да булгалады, шундый сәгатьләрдә ул кулына аккордеон ала да, җыр суза иде. Мин урта мәктәптә дә җырладым, үзешчән сәнгатьтә дә актив катнаштым, соңрак КВН командасында да чыгыш ясадым... Әндиҗан дәүләт педагогика институтының тарих факультетында укый башладым. Чөнки тарих белән V-VI сыйныфлардан ук кызыксындым, аеруча да Мисыр тарихына күңелем ятты. Ул китаплар әле дә саклана, хәтта «Мисырда кече пластик формалар» дигән китабым да бар иде. Армия хезмәтен Монголиядә үттем. Армиядән кайткач та, шушы ук институтта укучы студент кызга өйләндем. Елена Әндиҗанда туып-үскән, үз гаиләсендә яхшы тәрбия алган... Югары белем алуымны дәвам иттем, ләкин II курсны тәмамлагач, Үзбәкстандагы сәясәт үзгәрде һәм без, качаклар буларак, Саратовка юнәлдек. Андагы университетта читтән торып укыдым һәм Саратов өлкәсенең Базарлы Караболак районындагы Ключи авылында, йөз илле укучысы булган мәктәптә эшли башладым. 1994 елга кадәр өч ел буе тарих дәресләре укыттым.

– «Барыбер Кырымга кайтачакбыз!» дигән уй башыгызга килә идеме?

– Үзбәкстанга депортацияләнгән Кырым татарлары һәрчак туган якларын сагынып яшәде, һәрвакыт: «Кырымга әйләнеп кайтабыз әле!» – диләр иде. Әтиемнең кыз туганы Украинада яшәде, чөнки ул Бөек Ватан явында партизаннар отрядында сугышкан батыр, Кырымның атказанган партизаны! Шуңа аңа Украинада яшәргә рөхсәт ителде. Ул Үзбәкстандагы туганнарына – дүрт гаиләгә посылкалар сала иде. Кырым кояшы нурларында кызарган, бик тә сусыл, авызда эреп китүче Бере сортлы грушаларны еш салды. Бу төр грушалар Кырымда гына үсә, бөтенләй башка тәм. Кырымда гына үсә торган кизилдан да кайнатма ясап юллый иде...

Кырымга 1994 елда гаиләм белән кайттым. Чиста кырга, дүрт казыкка, алты сутый җиргә... Әтием Кырымга кайтырга ике ай кала вафат булды. Миңа ул чакта 24 яшь иде.

Ә дәү әтием Билалның Симферопольдәге йорты әлегәчә исән! Мин аңа әле дә карап узам. Билгеле, башка Кырым татарлары йортлары кебек үк, депортациядән соң дәү әтием йорты да хөкүмәт карамагына күчкән...

Ватанга кайткан беренче елларда, гаиләмнең матди ягын тартып баручы ир-ат буларак, нык тырышырга туры килде. Беренчедән, укытучы булып эшкә урнаша алмадым. Ул вакытларда Кырымга кайткан барча югары белемле ир-атлар йә төзүче, йә сатучы булып эшләргә мәҗбүр булды... Мин дә башта базарда карбыз саттым, йөк бушаттым. Әтием өйрәткәнгә, мин штукатурка ясауны, бетон эшләрен дә, таш өюне, мич чыгаруны да яхшы белә идем. Үндүрт яшемнән әтием белән төзелешкә йөрдем. Бер көнне газетада игълан укыдым, официантлыкка укытып, эшкә алачакбыз, диелгән иде. Өч айлык курсны бетердем һәм Симферопольнең «Москва» ресторанына официант булып урнаштым. Бер тәүлек буе официант хезмәтемдә, аннары ике тәүлек буе төзелештә – ташчы, ә бу ике эш арасындагы ял көнемдә, төнлә заводта сакчы булып та эшләдем. Нинди эш булса, шуңа алындым.

Өч ел буе официант булып эшләдем. 1990 еллар уртасы төрле төркемнәр, бригадалар, Әфганстанда, Урта Азиядә хезмәт итеп кайтучылар вакыты иде бит. Аларның ресторannarда җыелган чоры. Әлеге адәмнәрнең үзләре белгән җырларны тыңлыйсы килә, ә ресторан музыкантлары урам җырларын белми. Без Үзбәкстанда чакта ук аларны җырлый идек, шуңа мин ресторанда җырлар суза башладым. Бүген дә сәхнәгә чыгып җырлый алам, моннан читенсенмим...

2010 елга кадәр Симферопольдә, Кырымның күп шәһәрләрендәге рестораннарда, туй мәҗлесләрендә дә җырладым. Коктебельдәге бер милли кафены Кырым татары тота иде, ул мине чыгышларымның яртысын милли җырлар җырлау шарты белән кабул итте.

– Сезнең нәселегездә җырлый белүчеләр күпме?

– Әбием Гөлсемнең җырга сәләте бар иде. Аның «Къаранфиль» («Канәфер») дигән җырны матур итеп башкарганы истә. Илле яшьлек юбилей концертымда мин дә шушы милли җырыбызны башкардым. Әтием дә аккордеон тартып, халык җырларын җырлый иде. Бертуган абыем Сәйран Сахалинда яши. Ул андагы мәктәпләрнең берсендә система администраторы булып эшли, төрле конкурсларда җырлый. Нәселебез тарихын бик тирәнтен белмим, әмма бездә җырга сәләт булуы аңлашыла. Ана телемне яхшы аңласам да, сөйләшкәндә ялгышырмын дип, кыенсына төшә идем. Яшьлектә үзбәкчә һәм русча гына сөйләштем. Ләкин соңгы елларда туган телемне өйрәндем. Хәзер һәрчак үз телемдә сөйләшергә тырышам.

● «Ибн Фадлан» фильмын төшерү вакытында. Асан Билалов һәм Айгөл Әхмәтова.

Туган телемдәге җырларны башкаруга җаваплы карыйм, текстларның мәгънәсен өйрәнәм. Туйларга, төрле бәйрәм мәҗлесләренә чакырылганда, милли җырларыбызны күбрәк башкарам, шулай тиеш. Яшьләрдә милләтебезгә, мәдәниятебезгә карата мәхәббәт, ихтирам хисе тәрбияләргә кирәк, башка юл юк. Милләтне һәрдаим ныгытырга тиеш без! Ә бу иң беренче чиратта – туган телдә аралашу. Бар җирдә дә Ана телебездә сөйләшсәк кенә, телебезне саклап, балаларыбыз аша аны киләчәккә илтәчәкбез. Диңгез тамчылардан җыела.

– Асан бәй, уңыш өчен нәр-

● А.Билалов мәэзин дә әле.

● Җыр конкурсында җиңү мизгелләре.

АЛМЫШ ХАН

сә мөһим: гаҗәеп тырыш хезмәтме, җете талантның булумы? Бәлкем, барысы да берьюлыдыр?

– Боларның барысы да. Тырышу гына аз, талантны күрсәтеп бирә белү дә мөһим. Әйтик, Кырымга кайткач, берара кырымтатар фольклоры белән генә бәйле юнәлештә эшләп, шушы өлкәнә алга этәрергә кирәк, дигән нәтиҗәгә килгән идем. Барысы да 2010 елда үзгәрде. Хәләл җефетем мине "Украина" телекомпаниясе тарафыннан оештырылачак «Народна зірка» музыкаль шоуында катнашырга өндәде. Кастингка барырга теләгем юк иде, әмма Елена мәҗбүр итте. Бу – Россия телевидениесендәге «Ике йолдыз» конкурсына охшаш бәйге. Кастинг аша үттем һәм шушы конкурсның өченче сезонында катнаштым. Миндәй үзешчәнне Украинаның яшь, талантлы җырчысы Злата Огневич белән бер пар итеп берләштерделәр. Бу конкурста барлыгы ун пар көч сынашты, безгә музыкаль чыгышлар өчен төрле жанрдагы биремнәр бирелде. Безнең чыгыш алкышларга күмелде. Бәйге жюриена да, Украинаның бихисап тамашачыларына буй-сыныбыз, тышкы фактурабыз буенча да ошадык. Мин тирән мәгънәле, тәрбияви эчтәлекле җырлар яклы булдым. Үзебезнең «Къарылгъач» җырын да башкардым. Злата Огневич белән I урынны яуладык. Конкурсның призы 62 мең доллар яисә Украина акчасы буенча ярты миллион гривна иде. Бик сөендем. Бу акчаның нәкъ яртысына, ниһаять, һаман сузылып килгән йортымны төзеп бетердем. Приз акчасының калган яртысын мохтаҗ Кырым татарларына тараттым, бер хатын-кыз, бер ир-атка ясалырга тиешле җитди операцияләр өчен түләдем. Аларның хәлләрен әле дә белеп торам, алар исән-сау!

Әлеге җиңү мине Украина күләмендә сәләтле җырчы итеп танытты. Конкурстан соң бер ел узгач, 2011 елда директор Билал Билалов Кырымтатар дәүләт академик музыка-драма театрына эшкә чакырды. Төрле жанрларда иҗат итә торган театрыбызда әлегәчә хезмәт итәм. Биредә төп рольләрне дә башкарам. Драматург Г.Хаҗибәковның «Аршин мал алан» музыкаль спектаклендә баштарак Аскәр ролен башкардым, ә хәзер Сөләйман ролен уйныйм, Лопе де Веганың «Печән өстендә эт» комедиясендә – маркиз Рикардо ролен дә башкарам, калган спектакльләрдә дә рольләрем бар.

Конкурс нәтиҗәсе кино өлкәсендәге эшчәнлегемне дә арттырды. Мин «Прорыв года» номинациясендә җиңүче дип игълан ителдем. Россиядә төшерелгән берничә кинофильмда зур булмаган рольләр уйнадым. Кино төшерү өлкәсендә тәҗрибәм бар. Концертларга чакырсалар, катнашам. Ә зур милли концертларыбызның берсе дә миннән башка узмый. 44 яшемдә Фәүзи Якупов исемендәге Кырым инженерлык-педагогика университетының музыка факультетына кердем, аны академик вокал укытучысы профессиясенә ия булып тәмамладым.

– Сез кырыс этиме?

– Бу хакта кызларымнан сорарга кирәктер. Мин үземне кырыс кешегә санамыйм. Хәтта 29 яшьлек өлкән кызым да: «Синдә 52 яшь, ә кайчак үзеннә 6 яшьлек бала төсле тотасың», – ди. Мин – ихлас кеше. Балаларымны бары игелеккә өндәдем. Әниләре тәрбиясе дә көчле булды. Ходайга шөкер, кызларым Эвелина да, Эмилия дә кырымтатар ирләре белән тормыш корды. Үзләрен милләтпәрвәр итеп хис итәләр.

– Исламга ничек килдегез?

– Үзбәкстанда ураза тоту, Ураза бәйрәме, Корбан бәйрәме булуын белеп үстем. Әлеге көннәрдә без, бала-чагалар, өйдән-өйгә йөреп, олыларны бәйрәм белән котлап, үзебезгә сәдакалар җыя идек. Һәр олы кеше «Ленин»лы берәр сум акча бирә, алар сигез-унга тула, ә кино карау – 25 тиен иде. Рәхәт чаклар! Корьән ашлары, соңгы юлга озатулар, дини йолаларыбыз – барысы да исемдә кала килде. Кырымга кайткач, башта мәчетләрдәге җомга намазларына йөри башладым. Әкренләп күңелем белән исламга якынайдым, 2000 елдан башлап намаз укыйм.

Бер көн хөтбә вакытында мәчеттәге муллабыз вәгазь сөйләгәндә: «Кем ничек үлеп китсә, шул килеш Аллаһы Тәгалә каршына килеп басачак», – диде. Нык курыктым. «Үлгәч, Аллаһы Тәгалә алдында ярамаган кәефттә басып торырга язмасын!» – дип, үземдәге иманны тагын да ныгыттым.

– Сез бит әле мәэзин вазифаларын да башкарасыз.

– Моның сәбәбе бар. Намазлар кыла башлагач, бервакыт уйга калдым: «Ни өчен Аллаһы Тәгалә миңа шушындый тавыш биргән? Мөгаен, азан укырга тиешмендер». Һәм үз алдыма азанны дөрес һәм матур итеп укырга өйрәнү максатын куйдым. Өйрәндем. Кырымда, мин яши торган микрорайонда мәчет төзелмәгән иде әле. Шул чакларда үз йортым янындагы төзелеш өчен әзерләгән вак ташлар күче өстенә, биеккә менеп, азан укый идем. Симферопольнең Белое-5 микрорайонында мәчет мәэзине вазифасын инде дистә елдан артык башкарам. Әгәр эштә булмасам, вакыт табылу белән үк азаннар әйтәм. Симферопольгә XV гасырда, Кырым ханлыгының Акмәчет авылы җирендә нигез салынган. Минем өчен ул Акмәчет тә!

– Сез – иң ихлас кырымтатар ватанпәрвәрләренең берсе. Хәзерге кырымтатарларның субэтник төркемнәре арасында гомуми татулык хөкем сөрәме?

– Тормышымны Кырымнан башка күз алдына китерә алмыйм. Кырымтатар мәдәниятенә, үз халкыма хезмәт итәм. Үз җырларыбызны, инде онытыла башлаганнарын, сирәк башкарыла торганнарын да җырларга омтылам... Бездә дә, Коящта гаҗәеп яктылык-нурланышлар булып алган төсле, көчле яктылыклы, үҗәт рухлы, күңелләрендә ватанпәрвәрлек хисе һичкайчан да сүрелмәячәк шәхесләребез бар. Мин дә үз милләтем дип яшәүче. Танылган җырчы булуымны бары тик милләтем белән бәйлим. Милләтемнең көчле рухи булышлыгын 2010 елдагы конкурс барышында да тойдым.

Мәшһүрлек минем өчен авыр халәт дип әйтә алмыйм, мин тәкәббер түгел. Мәдәниятебез саклануына, үсешенә бүгенгәчә халык рәссамнарыбыз, сынчыларыбыз, декоратив-гамәли сәнгать осталарыбыз, язучы һәм шагыйрьләребез күбрәк көч куя төсле, тик бу осталарга дәүләт булышлыгы юк, шуңа күрә, нигездә, осталарыбызның һәркайсы үз остаханәләрендә тырыша... Керамика осталарыбыз да, чигүчеләр, милли кием тегүчеләребез дә... Милләтебез үзара тату. «Без – даладан чыккан ногайлар», «Без – Кырымның көньяк ярларыннан»,«ә без менә татылар» дип әйткәлибез, тик бу шаяртып әйтү генә, алар рухи чикләү тудырмый. Һәр милләт генофонды шул җирләрдә гомер иткән ыруларның, халыкларның холык-сыйфатлары белән туена. Иң мөһиме, милләт үзен игелекле гамәлләре белән генә зурларга тиеш.

– «Ибн Фадлан» кинофильмында Алмыш ханны уйнарга чакыруны ничек кабул иттегез?

– Казаннан хәбәр алгач, бик шатландым, шундук риза булдым. Чөнки күптәннән берәр тарихи нәфис кинофильмда уйнап карыйсым килә иде. Анары бу – мөселман динебезне пропагандалауга багышланган хезмәт тә!

– Алмыш хан образын ничек ачтыгыз? Мәшһүр төрек сериалын да карадыгызмы?

– Бу тарих хакында да җентекләп укыдым. Безнең үз ханнарыбыз да булган. Аларның кайсыберләре Казанда хакимлек итеп, биредә дә үз гамәлләрен кылган. Төрек сериалы – ул югары дәрәҗәдәге киноәсәр... Аның гомуми хиссиятле атмосферасы тәэсирле, әмма әлеге рольне үземчә күзалладым. Алмыш хан холкына кырыслык сыйфатын да өстәргә булдым. Чөнки хан, әгәр дә ул көчле шәхес икән, кырыс булмыйча кала алмый.

– Моңа кадәр Казанга килгәнегез бар идеме?

– 2014 елда Кырымтатар музыка-драма театры, Казан дәүләт консерваториясе ректоры Рубин Абдуллин белән килешеп, өч вокалчыны, шул исәптән мине дә, консерваториягә квалификация арттыру курсларына укырга юллаган иде. Опера җырчысы Зилә Сөнгатуллинаның шул чактагы дәресләре аеруча нык истә калган.

– Җырларыгызны интернетта табып, аларны тыңлап була-булуын. Ә менә сезне Казанга соло концертларыгызны уздырырга чакырсалар?

– Бик шатланып килер идем! Аларны оештыручы кирәк шул... Татар халкын үз итәм. Безнең телләр, мәдәниятләр – охшаш, динебез – бер. Әгәр Казанга килсәм, бик теләп ике-өч сәгатьлек концерт бирер идем.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

МАРИ ИЛЕНДӘГЕ

Марий Эл Республикасының Морки районында урнашкан Яңа Комыгырҗа (Тат-Чодраял) авылының тарихы башка татар авыллары тарихыннан әлләни аерылып та тормый. Әмма Тат-Чодраял авылы - бер җирлектәге ике халыкның ни дәрәҗәдә дус һәм тату яши алуына үрнәк мисал. Татар халкы, кайларда гына гомер итмәсен, иманын саклаган, милли кыйбласына тугры калган, намуслы тырыш хезмәт куйган, ут күршеләренә ихтирамлы һәм илтифатлы булган.

Авыл тарихын киләчәк буыннар өчен сакларга омтылган каһарман мөгаллим Фәрит ага Галләмов, Чулпан апа Гатиятова, Нурулла ага Гатиятовларның кульъязма хезмәтләре зур кыйммәткә ия. Шуларга нигезләнеп язылган әлеге хезмәтебез Яңа Комыгырҗа авылы тарихын фәнни юнәлештә өйрәнүгә тәүге адым булып тора. Авыл тарихын язганда Татарстан Республикасы дәүләт архивы (ТР ДА), Марий Эл Республикасы дәүләт архивы (МЭР ДА), Башкортстан Республикасы Үзәк тарих архивы (БР ҮТА), Россия Федерациясе Оборона министрлыгы Үзәк архивы (РФ ОМҮА) фондларында сакланган документлар өйрәнелде.

Авылдагы 21 нәсел шәҗәрәсен архив документларына һәм Нурулла ага Гатиятов язмаларына нигезләнеп төзедек. Алар арасыннан аеруча Мәннан Үтәгәнов шәҗәрәсе игътибарга лаек. Ул Яңа Комыгырҗа авылында яшәүче Мәнди нәселе вәкилләренең бөек галимебез Шиһабетдин Мәрҗани белән бер тамырдан булу ихтималының ни дәрәҗәдә югары икәнен дәлилли.

Язмаларда Мәннанның Сәрдәдә гомер иткән Сәйфулла мирза улы икәнлеге күрсәтелгән. Шушы нәсел дәвамчысы Фәйзелгаян хаҗи Фатыйхов безгә Сәйфулла улы Габделмәннанның (Мәндинең), гади крестьян буларак яшәргә теләк белдереп, Сәрдәдән Яңа Комыгырҗага килеп төпләнгәнлеге хакында авыл аксакалларыннан ишеткәнлеге турында сөйләде.

Баксаң, әлеге нәсел хакында мәшһүр Мәрҗани хәзрәтләре дә үз хезмәтендә бәян иткән икән: «Мелла Сәйфулла бине Үтәгән бине Нәдер бине Сөбкә бине Сафар бине Уразай бине Гаидхуҗа бине Шәмсихуҗа әс-Сәрдәви. Тумышы белән Казан тирәсендәге Комыргуҗа авылыннан. Югары Сәрдә авылында имам, хатыйб һәм мөдәррис булып, сонра Кызылъярга күчә. Аның түбән мәчетендә имам, хатыйб һәм мөдәррис булып, озын гомер сөреп, картлыкның чигенә җитә һәм 1269 (1852) елда зөлкагдә аеның егерме икесендә, шимбә көнне төн уртасында вафат була. Үзе бик картайгач, углы мелла Сираҗетдин Кызылъярга имам һәм хатыйб булды». *(Мәрҗани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: ТКН., 1989. – Б. 307.)*

Ризаэддин Фәхреддиннең «Асар» хезмәтендә Сәйфулла бине Үтәгән турында түбәндәге юлларны укый алабыз: «Кызылъяр (Петропавел) шәһәрендә 87 яшендә 1269/1853 елның Зөлкагдәсендә вафат булды.

Балалары: Габденнасыйр, Сираҗеддин, Габделлатыйф, Габделманнан, Әхмәд, Бәдреддин, Сахибҗәмал, Мәхбүбкәмал. Габденнасыйр Ханкирмән тарафында Курски исемле авылда имам вә мөдәррис булып вафат. Аңа хаҗи Вәлиэддин бине Хәсән әл-Бәгъдади тарафыннан 1234 елда язылган бер иҗазәтнамәсен күрдек.

Мәхбүбкәмал Төхфәтулла бине Габдеррахман никахында булып, Әхмәдвәли ахунның анасы иде.

Остазлары: Габдеррәшид бине Габделкәрим әс-Сәгыйди, Дагыстанда Хәсән әфәнде әл-Кәдали.

Шәкертләре: Габдулла бине Яхъя әл-Чиртушый, Сәгыйд бине Хәмид әл-Казаный, Хәммад бине Халид әс-Салавый, Фәйзулла бине Җомгакол әл-Кисильями, Морадым бине Йосыф әл-Уфавый һ.б.

Асылы Казан вилаяте Комыргуҗа авылыннан булып, шул җирдә дөньяга килгән. Тирә ягындагы мөгаллим вә мөдәррисләрдән укыганнан соң, Сәгыйдь бистәсенә барган, соңыннан Дагыстан якларына сәфәр кылган. Үз иленә кайтканнан соң Сәрдә авылында мәдрәсә тотып, уку-укыту белән шөгыльләнде, соңрак Ханкирмән өязендә Курскигә килеп өч ел вакыт торды вә шуннан Кызылъярга имам вә мөдәррис булып күчеп китте. Гомере озын булганга, гасырдашларыннан исән калып, игътибар вә хөрмәттә гомер кичерде, диләр». *(Фәхреддин Р. Асар. Т.2. – Казан: Рухият, 2009. – Б.58.)*

«Асар»да шулай ук дин эшлеклесе Рәхмәтулла бине Йосыфның да Сәйфулла бине Үтәгән шәкерте икәнлеге күрсәтелгән. *(Фәхреддин Р. Асар. Т.3-4. – Рухият, 2010. – Б.139-140.)*

Сәйфулланың улы Сираҗетдин турында китапта тагын мондый мәгълүмат китерелә:

«Сираҗетдин бине Сәйфулла бине Үтәгән Кызылъяр шәһәренең беренче мәчетендә имам булып, хаҗ сәфәреннән кайткан вакытында, 55 яшендә 1285 (1868) ел мөхәррәмендә Каһирәдә вафат булды.

Остазлары: атасы Сәйфулла (аның турында инде язылды), Байморад бине Мөхәррәм әл-Мәнгәри, Бохарада Салих бине Надир әл-Хөҗәнди, казый Шәриф бине Гата әл-Бохарый. Үз иленә кайткач, Кызылъяр шәһәрендә имам булды.

Шәкертләре: Әхмәдвәли бине Төхфәтулла әл-Кызылъярый һәм башкалар. Кайбер әсәрләр барлыгы турында риваять кылына». *(Фәхреддин Р. Асар. Т.2. – Рухият, 2009. – Б.123.)*

Галимебез Марсель Әхмәтҗанов та «Асар»да теркәлгән Сәйфулла бине Үтәгән шәҗәрәсен үзенең «Татар шәҗәрәләре» китабының I томына «Ш.Мәрҗани бабаларының билгесез туганнары булу ихтималын күрсәткән шәҗәрә» дип урнаштырган. «Әлеге шәҗәрәдә Ш.Мәрҗанинең Комыргуҗа бабасының якын туганнары дип Комыргуҗа авылыннан чыккан Шәмсехуҗа һәм Гаедхуҗаны кабул итәргә мөмкин. Әлеге исемнәр ул заманда Шәмсегуҗа, Гаедгуҗа рәвешендә әйтелгән булырга тиеш», – дип яза. *(Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре. Т.1. – Казан: ТКН, 2012. – Б.404.)*

Мәнди нәсел агачы шушы олуг галимнәребез хезмәтләрендә урын алган шәҗәрәнең бер тармагы булып тора.

● Яңа Комыгырҗа (Тат-Чодраял) авылы.

УРМАНДАГЫ ТАТАР АВЫЛЫ

Морки районында алып барылган археологик тикшерүләрдән күренгәнчә, бу төбәктә тәүге кешеләр б.э.к. III-II меңьеллыкларда яши.

XI гасырда Төньяк-Көнчыгыш Русь чикләре борынгы марилар (чирмешләр) яшәгән җирләр чикләренә кадәр килеп җитә. XII гасыр башында рус князьләре көчләп христиан диненә кертү сәясәте алып бара башлагач, марилар көчле каршылык күрсәтә. Ләкин, рус гаскәрләре көчлерәк булу сәбәпле, алар хәзерге Марий Эл һәм Татарстан республикалары җирләренә качып китәргә мәҗбүр була. X гасырдан башлап әлеге җирләрдә Арча каласы тирәләрендә дә шактый күп таралган борынгы удмуртлар (вотяклар яисә, марилар атап йөрткәнчә, одо-марилар) гомер итә. Удмуртларны «ар», «ар кешеләре» дип тә атаганнар. Алар анда яшәгән чордан Арын авылы сакланып калган. Арча каласы һәм дә чирмешләрнең вотяклар белән бәрелеше вакытында кирмән буларак хезмәт иткән Карман тавы атамалары да шушы этнонимга бәйле рәвештә барлыкка килгән. Чирмешләр Иделнең сулъяк ярына күченгән һәм, борынгы Хлыновтан (Колын) көнчыгышка таба хәрәкәт иткән чакта, вотяклар аларга үз җирләрен калдырып китәргә мәҗбүр була. Ә җирле халыкның күпмедер өлеше җиңүчеләргә кушыла. Шул рәвешле, XI-XIII гасырларда бирedәге вотякларны кысрыклап чыгарып, хәзерге Морки районы территориясен биләгән марилар районның иң борынгы халкы булып исәпләнә. *(История сел и деревень Республики Марий Эл. Моркинский район: Сборник документальных очерков. – Йошкар-Ола: Комитет Республики Марий Эл по делам архивов, Гос. архив Республики Марий Эл, Администрация муницип. образования «Моркинский район», 2004 г. – 320 с.)*

Башта Хәзәр каһанлыгына, соңрак Идел Болгарына ясак түләп торган чирмешләрнең җирләре XII-XV гасырларда Алтын Урда, соңрак Казан ханлыгы биләмәләре булып исәпләнә. 1489 елда Нократ җирләрен Рус дәүләте үзенә буйсындыргач, Ветлуга һәм Нократ елгасының урта агымына якын яшәүче чирмешләр дә руслар контролендә кала. 1523 елда тау чирмешләре яшәгән Сура һәм Идел елгалары кушылган җирдә Васильсурск каласы нигезләнә. Бу кала руслар өчен Казан ханлыгы яуларыннан саклану һәм соңрак Казан ханлыгына һөҗүмнәр җәелдерү өчен төп нокта буларак хезмәт итә. 1546 елның декабрендә тау чирмешләре һәм чуашлар, үзләренә сыену сорап, Явыз Иванга мөрәҗәгать итә. 1551 елда Зөя утравында кирмән төзелгәннән соң, тау чирмешләре һәм чуашлардан торган Тау ягы тулысынча русларга кушыла.

Болын ягы чирмешләренең русларга каршы аяусыз сугышлар алып бару сәбәпләрен мари галимнәре болай аңлата: «Испытывая влияние мусульманской культуры, постепенно воспринимая черты татарского лица, черемисы не лишались своей национальной самостоятельности: платя дань казанским царям, они сохраняли своих национальных князей и оставались хозяевами своей земли. Процесс отатарения совершался медленно и постепенно, мирным путем. К соседям татарам черемисы уже успели привыкнуть, сжились с ними. Русские же были для них загадочным, сильным врагом, совершенно чужими пришельцами с далекого запада. Вятских ушкуйников черемисы знали как опасных и дерзких разбойников. При всех этих условиях естественно, что пред лицом общей опасности черемисы не изменили татарам, соединились с ними против грозного неприятеля». *(Полтыш-князь черемисский. Малмыжский край: [Сборник / Ред.-сост. Л.Шемиэр (В.Н.Козлов)]. – Йошкар-Ола: Марийский полиграфкомбинат, 2003. – С. 57.)*

Икенче бер чыганакка мөрәҗәгать итик:

«Летом 1552 г. Иван IV двинул на Казань огромное войско; в походе участвовали и отряды горных марийцев. В то же время луговые мари оказывали помощь защитникам Казани. Они стали нападать на тылы русских войск, осаждавших город. Иван IV направил часть ратников, в составе которых были и «горные люди», на север от Казани «на многие места и велел воевати». Предпринятая военная операция сопровождалась жестокой рас-

ТАТАР АВЫЛЫ



● Мәннан (Мәнди) Үтәгәновның нәсел агачы.



● Казан өчен барган сугышлар картасы.

правой не только с вооруженными отрядами, но и с мирным населением, охватив территорию до 150 верст на север. Летописец писал: *«И быша убиения человеческая велика, и кровми полился варварская земля; блата и дебри, озера и реки намостишася черемискими костьми».*

Во время похода было захвачено у мирных жителей и пригнано в русский военный лагерь «бесчисленное множество скота». Взятые в плен 12 «арских князей», 7 «черемисских воевод», 300 сотников и 5 тысяч простых воинов были казнены перед казанскими стенами для устрашения защитников города.

2 октября 1552 г. после кровопролитных боев Казань была захвачена русскими войсками, Казанское ханство перестало существовать». (Иванов А.Г., Сануков К.Н. История марийского народа. – Йошкар-Ола: Марийское кн. изд-во, 1999. – С. 18.)

Казан яулап алынганнан соң, Рус дәүләтенә Болын ягы да буйсындырыла. Үз җирләрендә рус хакимияте урнашу белән килешмәүче болын марилары зур каршылыклар күрсәтә. 1550-1580 еллардагы бу бәрелешләр «чирмеш яулары» дип йөртелә. Бу тарихи мәгълүматны галимнәр мәктәп дәреслекләренә дә кертүнең гаять әһәмиятле икәнен аңлаган (китапның тулыландырылган варианты 2011 елда басылып чыккан) һәм милләтчелектә гаепләнеп 1937 елда карурманда атып үтерелгән чын халык шагыйре Сергей Чавайнның бәгыреннән тамган шигъри юлларны да урнаштырганнар:

«Разгром Казанского ханства и приведение к присяге представителей Луговой стороны отнюдь не означали установления мира на этой земле. Уже в декабре 1552 г. здесь вспыхнуло восстание местного ясачного населения. Марийцы части Луговой стороны, не уплатив ясак, перебили его сборщиков и направились к Казани. Высланные им навстречу отряды казаков и стрельцов были разбиты.

Так началось восстание, с марта следующего года переросшее в мощную национально-освободительную войну, которая затянулась с перерывами на 30 с лишним лет. Три всплеска этой войны получили общее название «черемисские войны». Одновременно сопротивление завоеванию широко развернулось среди татарского и удмуртского населения, перекинулось в башкирские земли.

Но царизм с самого начала проводил по отношению к марийцам политику национально-колониального гнета. Их присоединение сопровождалось неслыханными жестокостями по отношению к марийскому населению. Это вызывало естественное возмущение, сопротивление завоевателям. В ходе «Черемисских войн» второй половины XVI в. численность марийцев, особенно в центральной части Луговой стороны, значительно (не менее, чем наполовину) сократилась. Эти события остались незаживающей кровоточащей раной в исторической памяти народа, в его мировосприятии. Сергей Чавайн писал:

Ружейная бьется в лесу
стрекотня,
И пушки открыли дорогу огня.
Столетние сосны
от горя черны,
И трупами светлые реки
полны.
Звенят бердыши, громыхают
кольчуги,
Без отдыха рыскают царские
слуги.
Сражались мы тридцать
отчаянных лет,
На каждой тропинке
белеет скелет».

(Күрсәтелгән хезмәт. - Б. 25.)

Зур каршылыклар күрсәтелүгә карамастан, төбәк акрынлап руслар тарафыннан яулап алына, бер-бер артлы өяз үзәгенә әвереләчәк Кокшайск (1574), Козьмодемьянск (1583), Царевококшайск (1584), Уржум (1584), Царевосанчурск (1584), Яранск (1591) кирмәннәре нигезләнә. Идел буенда басып алынган җирләр белән идарә итү максатыннан Казан сарае приказы булдырыла. Халыкның төп өлеше ясаклы крестияннар катламына кертелә. 1724 елдан алар дәүләт крестияннары булып исәпләнә.

XVII гасырда төбәктә монастырь колонизациясе башлана: 1625 һәм 1649 елларда зур монастырьлар төзелә. XVII-XVIII гасырларда төбәк халкы берничә мәртәбә азатлык өчен көрәшкә күтәрелә.

1708-1920 елларда хәзерге Марий Эл территориясе Казан губернасы составына керә (1781-1796 елларда Казан наместниклыгы).

1920 елда Марий АО оеша. 1921 елда 3 кантонга бүленә. 1929-1936 елларда Марий АО Нижегородск крае составына керә. 1936 елда Марий АССР төзелә.

АВЫЛ НИГЕЗЛӘНҮ

Яңа Комыгырҗа (Тат-Чодраял) авылы Марий Эл Республикасының Морки районы Шиншә авыл советы үзәгеннән ике чакрым ераклыкта урнашкан. Авылны шартлы рәвештә ике өлешкә бүләләр: шосседан көньяктагысы Мари-Чодраял, төньяктагысы Тат-Чодраял дип атап йөртелә. Авылның көнбатыш өлешендә тирән ерым бар.

Тат-Чодраял дигән атама мари (чирмеш) теленнән гади генә тәрҗемә ителә: «тат» – татар, «чодра» – урман, «ял» – авыл дигән сүз, ягъни «урманда урнашкан татар авылы».

Әлеге авылның ничек барлыкка килүе турындагы хикәят ниндидер бер риваятьне хәтерләтә кебек. Әмма аның ни дәрәҗәдә дөрес икәнлеген шәҗәрәләр һәм ташъязма истәлекләр раслый.

XVIII гасыр башында елга буендагы урманлыкка беренчеләрдән булып биш мари гаиләсе килеп төпләнә. Гүзәл табигатьле урында урнашсалар да, яшәве җиңелдән булмый: көчленеке замана, дигәндәй, баштагы мәлләрдә аларны еш кына узгынчылар талап китә. Яннарына килеп төпләнүчеләр булмагач, марилар Әтнә базарында: «Әгәр дә күчеп килергә теләүчеләр булса, шундый яхшы урын бар!..» – дип белдерү ясый.

Мәгълүм ки, татарлар болын чирмешләре белән гасырлар дәвамында дустанә мөнәсәбәттә яши, иңне-иңгә куеп, милли-колониаль изүгә каршы көрәшә. Татарлар, үзләренең яуда сыналган тугры дуслары сүзенә колак салып, шушы җирләргә килә. Өченче ревизия дәверендә (1762 ел) марилар янына Казан губернасының Әтнә волосте Комыргуҗа авылыннан биш, Сәрдә авылыннан бер татар гаиләсе күченеп утыра.

Комыргуҗа – язма чыганакларда Казан ханлыгы дәвереннән күрсәтелеп килүче борынгы авыл. Аның оешуы, археологик истәлекләргә караганда, гомумболгар чорына барып тоташа.

XVIII гасырның беренче яртысында Россиядә ислам дине шактый эзәрлекләүләргә һәм кысуга дучар була. 1740 елда махсус оештырылган «Чукындыру буенча контора» эшчәнлеге нәтиҗәсендә 1742-1744 елларда, мәсәлән, Казан өязендә 536 мәчетнең 418 е юк ителә. Шул исәптән, Алат юлында мондый язмышка 91 мәчет дучар була. Алар арасында Абдул Ишбаев йөзлегенә кергән Комыргуҗа, Ябынчы һәм Төрекләр авылы мәчетләре дә бар. Яңа җирләргә килеп төпләнүчеләр менә шундый кысу-изүләрдән котылырга, күпмедер дәрәҗәдә булса да рухи азатлыкка ирешеп, үз диннәрен саклап калырга омтыла.

Янган урман урыны йортлар салу, ихаталар тоту өчен уңай җирләр була. Челтерәп аккан чишмәләре, елгалары, ерак түгел шаулап утырган урманнары белән җәлеп итә ул үзенә килүчеләрне. Татарлардан беренче булып килеп урнашкан кешеләрнең исемнәре халык хәтерендә әле дә саклана. Менә алар: Рәхмәтулла (Шөкери), Биккенә Журавлев, Ибәтулла Гобәйдуллин (Ибәт), Хәлиулла Нигъмәтуллин, Гобәйдулла Рәхмәтов, Мәннан Үтәгәнов (Мәнди).

Биккенә Журавлев, өяз үзәгенә барып, авыл исемен «Свободные ключи» (безгә мәгълүм документларда «Студеный Ключ») дип яздырган, диләр. Соңрак Комыргуҗадан тагын берничә гаилә күчә: Әхмәтҗан Вахитов, Бикбау Баязитов, Шәмси Баязитов, Биккол Сапколов, Галим Мөхәммәтрәхимов, Мөкатдәс, Хисмәт. Мулла Иле авылыннан абыйлы-энеле Нәҗми һәм Шәрәфи атлы кешеләр килә. Алардан соңрак Казан арты авылларының берсеннән сәүдәгәр Биккенә, тагын да соңрак Куәм (хәзер Татарстанның Әтнә районына карый) авылыннан Хөснетдин исемле кеше килгәнлеге билгеле. XX гасыр башында Чуаш Иленнән (хәзер Татарстанның Биектау районына карый) Сибгат Баязитов, Пичуш авылыннан (хәзер Марий Элнең Морки районы) Хәтмулла Гарәпшин, хәзерге Бәрәңге районына керүче кайсыдыр бер авылдан Мәүли Әгъләмов та шушы авылга килеп гаилә коралар. *(Гатиятов Н.Г. Тат-Чодраял авылы тарихы сәхифәләре [кулъязма]: Марий Эл, Морки районы, Тат-Чодраял авылы, 2008 ел. – 57 б.)*

Авыл халык телендә, татарлар күпләп килгән Комыргуҗа атамасын бераз гына үзгәртеп, Яңа Комыгырҗа буларак атап йөртелә. Филология фәннәре докторы Г.Ф.Саттаров язуынча, Комыргуҗа атамасы Гомәрхуҗа исемле кешенең ул авылга беренче булып килеп утыруы белән бәйле булырга тиеш (мисал өчен, Яшел Үзән районындагы Мулла Иле авылының исеме Муллагол дигән борынгы болгар кешесе исеменә мөнәсәбәтле). Бу фикернең дөреслегенә без Ш.Мәрҗани хәзрәтләре хезмәтләрен укып иналабыз:

«Мәрҗан авылы – Казаннан ике тукталыш төньякта, тау арасында урнашкан бер кечерәк авыл. Бабаларыбыз шул авылдан чыкканга, үзебезне шуңа бәйлибез. Дөресе: «Гомәрхуҗа» яки «Камәрхуҗа»дан үзгәртелгән – Комыргуҗа дигән авылдан чыккан бабабыз Габделкоддус килеп утырып, шуннан үзенә бер авыл башланып китkән.

Кечкенә булуына һәм күптән түгел оешуына карамастан, аннан күп кенә укымышлылар чыккан...» – дип яза бөек галимебез. *(Мәрҗани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: ТКН, 1989. – Б.228.)*

(Дәвамы киләсе санда).

Фидаил МӘҖИТОВ.

Төшемдә җиде

Мәгариф тарихының бер алтын баганасы булырдай Фатиха Габделвәли кызы Аитованың шәхесенә табынып яшим. Искитәрлек хәл: әтисеннән мирас булып калган акчасына Казан шәһәрендә әүвәл татар кызлары өчен мәктәп, ә 1916 елда, хәтта ир-балалар өчен дә булмаган вакытта (!), кызлар гимназиясе ача бит ул. Биналарын төзеткән, укытучыларга хезмәт хакы түләгән, читтән килүчеләр өчен пансионат та булдырган.

Аның мәктәбендә белем алып, мәдәният тарихыбызның гүзәл энҗеләре булып танылган Мәрьям Рахманкулова һәм Сара Садыйковалар белән горурланабыз. Ә башка кызларның язмышы нинди булган,ниләр кичерде икән алар гомер барышында? Шулай кызыксына торгач, миңа Сара апа белән бер сыйныфта ук укыган Хәлимә Госманова-Әхмәрова язмышын белергә насыйп булды. Тик кыз баланың ниләр күргәнен язарга озак вакытлар көч җитмәде.

Хәлимә апаның әтисе Гаязетдин ягыннан да, әнисе Җәмилә ханым ягыннан да (татарның күренекле мәгърифәтчеләре, җәмәгать эшлеклеләре Касыйм, Ибраһим, Хәмит Бикколовларның апасы) нәсел шәҗәрәләре бик кызыклы: Гаязетдин – Борһанетдин – Фәхретдин – Хәбибулла – Госман – Юныс – Чирүче (сугышчы мәгънәсендә). Чирүче исеменең чыгышы тарихыбыз белән бәйле: имеш, Әстерхан ханлыгы җимерелгәч, ул яклардан чукындырудан качып киткән юлчылар (хан нәселеннән булганнар диләр) хәзерге Чирмешән районында, урман буенда ялга туктаган. Алар кулында яшь бала да булган. Әмма юл бик куркыныч булганлыктан, яшь баланы ефәк юрганга төреп бишеккә салганнар да, агачка элеп калдырганнар. Янына 200 сум алтын акча куйганнар. Хәлне аңлатып, 100 сум акча баланы тәрбияләгән кешегә, 100 сум баланың үз тормышына дип язу да калдырганнар. Баланың яхшы нәселдән икәнен аңлатып тәрбия кылып үстерүне дә үтенгәннәр.

Хәлимә ханым нәсел тарихын яхшы белгән, тик ачыктан-ачык язып калдырырга курыккан булса кирәк. Нәселләренең рус шагыйре М.Лермонтов белән бәйләнешләре хакында балаларына да сөйләгән.

Шунысы кызыклы: Лермонтовның ерак бабалары Шотландиядән чыккан, дип элегрәк кайларга гына язмыйлар иде. Ә менә 2007 елда Оксфорд университеты галимнәреннән Брайан Сайкс бу нәселнең геннарын тикшереп караган һәм нәтиҗәсен язып та чыкты. Россиядә яшәгән Лермонтовлар белән Британиядә яшәүче Лермонтовлар арасында бернинди уртаклык табылмаган. Димәк, Михаил Васильевич та татардан бик ерак китмәгән булып чыга ич. Нәселләрендә дә татарлар барлыгы билгеле.

Хәлимә апаның әтисе Гаяз (Гаязетдин) - Иске Тинчәле авылы мулласы Борһанетдин баласы. Тик Гаязга 4 яшь тулганда ул үлеп китә. Әнисе баласы белән туган авылы Яңа Тинчәлегә кайта.

Кечкенәдән күркәм тәрбия алган, зирәк мулла баласының үскәч указлы мулла булып китүе гаҗәп түгел. Тик авылдашларына яшь мулланың яңалыкка омтылуы, балаларга дини генә түгел, дөньяви фәннәр дә укытуы ошап бетми. Алар Гаяз хәзрәткә төрле яла ягудан, хәтта һөҗүмнәр оештырудан да тартынмаган.

Хатыны Җәмилә абыстай белән аларның Мәсхүдә, Рәхимә, Хәлимә, Мәхмүт, Зәфәр исемле балалары туа. 1901 елда туган Хәлимәсен Гаяз мулла Казанга, инде даны еракларга таралган Аитова мәктәбенә (Аит мәктәбе дип йөрткәннәр) 1909 елда үзе китереп урнаштыра.

Инде мәгълүм булганча, Фатиха апа – ислам дине кануннарын кечкенәдән канына сеңдергән, барлык таләпләрен һәм йолаларын үтәгән, затлы нәсел тәрбиясе алган зыялы. Мәктәбендә дә һәрбер укучы кызга намаз укуны мәҗбүри куйган.

Әмма XX гасыр башы кешеләргә башка, яңа таләпләр куйган чор. Дин белән бергә дөньяви фәннәр өйрәнү кирәклеге зиһенле һәркемгә аңлашылган. Шуңа күрә мәктәптә дөньяви фәннәр дә укытыла башлый. Шунысы мактаулы – Фатиха апа Ана теле, гарәп телләре белән беррәттән, француз яки немец теле өйрәнүне дә кирәк тапкан.

Укучы кызларга тормышка яраклы һөнәр бирү турында да ныклап уйлана ул. Казанның атаклы аш-су осталарын чакырган, ә алар бу серләрне укучыларга өйрәткән. Кул эшләренә өйрәтү мөгаллимәсе булып Шумкова һөнәр гимназиясен тәмамлаган Вера Моисеева эшләгән. Һөнәр буенча имтихан биргәннән соң, кызлар Казан һөнәр управасына барып сынау үткән һәм аларга “Тегү остасы” дигән исем һәм документ бирелгән. “Авыр елларда ачлыктан кул эшләрен белүем генә коткарып калды”, – дип язган Хәлимә апа.

Җыр-музыкага өйрәтү дә игътибар үзәгендә. Җыр дәресләрен биредә намуслы хезмәте өчен соңрак, Совет власте елларында Ленин ордены белән бүләкләнгән Оркыя Мөштәриева алып барган.

Мәктәптә кара такта, парталар куелган, стенада карта эленеп торган. Дәресләр расписание нигезендә алып барылган, алар өчен махсус бүлмәләр җиһазландырылган. Укучылар куе-көрән күлмәк, кара алъяпкыч, ак яулыктан, ә бәйрәм көннәрдә ак алъяпкыч һәм калфактан йөргән. Уку елы ахырында, тантаналы шартларда, имтиханнар үткәрелгән. Аларга ата-аналар һәм шәһәрнең мөхтәрәм затлары чакырылган.

Мәктәпнең бай китапханәсе дә булган. Аны татар, рус, гарәп, фарсы, төрек телләндәге әдәби әсәрләр, Рәсәйдә һәм чит илләрдә басылып чыккан газета-журналлар тәшкил иткән.

Хәлимә апа менә шундый мохиттә укыган һәм гомер буе мәктәбендә алган, үзләштергән гадәт-тәртипләр буенча яшәргә дә тырышкан. “Әнием бик гыйлемле, сабыр кеше иде, – дип сөйли кызы Оркыя ханым. – Г.Тукайның барлык шигырьләрен дә яттан белә. Ш.Мәрҗани, Дәрдемәнд, Р.Фәхретдин, Акмулла кебек галимнәребез һәм шагыйрьләрнең әсәрләрен дә, Пушкин, Чехов, Достоевский, Лермонтовларның тәрҗемәләрен дә яратып укый иде. Гарәпчәне су кебек эчә, Коръәннең күбесен яттан белә, вәгазьне бик матур сөйли. Болар өстәвенә Шәрык медицинасыннан яхшы хәбәрдар, күпләрне дәвалаганын да хәтерлим. Бөтен авыл халкы аңа киңәшкә, эч серләрен сөйләп җиңеләеп китәргә дип тә килә иде”.

● Утырганнар (сулдан): Җәмилә Госманова, Рәйхана Морадимова. Басып торалар: Гаязетдин Госманов, Гариф Морадимов. 1927 ел.

Хәлимә апа Фатиха Аитова мәктәбендә алган белемнәре белән Яңа Тинчәледә мөгаллимә булып эшли башлый. Кыз балаларны ул үзләренең өендә, ә әтисе Гаяз имам ир балаларны мәчеттә укыткан.

1926 елда Хәлимә Татарстанның хәзерге Чүпрәле районы Кушкуак авылы мулласы Әхмәров Гарифуллага кияүгә чыга (араларында 30 яшь). Әйтеп үтик, Гарифулланың әтисе Шәрәфетдин сәүдәгәр булган, улына мәчетне дә үзе салдырып биргән икән... (Гарифулланың энесе Шиһаб Әхмәров – күренекле мәгърифәтче, Г.Тукайның иң якын дусты, бөек композиторыбыз Салих Сәйдәшевне тәрбияләп үстергән җизнәсе, репрессия газапларын кичергән кеше. Аның хакында газетабызда “Күгәрченкәй, ник кундың соң тәрәзәмә” дигән мәкалә бастырган идем).

Тик, уйлап карасак, Октябрь революциясеннән соңгы еллар - искә алырга да куркыныч бер чор бит. Совет власте урнашу белән башланган гражданнар сугышы, аңа ияреп үк килгән ачлык, мәчет-мәдрәсәләр ябылу, дин әһелләренең “хокуксыз җаннар”га әверелүе, булган мал-мөлкәтләренең тартып алынуы... Бу елларда ул хәлләрне кичергәннәрнең нинди аяныч хәлдә калуын аңлау кыен түгел.

Илдә колхозлашу башлангач, гомерләрен халыкка аң-белем таратуга багышлаган муллаларны илдән сөрү башлана. Алар хәзер “контрреволюцион элемент” дип кенә атала башлый. Менә шундый “элемент”ка әйләнгән Гаяз мулланы 1930 елның 24 мартында төнге сәгать 12 дә кулга алалар. Ул башта Буа, соңрак Казан төрмәсендә утыра. 1931 елның 25 февралендә Кемерово өлкәсенә сөрелә һәм анда шахтада эшләргә тиеш була. Әҗәле үк җиткән булган икән, шул ук елда, 67 яшьлек карт шахтада күмер төялгән ике вагонетка арасында кысылып үлә. Бәхетенә дип әйтимме, аны янында үзе белән бергә тоткын булган Хәмит Бикколов кабергә куя. Каберен дә берүзе казый...

Хатыны Җәмилә абыстай Бикколова да балалары белән кулга алына. Алар ерак Себер арьягына – Чита өлкәсенә сөрелә. Акыл ирешмәслек хәл: бу зинданнан башта 13 яшьлек Мәсхүдә Фирганәгә кача. Соңрак 7 яшьлек Рәхимәсе белән Җәмилә апа үзе дә Ташкентка качып китә. Башка балалар да шулай. Тагын да гаҗәбе: Ташкент урамында бу гаилә кешеләре бер-берсе белән очраша һәм шунда яшәп кала. Качарга үз татарларыбыз булышкандыр инде. Ул вакытларда мәрхәмәтле кешеләребез калган булган әле.

Инде Хәлимә апа язмышына килсәк, аларга да бер үк төсле “кояш”. Кулга

комган...

● Ф.Аитова мәктәбенең I сыйныф укучысы Хәлимә Госманова (унда) өлкән сыйныф укучылары белән.

алыначагын белгән Гарифулла хәзрәт Бакуга качып китә. Хәлимәне өч баласы белән 1930 елның 29 февралендә йортларыннан урамга куып чыгаралар, анда авыл советы кереп урнаша. 250 ел элек корылган нигез шулай җимерелә. 200 ел буе, ничә буын муллалар җыйган бик бай китапханә яндырыла. Мал-мөлкәт, хәтта бармакка киелгән йөзеккә кадәр талап алына.

Хәлимә апа, өйдән-өйгә йөрүдән туеп, сүтелми калган кечкенә өйләренә кире кайтып керә. Сүтәргә килүчеләр куса да, чыкмый. Соңрак барыбер чыгарганнар-чыгаруын. Колхозга кергән. Кушкуак авылында балалар яслесендә тәрбияче, укытучы булып та эшләп алган. Әмма авыл түрәләре аны ат караучы итеп куя. Колхозда нинди авыр эш бар – шунда эшләтәләр. Яз көнендә су ерып орлык ташый, тик аягына бик нык салкын тия.


١٩٢٦ نك عنوارنك ٢٥ سى
دوستم حليمه طوطاش
سزگه ده عمرلك يادكارم
اى دوستم اگر سين عاقله
ايرسەك أيتمه سرك نى
سنگا اول دوستكنك
دوستى بولور اولده سويله
دوستنگز: بعيسه
ساره عارف صاديقوا

● Сара Садыйкованың дусты Хәлимә Госмановага язган истәлеге.

Шулай салкыны да, күргән газаплар да эзсез үтми. Аит мәктәбен бетергән мөгаллимә 45 ел буе аяксыз утыра.

1944 елда авылга кайткан Гарифулла абзый ничектер кулга алынмыйча, исән-сау калып, 1963 елда 90 яшендә фани дөнья белән саубуллашкан. Соңгы көненәчә авылдашларын дини йолаларны үтәргә өйрәткән, муллалыгын ташламаган.

Гаиләнең туганнары, балалары өстенә төшкән газаплар да җитеп ашкан икән. Хәлимә апаның бертуган энесе Мәхмүт - һөнәре буенча табиб. Казахстанда эшләгән. Шунда Гайшә исемле бер кыз белән танышкан. Өйләнешергә булганнар. Тик Гайшәнең якыннары Мәхмүтне агулап үтерә дә, җәсәден тәрәзәсез бер бинага элеп куеп киптерә. Бу вәхшилек өчен беркем дә җавапка да тартылмый. “Контр мулла” улы кемгә кирәк?!

Хөкүмәт сәясәтен авыл мәктәпләрендә укучы балалары да татыган. Оркыя исемле кызларын Чирмешән мәктәбеннән дүрт мәртәбә куып чыгарганнар, әмма никтер һаман яңадан чакырып алганнар.

Хәлимәнең Зөфәр исемле энесе, үзенең хокукларын тартып алган, туган җиреннән куган илне саклар өчен, Бөек Ватан сугышына киткән һәм 1943 елда һәлак булган. Оркыяда ике открыткасы саклана.

Хәлимә ханым күргән бер төш бик гыйбрәтле. “Җиде комганны утка аттым”, – дип куркып уянган ул. Гаиләсендә бер-бер артлы җиде ир кеше үлемгә дучар булган бит. Теш кысып түзәргә динле булуы, сабырлыгы, күркәм тәрбиясе булышкандыр инде.

Гомеренең соңгы көннәрендә ул кызы Оркыя һәм кияве Әнвәр Мөхәммәтшин тәрбиясендә яшәгән. Оркыя югары белем алуга ирешкән, икътисадчы булып эшләгән. Апасы Мәрьям тегүче, туганнары Үзбәк университеты бетереп укытучы, Шеланга мәктәбендә директор булып эшләгән. Тик бары 44 яшендә йөрәге тибүдән туктаган.

Гарифулла хәзрәт 1963 елда вафат була. Ул үлгәч, Хәлимә апа авылда калмый, Казанга килә. Оркыя сөйләвенчә, үзен бик тәртипле, җыйнак тоткан. Урамга өйдә бәйләп йөргән яулыгы белән чыкмаган. Коръән укып, дини йолаларны бик тырышып үтәгән. Шунысы кызык: 61 яшендә ныклап русча өйрәнергә тотынган. Кызы: “Нәрсәгә инде ул сиңа?” – дигәч, “Мин алардан ким түгел бит, телләрен аңламый утырырга” – дип җаваплаган.

Шигырьләр язган. Аларда башыннан кичкән хәсрәтләрен аңлаткан:

Читләтеп үтте дип әйтмим,
Тормышның давыллары.
Басмады түгел күкрәкне
Кайгының авырлары.
Таныш миңа югалтулар,
Кичерешләр, янулар.
Түзә алмаслык газаплардан,
Ярадан сызланулар.
Тормыш утына каршы мин
Күкрәгем куйган кеше.
Әти-әни, туганнарны,
Дусларны җуйган кеше...

Ни хәл итмәк кирәк, ни өчендер дөньяның газаплары, бәхетсезлекләре талантлы, уңган, яхшы кешеләргә күбрәк төшә. Урыннары җәннәттә булсын.

Тәзминә БИКТИМИРОВА,
тарих фәннәре кандидаты.

Айга карыйН карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

2 апрель (шимбә). ***Рамазан аеның 1 нче көне. 2 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 5.52 сәгатьтә калка,19.50 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 13.11 сәгать.***

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

3 апрель (якшәмбе). ***Рамазан аеның 2 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында,6.01 сәгатьтә калка, 21.11 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 13.16 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Күңел төшенкелегеннән дәва

Чикләвекләр һәм кабак, көнбагыш төше туендырылмаган май кислоталарына, E, B, K, PP витаминнарына, Ca, Mg, Mn, Cu, Zn, Fe минералларына бай. Бигрәк тә татлы бадәм чикләвеге файдалы. Нутриентларга (азык матдәләренә) бай яшелчәләр һәм яшел тәмләткеч үләннәрне ашау кәефне күтәрә, энергиягә баета. Баклажан, томат, чөгендер, кишер, шпинат эч пошудан саклый. Банан, хөрмә, цитруслылар, йөзем, кара җимеш, шәфталу, фейхоа кәефне күтәреп кенә калмый, баш мие эшчәнлеген дә яхшырта, стресстан саклый. Какао (ачы шоколад) магний, тимер, калий, кальций, натрий кебек минералларга туендыра, эндорфиннар ясалуга булыша. Йомырка – В витамины һәм аксым чыганагы, ул тиз арада организмга хәл кертә, нерв системасын ныгыта һәм бавырны саклый.

4 апрель (дүшәмбе). ***Рамазан аеның 3 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында,6.11 сәгатьтә калка,22.31 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 13.20 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмләрәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Шифалы балан

Чуаннан, эренле сыткылардан, экземадан котылу өчен, аларга көненә 1-3 тапкыр балан согы белән компресс куярга кирәк. 2-3 атна дәвалангач, 1 атна туктап торалар, аннары тагын кабатлыйлар. Нәтиҗәсе күренсен өчен, 3-4 курс зарур. Экзема булганда, көненә ярты литрга кадәр балан согы эчү файдалы. Төнәтмә дә ярый: 2 аш кашыгы балан җиләген 1 стакан суда ярты сәгать төнәтәләр, ашарга 1 сәгать кала яртышар стакан эчәләр. Җәрәхәтләр тизрәк төзәлсен өчен, 1 аш кашыгы балан җиләген сытып, өстенә ярты стакан кайнаган җылы су салалар, 6-8 сәгать төнәткәч, сөзеп, 1 аш кашыгы бал өстиләр, шуның белән яраларга компресс куялар.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

5 апрель (сишәмбе). ***Рамазан аеның 4 нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында,6.25 сәгатьтә калка, 23.50 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 13.25 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп туплануын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

6 апрель (чәршәмбе). ***Рамазан аеның 5 нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында,6.45 сәгатьтә калка,1.03 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 13.30 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә әти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче өсти. Бизләр системасы, җилкә, кул,үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур.

Чия кесәле

Сулыш юллары ялкынсынганда, чия кесәле эчү файдалы. 400 г төшсез чия, 1,5л су, 6 аш кашыгы крахмал, тәменчә шикәр кирәк. Чияне суда кайнатып чыгарып, шикәр өстиләр, 10 минут пешерәләр. Ярты стакан кайнатып суытылган суда крахмалны эретеп, әкрен генә чия өстенә агызалар. Кайнап чыгуга ук уттан алалар, стаканнарга бүлеп суыталар.

7 апрель (пәнҗешәмбе). ***Рамазан аеның 6 нчы көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 7.14 сәгатьтә калка, 2.06 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 13.33 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказанын һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

Чикләвек каһвәсе

Ютәлләгәндә, бронхит һәм астма интектергәндә, йөрәк авыртканда, мондый каһвә эчү файдалы. Газ мичендә имән чикләвекләрен кызарганчы кыздырып алалар, төеп, каһвә кебек пешерәләр, сөт һәм шикәр кушып эчәләр.

8 апрель (җомга). ***Рамазан аеның 7 нче көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында,7.55 сәгатьтә калка,2.55 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 13.39 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

«Венеция» салаты

300 г тавыкның түш ите, 200 г шампиньон, 100 г кара җимеш, 100 г каты сыр, 4 пешкән йомырка, суган, кыяр, әстерхан чикләвеге, яшел укроп һәм петрушка, майонез кирәк. Тавык итен пешереп, кара җимешне кайнар суда парлап, вак кына турыйлар. Гөмбә белән суганны, турап, үсемлек маенда кыздыралар. Йомырканы пешереп, агын аерым, сарысын аерым уалар. Кыярны саламлап турыйлар, чикләвекне ваклыйлар. Пыяла креманкага катламлап тутыралар: иң аска – тавык ите, аннары – кара җимеш, майонез; аннан соң – суганлы гөмбә, йомырка сарысы, майонез; аннары – сыр, майонез, йомырка агы. Өстенә туралган петрушка белән укроп, чикләвек сибәләр, уртага кыярны матурлап өяләр.

Хөрмәткә лаек түгелме?!

ТНВ каналында “Әй, язмыш, язмыш” тапшыруында күренекле шәхесләребез белән очрашуларны яратып карыйбыз. Бу шәхесләр арасында яралы язмышлылары гади халыкныкына караганда да күбрәк икән, дигән нәтиҗәгә килдем. Гаилә тормышындагы катлаулы хәлләр, якыннарының бер-бер артлы китеп барулары, фаҗигале хәлләр һәм үзләренең дә хәтәр чирләр белән авыру очраклары турында елый-елый сөйләүчеләре дә булгалап тора.

Күренекле шәхесләребез арасында, күп төрле дәрәҗәле исемнәргә лаек булганнары белән беррәттән, бер исемсез булып, кыерсытылып калганнары барлыгын да онытмасак иде. Ни кызганыч, милләте өчен янып-көеп, аның мәнфәгатьләрен яклап, Конституциядә бирелгән хокукларыбыз үтәлешен һәм гаделлек таләп итүчеләрнең кыерсытылганнар арасында булуы – күңел кабул итә алмаслык хәл. Безне кыерсытырга теләүчеләр болай да инде чиктән ашкан. Шулар яклы булып, аларга кушылып, үзенең милли җанлы күренекле шәхесләрен суд юлларында йөртеп, штрафлар түләтеп яши торган тагын берәр ил бар микән бу дөньяда? Гомумән, югарыдан кушылганны үтиүти, безнең җитәкчеләребез үз халкын яклау түгел, үзләрен яклый алырлык та вәкаләтләре калмады бугай.

Мәктәпләрдә балаларга ана телендә укуларны тыйганда да, җитәкчеләребез каршылык күрсәтә алмыйча, ә депутатлар бер тавыштан яклап утырулары сәер хәл түгелмени? Җылы урыннарын саклап, хөрмәткә лаеклылар рәтендә буласылары килгәндә, ниләр генә эшләмәсләр бу түрәләр. Хәзерге депутатны халык фикере кызыксындырмый шул. Элек алар халык депутаты дип аталалар иде. Хәзер алар Дәүләт Думасы һәм Дәүләт Советы депутаты булгач, аларның кемгә хезмәт итүләре билгеле бит инде.

Мөхтәрәм язучыларыбыз Айдар Хәлим белән Фәүзия ханым Бәйрәмовага хәзергә кадәр дәрәҗәле Г.Тукай бүләге тапшырылмавы сәер хәл түгелмени? Инде арабыздан китеп барган, алтын бәһасенә торырлык Фәндәс әфәнде Сафиуллинга да дәүләт югарылыгындагы дәрәҗәле бүләкләр бирелмәве гаҗәп түгелмени? Марат ага Мөлеков җитәкчелегендәге милли хәрәкәттә катнашучылар тырышлыгы белән яулап алынган уңай нәтиҗәләр өчен, безнең җитәкчеләребез авызыннан берәр төрле җылы сүз ишетелмәве дә, гаҗәп хәл түгелмени? Машина алырга дип җыйган акчасын кызганмыйча, Америкага барып, референдум үткәргәндә катнашыр өчен халыкара күзәтчеләр алып килеп, референдум нәтиҗәләрен тулы көчкә ия булуын исбатлый алганы өчен, Илдус әфәнде Садыйковның җитәкчелек тарафыннан бер җылы сүз ишетә алмавы да гаҗәп хәл түгелмени? Татар иленең үзәгендә яшәп тә, шул ук милли хәрәкәт үзәген башка урын бирмичә генә, үзләренең эш биналарыннан куалап чыгару да, шулай ук сәер хәл түгелмени? Үз милләттәшләребезгә карата булган гаҗәп нәрсәләрне тиз генә санап бетерерлек түгел. Шулай булгач, кыерсытылган милләт хәлендә калганыбыз өчен, үзебез сәбәпче булабыз түгелме?

Бу илдә яшәүчеләргә карата куркыту, тыю, штрафлар түләү белән кыерсытулардан башка, хөрмәт, кешелеклелек, мәрхәмәт, изгелек гамәлләре дә булуы мөмкин түгел микән әллә дигән фикергә киләсең.

Күренекле язучының тарихи китабын экстремистлыкта гаепләп, бик зур штрафлар түләткәндә дә, яклап сүз әйтүче булмады. Яклау сүзе әйтсәң, үзең дә экстремист булып калуың бар бит.

Сүзебез “Әй, язмыш, язмыш” тапшыруы белән башланып киткән иде. Бер тапшыруда журналист, баш мөхәррир, хөрмәтле Илфат әфәнде Фәйзрахманов белән әңгәмәне яратып карап утырдык. Аның тормышында да фаҗигале хәлләр, якын кешеләрен югалту очраклары күп булган икән. Берничә генә журналисты белән, халык мәнфәгатьләрен күз алдында тотып, бигрәк тә авылларда яшәүче кыерсытылган халыкны яклап, булдыра алган кадәр ярдәмен күрсәтеп, ялагайланмыйча, гаделлек яклап яза бит ул. Шәхси газета редакторлары рәтләп ялларга да чыга алмыйча, хакимият ярдәменнән башка, үз көннәрен үзләре күреп яши.

Әгәр кулымнан килсә, шәхси газеталарның редакторларына чит ил машиналары бүләк итәр идем мин. Хөкүмәт үзе башкарып бетерә алмаганны башкаручы безнең кешеләр бит алар да. Нишләптер андыйларга дәрәҗәле исемнәр, хөкүмәт бүләкләре дә бирелми бугай. Югарыда әйтелгән “Әй язмыш, язмыш” тапшыруында Илфат әфәндедән дәрәҗәле исемнәре турында сорагач, андый исемнәрем юк, халык белә, Аллага шөкер, дигән иде. Анысы шулай, халык белә белүен, рәхмәтләрен дә җиткереп торалар. Ә нишләп хөкүмәт җитәкчеләре аларны читләтеп үтә икән? Алар да үз халкына хезмәт итүче, үз кешеләребез ләбаса. Саный китсәң, андый кыерсытылганнар бик күп әле.

Рәфкать ИБРАҺИМОВ.
Казан шәһәре.

Мәдәни тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

1 апрель – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).
2 апрель – Кече залда – Санкт-Петербургның Александр театры актеры, Россиянең халык артисты Н.Мартон башкаруында «Вертинский. Русский Пьеро» спектакль-концерты. Зур залда – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев).
3 апрель – Зур залда – Санкт-Петербургның Александр театры труппасы башкаруында «Маузер» спектакле (Х.Мюллер). Тимерьюлчылар мәдәният сараенда – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев).
5 апрель – «Хуш, авылым» (А.Җаббаров).
6 апрель – «Дон Жуан» (Жан-Батист Мольер).
7 апрель – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).
8 апрель – «Килә ява, килә ява...» (З.Хәким).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

7,8 апрель – «Царская невеста» (Н.Римский-Корсаков).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

1 апрель – 13.00, 19.00 – «Гомер буе сине көтәм» (И.Гали). 18.30 – «Беренче мәхәббәт» (И.Гали).
2 апрель – 12.00 – «Шах...Мат!» (Л.Сәләхетдинова). 17.00 – «Хыялый» (С.Әбүзәров).
3 апрель – «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов).
7,8 апрель – Премьера. «Мәдинә» (И.Зәйниев).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

1 апрель – 13.00 – «Бәхетле көнем» (Е.Гороховская). 18.30 – «Супер кияү» (Т.Миңнуллин).
2 апрель – «Сөннәтче бабай» (Г.Исхакый).
3 апрель – «Матур City» (А.Әхмәтгалиева).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

1 апрель – 11.00, 13.00 – «Приключения Чебурашки» (Э.Успенский), 19.00 – «Самовары» (Р.Таһиров).
2 апрель – 11.00, 13.00, 15.00 – «Маугли» (Р.Киплинг). 12.00 – «Кәҗә белән сарык» (Г.Тукай).
3 апрель – 10.00 – «Один день из жизни улитки» (Ольга һәм Юрий Устюговлар). 12.00, 14.00 – «Красная шапочка» (Ш.Перро). 13.00 – «Мактанчык әтәч» (Аманулла).
5 апрель – «Сны Диснея» (И.Зәйниев).
8 апрель – 11.00, 13.00 – «Малыш и Карлсон» (А.Линдгрен). 19.00 – «Әлфия» (И.Зәйниев).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

2 апрель – ДиДюЛя һәм камера оркестры концерты.
3 апрель – Балалар өчен «Бремен музыкантлары» музыкаль спектакле. 17.00 – «Веселая вдова» опереттасы.
5 апрель – Чаллы шәһәренең орган залында Оксана Шәйдуллина башкаруында «Для тебя!» дип исемләнгән концерт. Филармониянең концерт залында – җырчы Иркә концерты.
6 апрель – Никколо Паганининең 240 еллыгы уңаеннан Гайк Казазян концерты.
7 апрель – «Язгы солянка» концерты.
8 апрель – Татарстан Республикасы филармония джаз оркестры һәм Вероника Джиоева концерты.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

3 апрель – «Jazz-Famaly» дип исемләнгән концертта композитор, пианист, аранжировщик, мөгаллим Андрей Руденко баларны джаз музыкасын тыңларга өйрәтә һәм яратырга өнди. Джазның нечкәлекләрен тою сәләтен үстерү өчен оештырылган бу концертта музыкантның кызлары Мирослава белән Мария һәм Муса Яхин (фортепиано) катнаша.
7 апрель – Башкортстан Республикасы Милли симфоник оркестры концерты. Программада – З.Исмәгыйлев, Н.Җиһанов, Х.Әхмәтов, Ф.Яруллин, Л.Любовский, Р.Сабитов, Р.Кәлимуллин, В.Скобелкин, Л.Исмәгыйлева музыкалары. Дирижер – Дмитрий Крюков.
8 апрель – Башкортстан Республикасы Милли симфоник оркестры концерты. Дирижер – Дмитрий Крюков. Солист – Артур Назиуллин (кларнет). Программада – Г.Малер, А.А.Моцарт музыкасы.

Яшьнәр утың булсын

Күпләр икърар кылганча, каләм әһеле язучылык талантына гына түгел, кешелек талантына да ия булырга тиеш. Иҗатка тартылган Рашат Низамиев та мондый кыйммәтләрдән мәхрүм ителмәгән. Шунысы да әһәмиятле: аның рухәнә асылы башкалардан беркадәр аерылып тора. Мөгаен, шагыйрьнең үзенчәлекле язу рәвеше эчке табигатеннән киләдер.



Сүзне ихласлыктан башлыйк. Һәрбер кешене күркәм итеп күрсәткән әлеге хасият язу эшендә аеруча кирәкле нигъмәт булып санала. Шөкер, иҗатның нигезендә яткан күңел чынлыгы Рашат Низамига шактый мулдан бирелгән. Аның ихласлыгында балаларча садәлек тә, яхшы мәгънәсендәге беркатлылык та бар. Шулай тиеш, чөнки шагыйрь җанлы затка болары да бик килешә. Бу сыйфатлар тирәндә ята. Шәхеснең күзгә бәрелеп торган җитерәк билгеләренә килгәндә, аларның берсе Рашат Низамида аерата ачык күренә: монысы – тәвәккәллек. Хәер, әгәр вөҗүдеңә бераз дуамаллык катыш кыюлык салынмаса, бинаһая гайрәт чәчкән каләмне уйната алмас идең. Ул үзенең төрле әдәби геройларында да шушы үзлекне калкытыбрак чагылдырырга тели.

Болай тәфсилләп сөйләргә тулысынча хакым бар, чөнки Казан дәүләт университетында Рашат Низами белән бергә укыдым һәм шушы вакыттан бирле шәригемне үтәли күргәндәй якыннан беләм дип уйлыйм.

...Без инде дарелфөнүнне тәмамлап килә идек. Гел көтмәгәндә Рашат Үзәк Америкадагы Никарагуа Республикасы белән ихластан кызыксына башлады, аныграк әйткәндә, биредә озак еллар дәвамында тынмаган сугыш хәрәкәтләре төркемдәшебезне тәмам утка салды. Холкындагы тәвәккәллек калкынып куйгандыр, ул хәтта сандиночыларның милли азатлык фронтына иреклe яугир сыйфатында кушыларга теләп, шушы дуамал омтылышның чынга ашу-ашмавын төрле рәсми оешмалардан белешкәләп тә йөрде. Ай-һай! Совет хакимияте чорында моның ише «кайнар нокта»ларга «чикләнгән гаскәр» исәбендә генә барырга мөмкин иде.

Сугыш дигәннән ... Студент чакта кулына корал алырга омтылган Рашат Низамига дәһшәтле көрәш күренешләрен барыбер үзенчә сурәтләргә туры килде. Иҗади күзаллау ярдәмендә. Танылып килгән композитор Фәрит Яруллинның Бөек Ватан сугышына китеп баруы, тәвәккәллек факты буларак, гомер сынауларына битараф була алмаган язучы күңелендә хис-кичерешләр өермәсен кузгата. Озак уйланып йөргәннән соң, ул беренче татар балеты «Шүрәле»нең авторын үзәккә куеп, «Ут һәм җыр» исемле роман-хроника язу карарына килә.

Күренекле галимебез Тәлгать Галиуллин хаклы рәвештә искәртеп үткәнчә, «Рашат Низами – әдәбияттагы барлык жанрларны да «ияртергән» кеше». Сугышта шәһит киткән мәшһүр композиторның фаҗигале образы аны башкарак шәкелдәге әсәр язарга да этәрә. Монысы инде ике пәрдәле драма – «Җыр һәм мылтык» дип атала.

Гомумән, милли музыка дөньясы Рашат Низамины мавыктыргыч кимәлдә үзенә җәлеп итте. Аны башка бөек композиторларның язмышы да киң полотноны әсәрләр язарга рухландыра башлый. Халкыбызны төрле яклап зурлаган темаларга өстенлек биргән язучы Салих Сәйдәшев һәм Рөстәм Яхин турында материаллар туплый. Шул рәвешле «Сәйдәшнең соңгы елы» роман-кыйссасы һәм «Яшәүгә гимн» поэма-рапсодиясе дөньяга чыга. Салих Сәйдәшев, Фәрит Яруллин, Рөстәм Яхин... «Татар моңының өч йолдызы» дигән исем астында басылган китапта («Сүз» нәшрияты, 2016) Рашат Низаминың нәкъ менә шушы затларны олылаган әсәрләре тупланган. Документаль нигезгә корылган ошбу багышлаулар, һичшиксез, милләтебез шәхесләре галереясын яңача баетачак.

Талант, холык-фигыль, стиль... Әлеге категорик төшенчәләр үзара бәйләнгән. Иҗат белән шөгыльләнүчегә аларның һәркайсы зарур. Җан тынгысызлыгы да мөһим. Тыныч холыклылык язучыларга килешми. Бу яктан Рашат Низаминың эчке халәте мондый императив таләпкә тулысынча туры килә. Хәтерлим, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире урынбасары булып эшләгәндә дә ул искә төшкән саен тәнне чымырдатып куярлык тәвәккәллек кылды... Кемдер аның кабинетын тыштан бикләп киткән. Рашат озак уйлап тормый: 10 нчы каттагы тәрәзәдән тап-тар кәрнизгә җәһәт чыгып баса да шул чыгынты буйлап күрше бүлмәнең ачык тәрәзәсенә килә. Каләмдәшләре аңа Терекөмеш кушаматын тиктомалдан гына тагып куймагандыр.

Мин болар хакында нигә шулай җентекләп сөйлим соң?! Гадәттә, әдип үзенең язганына холкындагы асыл сыйфатларны яхшылап сеңдергән очракта гына, аның әсәре башкаларны һәрьяктан да тәэсирләндерерлек дәрәҗәдә килеп чыгарга мөмкин. Шунысы кыйммәт: Рашат Низами дөньяга нәкъ менә үз рухияте аша карарга омтыла, әлеге иҗтиһатның нәтиҗәсе буларак, тормыштан алынган беренчел тәэсирләр иң әүвәл шагыйрьнең тынгысыз күңелендә эшкәртелә. Эзләнүчән шәхеснең аерымлыгын билгеләүче җитә сыйфатлар, ниндидер әверелеш казанына эләгеп, иҗатта үзеннән-үзе романтизм башлангычының көчәюенә китерә. Аңа күпчелек очракта иҗтимагый, төгәлрәк әйткәндә, гомуммилли яңгырашлы төсмер бирелә. «Уч төбендә – яшен» дип исемләнгән шигырьләр һәм поэмалар җыентыгында да (Татарстан китап нәшрияты, 2020) Рашат Низаминың эчке табигате җирлегендә үзләшкән алымнар ап-ачык күренеп тора. Авторның байтак үзлекләргә ия темпераменты «Тормыш трамвае» шигырендә дә тоемлана.

Барган шәпкә сикердем дә
мендем,
Үз-үземә урын барладым...

Ашкынучан кеше болында пакусны киң алучан. Тереләгән һәрбер хәрәкәтендә ачык рәвештә сиздерткән Рашат Низами, искәртеп үтелгәнчә, сүз сәнгатенең байтак жанрында үз талантын күрсәтергә тырыша. Әдәби юнәлешләрне үзләштерер өчен генә дә пегас иясеннән никадәр җөрьәтлелек сорала. Шигъри иҗатта ул кош очар биеклеккә кадәр күтәрелсә, прозада ике аягы белән дә җирдә басып тора. Үз дигәненә омтылып эзләнү яңарак катламнарга китереп чыгара. Язучылык эшчәнлегенә кагылышлы бихисап сорауларга җавап биргән «Алдым каләм кулыма...» хезмәте (Татарстан китап нәшрияты, 2007) Рашат Низаминың чагыштырмача сирәк күтәрелгән темалар алдында да куркып калмавын күрсәтә. Аның «Яшьлеккә хат» дигән повесте да бик үзенчәлекле булуы белән игътибар казанды. «Әлеге фәлсәфи-публицистик, үгет-нәсыйхәткә корылган педагогик әсәрдә үтә кызыклы күзәтүләр, уй-фикерләр бар, – дип язды Марс Шабаев. – Мондый әсәр үзенә күрә бер феномен – безнең әдәбиятта әле моңа кадәр очрамаган бер күренеш».

Бөтен курыкканым – пыскып яшәү,
Яшим икән, яшьнәр утым булсын!..
(«Хакыйкатьне эзләгәндә»)

Күрәбез, үзенең яшәү шигарен яшьли үк билгеләп куйган Рашат Низами шушы мәсләгенә тормышта да, күпкырлы иҗатында да хыянәт итми. Мондый эшчәнлек хөрмәтләнергә тиеш. Һәрхәлдә, аның мәкаләмдә телгә алынган китаплары дәүләти югарылыкта зурлап бәяләнүгә лаек.

Зиннур МАНСУРОВ.

Аккан сулар кире кайтмый

Публицист, педагогик хезмәт ветераны, халык мәгарифе отличнигы Альберт Мөхәммәдулла улы Урамаевның "Аккан сулар кире кайтмый" повестеның беренче китабы үзе исән чакта чыккан иде. Бу китапның редакторы – педагогик фәннәр кандидаты Клим Садыйков авторның икенче китабын чыгаруда да ярдәм күрсәтә. Ул иңалыклары белән таныштырып: "Аккан сулар кире кайтмый" дип аталган беренче китапта Альберт Урамаев, үзенең нәселе белән бәйләп, Себер татарларының тормыш-көнкүрешләре аркылы XVI гасырның икенче яртысыннан XX гасырның беренче яртысына кадәр булган тарихи вакыйгаларны үз күзлегеннән чыгып сурәтли. Китапны укыганда, укучы авторның сүз байлыгын, табигатьне бик үзенчәлекле тасвирлавын тиз тоя ала. Себер татарларының җирле колоритын саклау максатыннан кайбер сүзләр, җөмләләр җирле татарларның сөйләм теле үзенчәлекләрен саклап бирелгән. Себер татарларының тарихында булган фаҗигале вакыйгаларны, монда яшәгән халыкның тормышын, гаилә традицияләрен, чыдамлыгын, бәхетле тормышка лаек булуларын автор Урамайлар токымы язмышы үрнәгендә күрсәтә. Китапның эчтәлеге туган якка һәм илебезгә мәхәббәт, патриотизм хисе тәрбияләүгә юнәлтелгән", – дип сөйләде.

Альберт Урамаевның икенче китабында тарихи хикәяләр нигезендә Бөек Ватан сугышы вакыйгалары, Саускан авылы халкының сугыш вакытында күргән авыр тормышы тасвирлана. Укучысын ул татар халкының гореф-гадәт йолалары белән дә таныштыра. Бөек ватан сугышы елларын, үз төбәгендәге вакыйгаларны җентекләп өйрәнеп, мәгълүмат туплап китаплар чыгарган ветеран укытучы Альберт Урамаевның хезмәте бәяләп бетергесез. Китапның һәр бүлегендәге геройлар укучыларның игътибарын җәлеп итә, аларда кызыксыну уята. Бу китаплар рус теленә дә тәрҗемә ителсә, башка милләт вәкилләре өчен дә кызыклы, файдалы һәм кирәкле булыр иде. Яшь буын Себер ягыннан чыккан язучыларыбызны белеп, аларның иҗади хезмәтләрен, яңа китапларын укып үссеннәр иде, дигән теләген белдерде мөхәррир.



Клим абый сүзен дәвам итеп: "Кызганычка, Альберт абый белән яңа чыккан китабы турында сөйләшеп, аны котлап, шатлыгы белән уртаклашырга мөмкин түгел. Ул исән чагында китапны бастырып өлгермәдек. Аны укучылары да, якыннары да сагынып искә ала. Аның иҗат иткән китаплары бүгенге көндә дә актуаль. "Аккан сулар кире кайтмый" – тарихи повесть, шушы җирлектә яшәүче халкыбыз һәм яшьләр өчен бик кирәк", – диде.

Римма ӨМЕТБАЕВА.
Түмән өлкәсе.

Гел беренче

Хәзер Кытай банклары, клиентларга биргәнче, акчаны ультрашәмәхә нурлар һәм югары температура белән йогышсызландырырга, аннары 7-14 көн сакларга тиеш. Хастаханә һәм базар кебек аеруча хәвефле урыннардан кергән акча махсус эшкәртелә һәм, әйләнешкә кертелмичә, кабат Үзәк банкка җибәрелә. Акча җитәрлек булсын өчен, банк әледән-әле яңа купюраларны күпләп әйләнешкә кертә. Былтыр гыйнварда, мәсәлән, Уханьда банк 4 миллиард юаньны өр-яңа купюраларга алыштырып биргән. Кытай дөньяда кәгазь акча куллана башлаган беренче дәүләт санала һәм, мөгаен, купюралардан баш тарткан беренче ил дә булачактыр. Тәүге кәгазь банкноталар биредә XI гасырда, Сун династиясе хакимлек иткән чорда бастырылган һәм ун гасыр буе - 2014 елга кадәр популяр булган. Ә шуннан соңгы өч ел эчендә илнең күпчелек халкы мобиль платформаларга күчеп беткән – 2017 елда смартфон аша түләүләр әйләнеше инде 5,5 триллион сум тәшкил иткән, бу АКШтагыдан 50 тапкырга артыграк. Әлеге җәһәттән Европада иң алдынгылардан саналган Финляндиядә бөтен түләүләрнең 42 проценты, ахыргы урындагы Мальтада исә 92 проценты кулдагы акча белән башкарыла. Кытайда, акча күчерү өчен, QR-кодны сканерлап алу җитә. Акча банктагы исәп-хисап счетына бәйләнгән мобиль аппаратта янчыкта саклана. QR-кодлардан файдалану бик ансат, ул сәүдәдә дә, транспорт яллау хезмәтләрендә дә, ТКХ һәм медицина хезмәтләре өчен түләүдә дә кулланыла. Хәтта авыллардагы теләсә кайсы базарда да фермерларга QR-код аша түләп була.

(“Синьхуа”).

Тузган акча кызыктырган

Англиядә 1963 елның 8 августында почта поезды талану турында инде әллә ничә китап язылган, берничә фильм төшерелгән, тик ул һаман игътибар үзәгендә әле. Банданы антиквариат кибете хуҗасы, 32 яшьлек Брюс Рейнольдс оештырган. Ул аңарчы да бер ун тапкыр җинаять җаваплылыгына тартылган булган инде. Брюс тузган купюралар төялгән поездның әледән-әле Шотландиядән Лондонга баруы турында төрмәдә белеп алган. Англия банкында акчаларның саннарын кучереп язалар һәм аннары яндыралар икән. Номиналы 1 дән 5 фунтка кадәр купюралар төялгән почта вагоны аена бер тапкыр Глазго-Лондон составына тагыла. Шундый көннәрнең берсендә унбиш бандитның берсе, иртәнге сәгать 3 тә семафорга менеп, аның яшел “күзен” кара пакет белән каплаган да, үз фонаре белән башта сары, аннары кызыл ут яндырып, составны туктаткан. Тимер юл эшчеләре булып киенгән талаучылар, инкассаторларны бәйләп, 120 капчык акчаны алып киткән, анда барлыгы 2 миллион фунт стерлинг (хәзерге 46 миллион фунтка тәңгәл) акча булган. Тиз арада банданың эзенә төшкәннәр һәм барысын да кулга алганнар, тик менә акчаның күп өлешен тапмаганнар. Ун елга хөкем ителгән Рейнольдс, 1978 елда ирекккә чыкканнан соң, язучылар һәм кинорежиссерлар белән бик теләп аралашкан, 2013 елда 81 яшендә дөнья куйган.

(“Интересно.cc”).

Вакытында ашау зарур

Калифорниядәге Солк институты галимнәре озак яшәү өчен сәламәт туклану гына җитмәвен ачыклаган. Әле билгеле бер вакыт аралыгында ашау да мөһим. Иртәнге аш сәгать 8дә икән, соңгы, кичкесе белән арасы ун сәгатьтән артмаска тиеш – димәк, анысы кичке сәгать 6да булу зарур. Галимнәр аңлатуынча, организмда циркада ритмнары бар, алар төрле вазифаларны активлаштыру, шул исәптән ашкайнату һәм күзәнәкләрне “ремонтлау” өчен җаваплы. Өлкәнәйгән саен, циркада ритмнары бозыла һәм организм ризыкны эшкәртү яки метаболизм функцияләрен үтәү вакытларын мөстәкыйль көйли алмый башлый. Шул рәвешле әлеге тайпылыш төрле чирләр китереп чыгара. Сәламәтлекне саклау өчен, галимнәр ризык кабул итүне ун сәгатьлек интервал белән чикләргә тәкъдим итә дә инде. Биоритмнар бозылуга карамастан, бу гомерне озайту мөмкинлеге бирә. Үз теорияләрен дәлилләр өчен, тикшеренүчеләр тычканнар белән тәҗрибә үткәргән. Кимерүчеләрнең циркада ритмнарын “сүндереп”, ике төркемгә бүлгәннәр. Беренче төркем тәүлекнең теләсә кайсы вакытында тукланган, икенче төркемдәгеләренә азык ун сәгать кысаларында гына бирелгән. Рационның составы да, калориялелеге дә бер үк төрле булган. Бераз вакыттан соң беренче төркемдәге тычканнарда әллә никадәр чир табылган, икенче төркемдәге кимерүчеләрнең сәламәтлеге исә яхшырганнан-яхшырган. Галимнәр якын киләчәктә теорияне кешедә дә сынап карарга җыена.

(“The New York Times”).

Күңел тапмак бер калҗа

Тормышның аеруча мөһим мизгелләрендә кешенең кинәт кенәниндидер ризык ашыйсы килеп китә. Мондый омтылышны психологлар болай аңлата. Әгәр кишер кимерәсе килә икән, димәк, кешенең эче поша. Әчкелтем ризык татып карыйсы килү – күңелдә эгоизм хисе уянуга ишарә. Салкын һәм каты ризык белән сыйланасы килү кешедәге тынычсызлыкны, ниндидер хәвеф көтүне аңлата. Алманы – хезмәт дәрте кабынганда, кәбестәне – искиткеч саранлык уянганда, бәрәңгене – чит кеше фикеренә колак салганда, помидорны – тормыш мәгънәсе балаларда һәм гаиләдә икәнне аңлаганда ашыйсы килә, имеш. Җир җиләге белән сыйлану теләге зәвык уянганда туа. Баклажан һәм татлы борычны күпләп ашый башлау максатка омтылучан чакка туры килә. Баллы ризык күңелдә тыелгысыз хисләр кайнаганда бик кирәк. Әгәр һәр эш уңа, горурлык чиктән аша икән – тозлы ризык белән сыйланыр чак. Үзеңне ялгыз,беркемгә кирәксез итеп тойганда исә сыек шулпа эчеп юану табып була.

(“Die Presse”).

● Кристалл мәчет.

● Иерусалимдагы Куббат әс-Сахра мәчете күчермәсе.

● Истанбулдагы Сөләйман мәчете репликасы.

Малайзиядәге Кол Шәриф

Малайзиянең Куала Теренгану штатындагы Пулай Ван Манн утравында 2008 елдан бирле Ислам цивилизациясе паркы эшли, анда дөньяның төрле почмакларында урнашкан иң матур мәчетләрнең реплика-макетлары төзеп куелган. Алар арасында әл-Харам (Согыд Гарәбстаны, Мәккә), әл-Әкъса (Фәләстин, Иерусалим), Таҗ Махал (Һиндстан), әл-Һамбра (Испания), Солтан Сөләйман мәчете (Төркия, Истанбул), Сәйфеддин мәчете (Бруней) һәм тагын дистәдән артык җәүһәрнең күчермә-репликалары, ә иң куандырганы – андагы пальмалар янәшәсендә безнең Кол Шәриф мәчетенең 10 метрлы макеты да бар. Бу паркта мөселман дөньясындагы иң гаҗәеп гыйбадәтханәләрдән берсе – Кристалл мәчет урнашкан, иң биек манарасы 42 метрлы бинаны ике ел эчендә төзеп куйганнар. Тимер-бетон корылма тулысынча көзгеле пыяла белән капланганга, мәчет көндез кояш нурларында искиткеч матур булып балкып утыра, төнлә исә төрле төстәге утлары белән җемелдәп әллә кайдан күренеп тора. Израильдәге 687-691 елларда төзелгән Куббат әс-Сахра (“Кыя гөмбәзе”) мәчетенең архитектура күчермәсе, оригиналыннан дүрт тапкырга кечерәк булса да, шулай ук искиткеч гүзәл. Төркиядәге Сөләйман мәчете репликасы 1:11 масштабында, бөтен пропорцияләр һәм детальләрне саклап салынган. Дүрт манарасы бар, зур гөмбәзне ике кечерәге тотып тора.

(“Islamnews”).

● Казандагы Кол Шәриф мәчете макеты.

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

4 апрель
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 16.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 17.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Уймак» һәм «Сәйлән».
17.30 «Трибуна «Нового Века». 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.00 Документальный фильм. 12+
23.50 «Каравай». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «МОСКОВСКАЯ ПЛЕННИЦА». 12+
10.25, 21.00 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «СЕРДЦЕЕД». 16+
14.30 «Дорога в космос». 12+
15.00 «Еда здорового человека». 12+
15.30 «Мечтатели». 12+
16.20 «Четверо в кубе».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «ЛЕТО ВОЛКОВ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.25, 12.15, 15.15, 18.20, 0.00 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «НИКТО НЕ УЗНАЕТ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Владимир Малышев.
7.35 «Владимир Котляков. Время открытий».
8.15 Дороги старых мастеров. «Гончарный круг».
8.35 «ДОЧЕНЬКА».
9.50 Цвет времени. Пабло Пикассо. «Девочка на шаре».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Эхом нашей юности была... Майя Кристалинская».
12.15 «Забытое ремесло».
12.35 «Интернет полковника Китова».
13.20 Линия жизни. Михаил Мишин.
14.15 «Борис и Ольга из города Солнца».
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «АНДРЕЙ РУБЛЕВ».
16.50 «Агора».
18.45 «Шигирский идол».
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Даниил Давыдов. «Цивилизация подземелий».
20.45 90 лет со дня рождения Андрея Тарковского. Острова.
21.40 «Сати. Нескучная классика...»
22.25 «СТРАЖА».
23.10 «Афиша - документ истории».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ». 16+
13.30 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЧИНГАЧГУК». 16+
23.45 «ПЁС». 16+

Сишәмбе

5 апрель
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Уймак» һәм «Сәйлән».
16.00, 21.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
23.00 Документальный фильм. 12+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛЕТО ВОЛКОВ». 16+
10.30, 21.00 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «КУРЬЕР ИЗ «РАЯ». 12+
14.35 «Дорога в космос». 12+
15.00 «Инвиво». 12+
15.30 «Афганистан. Неизвестная война инженерных войск». 12+
16.15 «Четверо в кубе».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.25, 12.15, 15.15, 18.20, 0.00 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «НИКТО НЕ УЗНАЕТ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Шигирский идол».
8.15 Цвет времени. Павел Федотов.
8.35 «ДОЧЕНЬКА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Леонид Александрович Говоров».
12.20 Цвет времени. Анри Матисс.
12.35 «Предки наших предков».
13.20 «Игра в бисер» «Лев Толстой. «Холстомер».
14.05 Острова. Андрей Тарковский.
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «АНДРЕЙ РУБЛЕВ».
17.10 Цвет времени. Жан Этьен Лиотар. «Прекрасная шоколадница».
17.20 «Сергей Рахманинов. Очарованный Россией».
18.35 «Кровь кланов».
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Ольга Свиблова. «Искусство: здравый смысл и социальные сети».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 «Андрей Рублев». Начала и пути».
21.40 «Белая студия».
22.25 «СТРАЖА».
23.10 «Афиша - документ истории».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ». 16+
13.30 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЧИНГАЧГУК». 16+
23.45 «ПЁС». 16+

Чәршәмбе

6 апрель
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 16.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+
11.00, 0.15 «Каравай». 6+
11.30, 17.00 «Татарлар». 12+
12.00 «СВОИ 2». 16+
13.00, 0.40 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Шома бас» һәм «Сәйлән».
17.30 «Трибуна «Нового Века». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 23.50 «Соотечественники». 12+
22.10 «ГОРЯЧИЙ СНЕГ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
9.40 «Йөрәктән - йөрәккә». Равил Шәрәфиев турында телеочерк. 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Юлчы». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛЕТО ВОЛКОВ». 16+
10.30, 21.00 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ДИКАРЬ». 16+
14.45 «Наша марка 2». 12+
15.00 «Без химии». 12+
15.30 «Афганистан. Неизвестная война инженерных войск». 12+
16.15 «Четверо в кубе».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.25, 12.15, 15.15, 18.20, 0.00 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «НИКТО НЕ УЗНАЕТ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.35 «Кровь кланов».
8.35, 16.35 «И ЭТО ВСЁ О НЁМ».
9.50 Цвет времени. Альбрехт Дюрер. «Меланхолия».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Искатели кладов».
12.20 Дороги старых мастеров. «Балахонский манер».
12.35 «Предки наших предков».
13.20 Искусственный отбор.
14.00 «Забытое ремесло».
14.15 «Андрей Рублев». Начала и пути».
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
17.50 Сергей Рахманинов. Избранные сочинения. «Колокола». Владимир Спиваков, Национальный филармонический оркестр России, Академический Большой хор «Мастера хорового пения».
19.45 Главная роль.
20.05 Абсолютный слух.
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 «Солярис». Ну вот, я тебя люблю».
21.40 Власть факта. «Реформация и козни «нечистой силы».
22.25 «СТРАЖА».
23.10 «Афиша - документ истории».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СЕВЕРНЫЕ РУБЕЖИ». 16+
13.30 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЧИНГАЧГУК». 16+
23.45 «ПЁС». 16+

Пәнҗешәмбе

7 апрель
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00 «СВОИ 2». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник» һәм «Сәйлән».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.10 «ИДИ И СМОТРИ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Калеб». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛЕТО ВОЛКОВ». 16+
10.30, 21.00 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ЛЮБОВЬ ВРАЗНОС». 16+
14.30 «Дорога в космос». 12+
15.00 «Еда здорового человека». 12+
15.30 «Афганистан. Неизвестная война инженерных войск». 12+
16.15 «Четверо в кубе».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.25, 12.15, 15.15, 18.20, 0.00 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «НИКТО НЕ УЗНАЕТ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 Лето Господне.
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.35 «Кровь кланов».
8.35, 16.35 «И ЭТО ВСЁ О НЁМ».
9.50 Цвет времени. Жорж-Пьер Сёра.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Мастера искусств. Борис Чирков. Народный артист СССР».
12.20 «Забытое ремесло».
12.35 «Предки наших предков».
13.20 Вспоминая Виктора Татарского. Линия жизни.
14.15 «Солярис». Ну вот, я тебя люблю».
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Пряничный домик. «Дулевская роспись».
15.45 «2 Верник 2».
17.50 Сергей Рахманинов. Избранные сочинения. «Элегическое трио». Дмитрий Махтин, Александр Князев, Борис Березовский.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга.
20.30 Цвет времени. Рене Магритт.
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 «Зеркало» для режиссёра».
21.40 «Энигма. Герберт Блумстедт».
22.25 «СТРАЖА».
23.10 «Афиша - документ истории».

«НТВ»
4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
8.25 «Простые секреты». 16+
9.00 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
10.35 «ЧП. Расследование». 16+
11.10 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СЕВЕРНЫЕ РУБЕЖИ». 16+
13.30 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.50 «ДНК». 16+
20.00 «Жди меня». 12+
21.00 «Страна талантов». 12+
23.40 «Своя правда». 16+

Җомга

8 апрель
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30, 16.30, 21.00 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «СВОИ 2». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Рыцари вечности». 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Төймә» һәм «Сәйлән».
16.00 «Мин». 12+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10 «Туган җир». 12+
20.00, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛЕТО ВОЛКОВ». 16+
10.30, 21.00 «УЛЫБКА ПЕРЕСМЕШНИКА». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «ОБЛАСТИ ТЬМЫ». 16+
14.50 «Наша марка 2». 12+
15.00 «Инвиво». 12+
15.30 «Афганистан. Неизвестная война инженерных войск». 12+
16.30 «Четверо в кубе».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.25, 12.15, 15.15, 18.20 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
22.00 «Голос. Дети».
23.40 «АРТИСТ». 12+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Кровь кланов».
8.35, 16.45 «И ЭТО ВСЁ О НЁМ».
9.45 «Первые в мире».
10.15 «НОВЫЙ ГУЛЛИВЕР».
11.35 «Казань. Дом Зинаиды Ушковой».
12.00 Открытая книга.
12.35 «Предки наших предков».
13.20 Власть факта. «Реформация и козни «нечистой силы».
14.00 «Забытое ремесло».
14.15 «Зеркало» для режиссёра».
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Герберт Блумстедт».
16.15 «Ростов-на-Дону. Особняки Парамоновых».
17.55 Сергей Рахманинов. Избранные сочинения. Александр Сладковский, Государственный академический симфонический оркестр Республики Татарстан.
18.45 «Билет в Большой».
19.45 «Смехоностальгия».
20.15 Линия жизни. Виктор Добронравов.
21.15 «ИВАНОВО ДЕТСТВО».
22.45 «2 Верник 2».

«НТВ»
4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
8.25 «Простые секреты». 16+
9.00 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
10.35 «ЧП. Расследование». 16+
11.10 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СЕВЕРНЫЕ РУБЕЖИ». 16+
13.30 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.50 «ДНК». 16+
20.00 «Жди меня». 12+
21.00 «Страна талантов». 12+
23.40 «Своя правда». 16+

Шимбә

9 апрель
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Мин». 12+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «Созвездие - Йолдызлык-2022». 6+
14.40 «Үткәннәрне барлап...» 6+
15.40 «КАЗАНГА КАЗАНДА». 12+
17.00 «СТЕНДАПханә». 16+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБиТ- шоу». 12+
23.00 «СИБИРСКИЙ ЦИРЮЛЬНИК». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Шагыйрьләрдән дә шагыйрьрәк». Айрат Арсланов турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.10 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.05 Дания Нуруллинаның юбилей кичәсе. 6+
14.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.40 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 Зөфәр Хәйретдиновның 60 яшьлек юбилей кичәсе. 6+
23.20 Спектакль «Өти балак Гөлүзә». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Еда здорового человека». 12+
5.30 «Дорога в космос». 12+
6.30 «Опыты дилетанта». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Джинглики».
8.00, 14.45 «Наша марка 2». 12+
8.15 «АЛЕШКИНА ЛЮБОВЬ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ДОЛГОЕ ПАДЕНИЕ». 18+
15.00 «Все, кроме обычного». 16+
16.00, 18.10 «УЛЕТНЫЙ ЭКИПАЖ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЛЮБОВЬ И СТРАСТЬ. ДАЛИДА». 16+
23.10 «Человек - невидимка». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
10.15 «АнтиФейк». 16+
11.05, 12.15, 15.15 «ДНИ ТУРБИНЫХ». 12+
15.50 «Кто хочет стать миллионером?»
17.05 «Человек и закон». 16+
18.20, 22.00 «ШИФР». 16+
21.00 «Время».
23.35 «ВАН ГОГ. НА ПОРОГЕ ВЕЧНОСТИ». 16+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.35 «НЕВЕСТА КОМДИВА». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «МАЛЬЧИК МОЙ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 «Кот Леопольд».
8.40 «ПУТЕШЕСТВИЕ МИССИС ШЕЛТОН».
10.15 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
10.45 Неизвестные маршруты России. «Бурятия. От Улан-Удэ до Белого камня».
11.25 «ИВАНОВО ДЕТСТВО».
13.00 «Брачные игры».
13.55 «Дом ученых». Артем Оганов.
14.25 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.20 Концерт Кубанского казачьего хора в Государственном Кремлёвском дворце.
16.35 «ШУМНЫЙ ДЕНЬ».
18.10 Больше, чем любовь.
18.55 «Музей Прадо. Коллекция чудес».
20.25 «СОВСЕМ ПРОПАЩИЙ».
22.00 «Агора».
23.00 «ПАЦИФИСТКА».

«НТВ»
5.05 «Хорошо там, где мы есть!»
5.30 «КУРКУЛЬ». 16+
7.20 Смотр.
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «Готовим с Алексеем Зиминым».
8.50 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00 «Что могут экстрасенсы?» 12+
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «По следу монстра». 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.30 Ты не поверишь!. 16+
21.30 «Секрет на миллион». 16+
23.40 «Международная пилорама». 16+

Якшәмбе

10 апрель
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Пар алма». Илназ Баһ һәм Гүзәл Идрисова концерты. 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Полосатая зебра».
9.00 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Тархан». 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент.Общество». 12+
13.30 «Созвездие - Йолдызлык-2022». 6+
14.40 «Үткәннәрне барлап...» 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Соотечественники». 12+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «ЗАКОНЫ ПРИВЛЕКАТЕЛЬНОСТИ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.35 «Нәсыйхәт». 6+
6.00, 13.00 «Татарлар». 12+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00, 16.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
8.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Айрат Арсланов турында телеочерк. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп әйрәник». 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы». 12+
14.05 Спектакль «Син бит минем бергенәм». 12+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «СТЕНДАПханә». 16+
21.40 Спектакль «Мулла». 6+

«ЭФИР»
5.00 «Инвиво». 12+
5.30 «Дорога в космос». 12+
6.30 «Опыты дилетанта». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Джинглики».
8.00 «Кондитер». 16+
9.00, 11.10 «УЛЕТНЫЙ ЭКИПАЖ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЛЮБОВЬ И СТРАСТЬ. ДАЛИДА». 16+
15.15 «АЛЕШКИНА ЛЮБОВЬ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ДОЛГОЕ ПАДЕНИЕ». 18+
22.45 «Человек - невидимка». 16+
23.40 «МУЖЧИНЫ ПРОТИВ ЖЕНЩИН». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.35, 6.10 «ХИРОМАНТ». 16+
6.00, 10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
6.30 «ХИРОМАНТ. ЛИНИИ СУДЕБ». 16+
8.20 «Часовой». 12+
8.50 «Здоровье». 16+
10.15, 12.15, 15.15, 18.20 «МОСГАЗ». 16+
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»
23.45 «А напоследок я скажу». 12+

«РОССИЯ»
5.10 «НАРОЧНО НЕ ПРИДУМАЕШЬ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.35 «НЕВЕСТА КОМДИВА». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.40 «ШУМНЫЙ ДЕНЬ».
9.15 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
9.45 «Мы - грамотеи!»
10.25 «СОВСЕМ ПРОПАЩИЙ».
12.00 Письма из провинции.
12.30 Диалоги о животных.
13.10 Невский ковчег. Теория невозможного. Лидия Зверева.
13.40 «Игра в бисер» «Поэзия Беллы Ахмадулиной».
14.25 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.10 XV Зимний международный фестиваль искусств в Сочи. «Фантастическая Кармен». Режиссер П.Сафонов.
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Пешком...»
17.40 «Вадим Шверубович. Честь имею».
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «СТАЛКЕР».
22.45 Венский оркестр Иоганна Штрауса. «Музыкальное путешествие по Австрии».

«НТВ»
4.50 «ПОЛУЗАЩИТНИК». 16+
6.25 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.40 «Маска». 12+
23.40 «Звезды сошлись». 16+

ТУГАН АВЫЛ ҖЫЛЫСЫ

Балтач районының Чапшар авылында шаржлар остасы, журналист, музыкант Зөлфәт Хәйруллинның 65 яшьлек юбилеена багышланган кичә үтте. Аны клуб мөдире Гүзәлия Вәлиева һәм Зөлфәтнең классташлары оештырган иде.

«Чапшар сигезьеллык мәктәбен тәмамлап, авылдан Казанга чыгып киткәнгә дә быел 50 ел тула. Ә авылдашларым белән элемтәнең өзелгәне юк, гел хәбәрләшеп торабыз. Туган авылымны бик яратам. Йокларга ятсам, уйларым белән авыл урамнары буйлап йөрим, кешеләре белән сөйләшә башлыйм. Авылдашларымнан килгән рәхмәтләр белән инде икенче дәфтәрем тула, остазларым Гәрәфи Гаязов, Моратхан Шакиров, Тарих Ситдиковларны, дусларым Фәргәт Мөхәммәтҗанов, Дамир Хисамовларны сагынып искә алам», – ди Зөлфәт Әнәс улы.

Кичәдә Гөлфирә Мәннанова З.Хәйруллинның «Авылым урамы» дигән җырын башкарды, ә Илхан Шакиров аңа баяны белән кушылды. Чапшар авылы музыканты Байронның баянда уйнавы, аның улы актер Раушан Ситдиковның чыгышы ямь өстенә ямь булды. Элеккеге җырчылар Нәзирә Фәйзрахманова, Флүсә Котдусова җырлавын да халык алкышлар белән каршы алды. Фәргәт Гаязов, Мансур Сәләхов да гармуннарында сыздырды. Авылның атаклы музыканты, гармунчысы Гаязов Гәрәфи абый белән Зөлфәт Әнәс улы бик дус булган. Зөлфәт хәзер дә дусты турында матбугатта язып, искә алып тора. Гаязовлар нәселе, этиләре исеменнән Гәрәфи абыйның балалары юбилярны аерым килеп котлады.

Чапшар авылының Гүзәлия Вәлиева җитәкчелегендәге бөтен республикага танылган, «Энҗекәй» бию төркеме, авылның олылардан гына торган «Яшьлек» фольклор ансамбле дә матур чыгышлары белән сөендерде.

Бәйрәмгә шулай ук Таузар авылыннан Шамил Усманов, Шәмәрдәннән Руфинә Мозаффарова, Яңгулдан Рузилә Габдрахманова, Мирзән авылыннан Басир әфәнде кебек оста гармунчылар, җырчылар да килгән иде, аларны да халык алкышлады, сәхнәдән дә төшермәде.

Кичәдә Балтач мәдәният идарәсе башлыгы Илназ Петров район хакимияте башлыгы Рамил Нотфуллинның Рәхмәт хатын тапшырды. Шуннан соң мәктәп укучылары «Чапшарда торсаң иде» дигән җыр башкарды. Зилә Зиннәтуллина, Кәрим Кәбиров, Фирүзә Мадиярова бик матур итеп З.Хәйруллин шигырьләрен сөйләде. Зөлфәтне шулай ук классташлары да котлады.

Зөлфәт Әнәс улының рәсем-шаржлары газеталарда атна саен диярлек басылып тора. З.Хәйруллин шарж сәнгатенә гомерен багышлады. «Дусларым, дус-ишләрем» дигән шаржлар китабы чыкты, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтында «Дусларча шаржлар» галереясы ачылды.

Рамазан ФӘРЗИЕВ,
Россия инвалидлар җәмгыятенең Балтач бүлеге рәисе.

Россиядә Мәдәни мирас елы уңаеннан Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының сәнгать белеме үзәге Америкада яшәүче композиторыбыз Мәсгудә Шәмсетдинова белән очрашу оештырды. Анда Казан дәүләт консерваториясе, музыка көллияте, Мәдәният һәм сәнгать институты мөгаллимнәре, Мәдәният өлкәсендә традицияләрне саклау һәм инновацияләр кертү ресурс үзәге белгечләре, рәссамнар, студентлар катнашты.

Бишек көйләрендә галәм аһәңе

М.Шәмсетдинованың тормышы вә иҗаты күпләрне шаккатыра. Башкортстанның Кышлау елга авылында туып-үскән кызның, алты яшендә әтисез калгач, Казахстанга әнисенең бертуган сеңлесе янына яшәргә күченүе тормышка ашмаслык хәл кебек, чөнки ул елларда авылдан чыгып китүе бик авыр булган. Әнисенең бертуганы да мең михнәт белән шахталарга чыгып киткән. Нык бәдәнле Мәсгудәне спорт мәктәп-интернатына бирергә дип барганда ялгыш тукталышны үтеп, нәкъ музыка мәктәбе янында төшүләре кызык тоела. Әмма шул ялгышулары кызның язмышын хәл итә. Казахстанда музыка мәктәбе, училище тәмамлаганнан соң кире Башкортстанга эшкә юллама алса да, М.Шәмсетдинованың Казан консерваториясенә килеп имтихансыз укырга керүе һәр кешенең гомерендә була торган хәл түгел. Композиция бүлегендә укуын тәмамлагач Казан киностудиясендә тавыш режиссеры булып, «Әкият» курчак театрында музыкаль бүлек мөдире, Казан телевидениесендә музыкаль тапшырулар редакторы, Казан дәүләт консерваториясе каршында Идел буе халыклары музыкасы кабинеты мөдире булып эшләгәннән соң, бер елга якын Швециянең Стокгольм шәһәрендә фольклор буенча стажировка үтүе дә тикмәгә генә булмаган икән. Ниһаять, танылган музыка белгече Йолдыз Исәнбәтнең утыз елдан артык мөнәҗәт, бәетләр җыйган белгечкә, син фольклор буенча эшләргә тиеш, дип хәер-фатихасын бирүе М.Шәмсетдинованың иҗат юнәлешен билгели. Санкт-Петербург университетында фәлсәфә фәннәре кандидаты дәрәҗәсендә кандидатлык диссертациясе яклаган М.Шәмсетдинова – татарда бердәнбер. Нева буйларыннан илһамланып кайткач, бер җирдә бернинди эш таба алмыйча илле яшьләрендә гаиләсе, ике улы белән Американың Сиэтл шәһәренә яшәргә китүе бер яктан, милли талантларыбызның никадәр кадерсез булуын күрсәтсә, шул ук вакытта кыю, башбирмәс композиторга карата соклану хисе уята. Чил илдә тел өйрәнеп, тәрҗемәче белгечлеге алганнан соң, М.Шәмсетдинова музыка буенча лекцияләр укый. Иң куандырганы – музыкаль фольклорны таныту эшен дәвам итүе. Моның өчен композитор радиоалгычлы tatars.com интернет сайтын булдыра. Бер үк вакытта дөнья халыкларының бишек җырларын җыю белән мәшгуль булуы билгеле. Сиэтлда фестивальләр дә узган, бишек җырларыннан лазер-тәлинкә дә чыгарганнар. Композиторның зур хыялы – күп еллар җыйган җырларын бишек җырлары музеена тапшыру. Әлегә бу байлык lullaby.com сайтында тупланган. Теләүчеләр шунда ук анкета тутырып, үз җырларын тәкъдим итә ала.

Очрашуда М.Шәмсетдинова татар музыкаль мирасының бәһасез байлык булуын тагын бер кат ассызыклады, аны саклау, кадерләү, тарату кирәклеген искәртте. Бишек җырларыннан рухи көч алуын әйтте.

Музыка белгече Гүзәл Юнысованың композитор М.Шәмсетдиновага һәм аның иҗатына карата мөнәсәбәтен белүе күпләргә кызык тоелгандыр. «Мәсгудә Шәмсетдинова консерваториягә укырга килгәч үк ирек сөюе, баш бирмәслеге, үзен тыныч тотуы белән игътибарымны җәлеп иткән иде. Бүген байтак музыкант, композиторларыбызның иҗатлары сүлпәнәйгән вакытта М.Шәмсетдинованың актив иҗат итүе шулай ук рух ныклыгын күрсәтә», – диде галимә. Г.Юнысова «Сөембикә турында бәет»нең премьерасын сокланып искә алды. 1990 еллар башында беренчеләрдән булып Казанны алу темасына мөрәҗәгать иткән композиторның иҗатына матбугатта зур бәя көтсә дә, рецензентларның әсәрдә яхшылык һәм яманлык көрәше генә күрүе күпләрнең, шул исәптән Юнысованың да кәефен кыра. М.Шәмсетдинова «Сөембикә турында бәет»тә үзе дә сәхнәгә чыгып, тамашачыны таң калдыра. Андагы тавыш, актерлык осталыгы! Композитор тикмәгә генә утызлап спектакльгә музыка иҗат итмәгән икән. Ул бизәгән спектакльләр арасында «Кара чикмән», «Җирән Чичән һәм Карачәч-сылу», «Эзләдем, бәгърем, сине...» кебек татар театр сәхнәсенә яңалык алып килеп, тарих битләренә уелып калганнары һәм «Итил суы ака торур», «Ак калфак» кебек халыкара бәйгеләрдә бүләкләнгәннәре дә бар.

Композитор М.Шәмсетдинованың беренчеләрдән булып Ибн-Фадлан, Чыңгызхан шәхесләрен үзәккә алып симфонияләр иҗат итүе шулай ук иҗат колачын чамаларга мөмкинлек бирә. Иҗатының зурлыгын белү өчен, «Корбан бәйрәме» мистериясе, «Адәм балалары» кантатасы, «Көмеш кашык болытта» балеты, «Дастан» симфоник поэмасы, «Кадер киче» балет ораториясе, «Дәрвиш» симфоник поэмасы һ.б. әсәр исемнәреннән күз йөртеп чыгу да җитә. Музыкаль фольклор белән шөгыльләнүендә унбер яшеннән мөстәкыйль яшәргә мәҗбүр булган композиторның үзенә терәк-таяныч, җанына җылы эзләвен, көч өстәргә омтылуын чамалау авыр түгел.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

КАЗАН ӨСТЕНДӘ ЯКТЫ АЙ

● Анатолий Егоров.

●«Н.Фешин» гобеленының урта өлеше.

Татарстанның халык рәссамы, атказанган сәнгать эшлеклесе Анатолий Егоров «Казан өстендә якты ай» гобеленнар шәлкеме өчен республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим ителде. Бу рәссамның үзен һәм иҗатын газета укучыларыбыз да күз алдына китерсен әле.

А.Егоровның гамәли бизәү сәнгатенә кереп китүе тикмәгә генә түгел. Казаныбызның 3 нче рәсем сәнгате мәктәбендә укыганда бервакыт малай композиция укытучысы белән бәхәскә керә. «Баскетбол уйнаучылар озын буйлы була, синең рәсемеңдәге ише кәрләләр тупны кәрзингә эләктерә алмаячак», – ди икән укытучысы. Чын баскетболчыларны гомерендә дә күрмәгән Анатолий исә аяк терәп каршы тора, безнең мәктәптә баскетболны гап-гади малайлар уйный, әллә кем булмаса да, мәктәп ярышларында хур булганнары юк, ди. Укытучысы белән фикерләре туры килмәгәнгә, 11 яшьлек малай мәктәпне ташлап китә. 14 яшьләрендә Мәдәният йортындагы рәсем студиясенә укырга килә. Анда балаларны һәм олы яшьтәге шәкертләрне бердәй якын күреп Рөстәм Килдебәков укыта. Аның Львовта сәнгать институты тәмамлап кайткан гына чагы. Рөстәм ага, тыштан тыныч тоелса да, соцреализм иҗат өслүбенә каршы барып, шактый тәнкыйть ишеткән кеше. Аны Рәссамнар берлегенә дә, Украинадан ияртеп кайткан хатыны Мария Семеновнаны кабул иткәннән соң, тагын ун ел үткәч кенә алалар. Өстәвенә, Львовта гамәли бизәү, монументаль сәнгатьләрне өйрәнә. Хатыны Мария Карача – гобелен остасы. Рөстәм ага үзе дә хатыны белән бергә гобеленнар иҗат итә, бергәләшеп республикабызның Г.Тукай исемендәге премиясенә ия булалар. Остазының ирек сөючән, башбирмәс холкы, гамәли бизәү сәнгате белән мавыгуы А.Егоровка да тәэсир итеп, халык һөнәрчелегенә карата кызыксынуын арттырган булса кирәк. Николай улы Анатолийның гамәли бизәү сәнгатен сайлавының тагын бер сәбәбе – соцреализм камыты кияргә теләмәве дип тә уйларга нигез бар. 11 яшендә үз сүзен яклап чыккан икән, олыгая барганда да, кеше арбасына утырмыйча, үз җырын гына җырлаячагы көн кебек ачык.

А.Егоров Мәскәүдә сәнгать-сәнәгать югары училищесында белем алганнан соң, картиналар иҗат итә, гобеленнар тукый. Рәссамның үз йөзе бар, гобеленнарын әллә каян танып алырлык. Мария һәм Рөстәм Килдебәковлар татар халык авыз иҗатына нигезләнеп, башлыча җете төстәге җепләрдән, яссы фигуралар белән иҗат итсә, А.Егоровның иҗат әсәрләрендә берьюлы реализм, импрессионизм, постимпрессионизм, модерн иҗат өслүбләре кушылганын күрергә мөмкин. Авторның шулкадәр төрле стильләрне табигый берләштерә алуы сокландыра. Гобеленнарның төсләре бик матур. Егоров төсне беренче урынга куя. Төс дөрес сайланса, сызымнар да, формалар да булачак, дияргә ярата. Төскә бик зур әһәмият биргәнгә күрә, аның нечкә, нәзакәтле иҗат ителгән гобеленнарын карaганда, күңел рәхәт чигә.

Гобеленны теләсә кем иҗат итә алмый. Бу төр сәнгатьтә авторлардан зур түземлек, эш сөючәнлек сорала. Шуңа күрәдер, бәлки, бездә гобелен осталары бармак белән генә санарлык. А.Егоров – шундый сирәк шәхесләрнең берсе. Аның дөньякүләм танылган Казан рәссамы Фешинга багышланган гобелен үлчәме – 4х2,2 метр. Рәссам аны ун ел иҗат иткән. Зөя утравына багышланганы да аннан ким түгел – 4х2 метр. Аңа биш ел вакыт киткән. Бу эше өчен А.Егоров олуг рәссамыбыз Б.Урманче исемендәге премиягә ия була. Рәссамның Бауман урамын, Ленин бакчасындагы фонтан тирәсендә кайнаган тормышны үзәккә алып тукылган иҗат әсәрләре дә сокландыра. Бер кешедә шулкадәр сабырлык булыр икән! Шуның өстенә рәссамның йөзләп картинасы да бар ич әле!

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

●«Тәрәзәдән Кремль күренеше».

●«Казанның Бауман урамы».

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 1.04.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2750 данә

Заказ 2746

16+